www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 5 (1370) 11 февраль 2022 ел

Татарстанда язылу индексы – П2355.

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga
madanizhomga
madanizhomga
madanizhomga

Пензада яшәп иҗат итүче рәссам Илдар Акъегет 1812 елгы Ватан сугышында, Беренче бөтендөнья сугышында катнашкан татарлар темасына да мөрәҗәгать итә.

Казан мәктәбендәге атыш кебек коточкыч хәлләр килеп чыкмасын өчен, нишләргә, бу вакыйгада кем гаепле – психолог фикере.

Татарстан Журналистлар берлегендәге картиналар күргәзмәсе күренекле радиожурналист, язучы Дания Гайнетдинованың бай күңел дөньясын ача.

Камиллекнең чиген билгеләргә Күкләр татар кызын яраткан!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Пенза өлкәсенең Урта Әләзән авылындагы Хатын-кызлар йортында Бөтендөнья хиҗаб көненә багышланган чара узды.
- 14 февральдә К.Тинчурин театрында шагыйрь Рифат Җамалның 70 яшьлек юбилеена багышланган «Күңелем сүрәләре» әдәби-музыкаль кичәсе уздырыла.
- 24 февральдә Мәскәүнең Үзәк кинематографистлар йортында Мөхәммәт Мәһдиев повесте буенча төшерелгән «Без – 41нче ел балалары» дигән нәфис фильм премьерасы була.
- Татарстан Милли китапханәдә татар рок-музыкантлары Рәдиф Кашапов, Зәринә, «Усал» һәм Gauga, Juna төркемнәренә багышланган «Ехали татары» веб-сериалы тәкъдим ителде.
- Казан кооператив институтының Татар мәдәнияте үзәге «Туфан Миңнуллин феномены» дип аталган бәйге игълан итте.
- Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте мөфти Нәфигулла хәзрәт Ашировның үтенече белән Урал, Көнбатыш һәм Көнчыгыш Себер мөселманнарына китаплар җибәрде.
- Татарстанның Питрәч районында Мәүлә Колый хөрмәтенә стела куелачак.
- Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан Новосибирскида беренче тапкыр мөселман мәдәнияте күргәзмәсе ачылды.
- Танылган журналист, телевизион алып баручы, Казан федераль университеты укытучысы Константин Куранов 86 яшендә вафат булды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Туфан ИМАМЕТДИНОВ, К.Тинчурин театрының баш режиссеры:

«Мин аңлыйм — һәр театрда бозарга ярамаган ниндидер традицияләр була ул. Әмма шуның аркасында алга куелган бурычлар үтәлми. Чөнки әлеге бурычларны үтәргә яраклы кешеләр җитешми. Әйтик, мин ТЮЗга килгәндә, анда 16 яшьлек малайны 45 яшьлек ир кеше уйный иде. Бу бик сәер күренә. Ә 19 яшьлек артист әлеге 45 яшьлекнең абыйсын уйный».

СЫНАМЫШЛАР

14 февральдә аяз күктә йолдызлар ачык күренсә, яз соң килә ● 15 февральдә кыш белән яз очраша, шунлыктан бу көнне һава торышы нинди булса, яз да шундый килә: кар яуса – яңгырлы ел көтелә; тамчы тамса – бодай, җил иссә – җиләк-җимеш уңа ● Салкын көндә кар яуса – җылыта ● Төнлә ай зур, кызгылт күренсә – җепшекләтә.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **7 сәгать 17 минутта** чыкты, һәм ул **16 сәгать 38 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **9 сәгать 21 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **32 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **18 февральдә 9 сәгать 53 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

12 февраль – актриса, Татарстанның халык артисты Рәйсә Гобәйдулла кызы Гобәйдуллинаның тууына 110 ел (1912–1997);

– тарихчы, сәясәтче, Татарстан Фәннәр академиясе академигы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстанның Дәүләт премиясе лауреаты Рафаил Сибгат улы Хәкимовка 75 яшь (1947).

14 февраль – язучы, педагог һәм публицист Мәхмүт Рәхим улы Әхмәтҗановның тууына 95 ел (1927–2010).

15 февраль – шагыйрь Кадыйр (Минкадыйр) Идият улы Сибгатуллинның тууына 80 ел (1942–1994).

17 февраль – баянчы, музыка белгече, педагог, Татарстан һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Рәгыйде Фатыйх улы Халитовка 80 яшь (1942).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Февральнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 11 февраль.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(8-16 февраль)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **16 гыйнвардан 17 февральгә кадәр** ашказаны, ашказаны асты бизе, талак актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны чистарту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген рәҗәб аеның 10 нчы көне

ҖАН АВАЗЫ

Казахмы дәүләтсез халык, әллә башкортлармы?

Башкортстандагы «башкортлаштыру» идеологларының берсе, татар халкы турында ямьсез, кимсетүле чыгышлары белән танылган журналист, тарих фәннәре кандидаты Салават Хәмидуллин үзенең игътибарын хәзер казахларга каршы юнәлдерә.

27 гыйнварда Дүртөйледә «Төньяк-көнбатыш башкортларның тарихы һәм мәдәнияте» темасына узган түгәрәк өстәл утырышында С.Хәмидуллин «казахларның дәүләте булмаган, ханлык булган, әмма ханлык – ул дәүләт түгел» дигән фикер белдерде.

Интернет киңлегендә «Малевич» псевдонимы астында татарларга каршы көрәш алып барган С.Хәмидуллинны күптән түгел Башкортстанда Халыклар дуслыгы йорты җитәкчесенең урынбасары итеп билгеләделәр.

Җанисәп алдыннан чуашлар, татарлар һәм Татарстан турында чит исем белән бик ямьсез комментарийлар язгач, блогер Ленар Мифтахныкы әлеге кешенең кем икәнен белергә алына. Бу эш әллә ни кыен булып чыкмый, чөнки С.Хәмидуллин, телеграмм мессенджерының ничек эшләвен аңлап бетерә алмау сәбәпле, үзенең кем икәнен ачыкларлык «эз» калдыра. Шулай итеп, «Татарстан Республикасы» атамасын «Татаросран» дип язып утыручы «Малевич» кушаматы астына яшеренгән бу кешенең «мәшһүр» тарихчы, С.Юлаев исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты С.Хәмидуллин икәнлеге ачыклана. Татарлар һәм чуашлар турында язган тискәре һәм ямьсез комментарийларны язып тору кирәкмәс, теләгәннәр интернетта Ленар Мифтахныкы блогына кереп укый ала.

Татарлар белән «дуслык күпере» салган кеше Халыклар дуслыгы йортына директор урынбасары итеп билгеләнгәч, ул, кәнәфигә утырып, казахлар белән элемтәне «нычытырга» җыенамы дигән сорау туа.

С.Хәмидуллинның Дүртөйледәге түгәрәк өстәлдә ясаган чыгышыннан өзек:

– Без Казахстандагы хезмәттәшләребез белән казах дәүләте турында сөйләшкәндә, Путин күптән түгел генә: «Казах дәүләте булганмыни?» дип әйтте. Бар да моны троллинг буларак кабул итте, ләкин тарихи яктан карасаң,

● С.Хәмидуллин Дүртөйледә узган түгәрәк өстәл утырышында чыгыш ясый.

бернинди дә казах дәүләте булмаган. Казах ханлыгы булган, ләкин ханлык – ул дәүләт түгел», – дип сөйли Хәмидуллин һәм ханлыкның ни өчен дәүләт булмавын аңлата башлый.

«Дәүләтнең нинди билгеләре бар? Халыктан читләшкән, халыкны легитим көчләү аппараты бар, ягъни – хакимият.

Төбәк тарихын өйрәнүчеләр казах яки башка ханлыкны «дәүләт» дип язса, теләсә кайсы тарихчы: «Юк, дөрес язмагансың. Ханлык дип яз, чөнки дәүләт өчен бу туры килми», – дип әйтәчәк. Европаны күздә тотсак, хәзерге типтагы дәүләтләр Яңа чорда гына барлыкка килгән. Мин Кытай турында әйтмим. Ул аерым очрак», – дип сөйли С.Хәмидуллин.

Төбәк тарихын өйрәнүчеләр башкортларның дәүләтчелеге турында сүз чыккач югалып калуы С.Хәмидуллинны борчуга сала икән. Хәмидуллин әлеге чыгышында башкортларның үз дәүләте булганмы-юкмы дигән мәсьәләне күтәрә, ләкин аңа читләтеп кенә җавап бирә. Әгәр дә Башкортстанда ханлык та, борынгы шәһәрләр дә булмаган икән, кайгырасы юк, башка халыкларның казанышларын «сызып ату» юлы белән үзеңне-үзең «күтәрергә» була. Хәмидуллинның схемасы шундый – Борынгы Грециядә дәүләт булмаган дип игълан итә, башкортларның да дәүләтләре булмаган. Димәк, алар икесе бер дәрәҗәдәге цивилизация булган икән.

– Борынгы Греция – алга киткән җәмгыятьме, юкмы? Әлбәттә, алга киткән. Әмма борынгы Грециядә дәүләт булмаган. Дәүләт – ул прогресс дигән сүз түгел. Борынгы Грециядә шәһәр общиналары дип аталган полислар яшәгән. Аларда бернинди дәүләт структуралары булмаган. Болар – башкорт волостьлары кебек үк общиналар. Общинниклар үзара тигез булган. Бөтен мәсьәләләр дә бергәләп хәл ителгән, барысы да ирекле гражданнар булып исәпләнгән, – дип тәкрарлый «бөек» Хәмидуллин.

Кызып киткәч, Хәмидуллин халык алдында Россия тарихы белән дә авыз чайкарга читенсенми.

– Киев Русе дәүләт булганмы? Юк, булмаган. Ул бер гаилә идарә иткән кенәзлекләрдән торган. Ул – буйсындырылган славяннардан ясак җыя торган вотчина дәүләте. Россия дәүләте дип Иван III дән соңгы вакытны әйтергә була. Ул вакытта Мәскәү Русе берләшә, салым, акча әйләнеше барлыкка килә. XV гасырга кадәр Русьнең үз акчалары да булмаган бит. Элегрәк йә Византия, йә гарәп тәңкәләре әйләнештә йөргән, Алтын Урда чорында Урда дирһәмнәре әйләнештә булган. Рус тәңкәләре XV гасырда гына барлыкка килгән, – дип тә өсти «бөек акыл иясе».

Мәскәү мэриясе сайты Киев Русендә бакыр акчалар X гасырда ук барлыкка килүе турында яза. Димәк, беренче рус акчаларына килгәндә, йә С.Хәмидуллин, йә Мәскәү мэрының сайты биш гасырга ялгыша.

Нумизмат, тарихчы Олег Степанов хәбәрчебезгә Мәскәү кенәзлегендә акчалар 1365 елда суктырыла башлавы мәгълүм булуын әйтте. Элекле рәвештә акча сугуны Дмитрий Донской башлап җибәргән. Тарихчы фикеренчә, аңарчы аерым кенәзлекләрнең дә үз акчалары булуы мөмкин, ләкин аларның елы билгеле түгел икән.

Казахларның дәүләтчелеге турында кызыксынып, без тарих фәннәре докторы, Казахстанның Вәлиханов исемендәге Тарих һәм этнология институты директоры Зиябек Кабульдиновка мөрәҗәгать иттек.

– Казахстан халкы һуннар, саклар, Төрки каганлыгы заманнарыннан бирле – 2500 елга якын дәүләтчелек традицияләренә ия. Хәмидуллин борынгы әби-бабаларыбызның уртак тарихын оныткан, – диде казах галиме.

Казахлар бу видеога тискәре фикер белдерә: «Башкортларның үз дәүләтләре булмаган, казахтан көнләшә», «провокатор» дип яза алар.

С.Хәмидуллинның «казах дәүләте булмаган» дигән сүзләре башкорт активисты, тарихчы Руслан Габбасовны да гаҗәпләндергән.

– Тарихчы дип аталган С.Хәмидуллин казахларда дәүләт булмаган дигән сүзләре белән ни әйтергә теләде икән? Бәлки, ул «ханлык – дәүләт түгел» дигән гыйбарәсен аңлатыбрак сөйләр дип, Казахстаннан дусларым бу турыда миннән аптырап сорый. Мине дә бу сүзләр гаҗәпләндерде. Хәзер безне бер үк көчләр казахлар белән дә ызгыштырырга тели, дигән фикер керә. Ә үземнең казах туганнарыма алдан ук әйтеп куям: сез безнең өчен иң якын, тугандаш халык һәм шундый булып калырсыз! – дип язган Руслан Габбасов үзенең Фейсбуктагы сәхифәсендә.

С.Хәмидуллин чыгышының мәгънәсен аңлау өчен, без Уфада яшәүче милләттәшебез, тарих фәннәре кандидаты Илдар Габдрәфыйковка мөрәҗәгать иттек.

– Беренчедән, Дүртөйлегә барып, төбәк тарихын өйрәнүчеләр алдында чит дәүләтләр турында фәлсәфә корунең бернигә кирәге юк. Тарихчыларга туган як тарихын өйрәнү методикаларын, архивлар белән эшләргә өйрәтсәләр, файдасы күбрәк булыр иде.

Һаман да шул бер үк кешеләр җыела да, җанисәп алдыннан чәйнәгән бер балык башын чәйни. Халык гарык бит инде ул сүзләрдән. Тынычланырга вакыт инде аларга. Безгә бит бер җирлектә бергә яшәргә, уртак проблемаларыбызны хәл итәргә кирәк. Республика башлыгы Уфада алдынгы университет төзү бурычын куйды. Дөньяга урта гасырлар карашы белән карап алга китеп булмый.

Икенчедән, ничек инде казахлар дәүләтсез халык булсын?! Төрки каганлык, Алтын Урда дәүләт булмаганмы? Башкортлар үзләре дә, татарлар, казахлар, ногайлар кебек үк – Алтын Урда дәүләтенең бер өлеше. Алтын Урда – чын дәүләтнең классик үрнәге. Казах ханлыгын ничек дәүләткә санамаска була? Аның да парламенты, идарәсе булган.

Кешелек цивилизациясенең бишеге булып исәпләнгән Борынгы Грецияне дәүләт түгел дип атау – ахмаклык. Мин моны тарихта үзен туз итеп күрсәтү өчен генә әйтелгән сүз дип аңлыйм. С.Хәмидуллин хәзер – Халыклар дуслыгы йорты җитәкчесенең урынбасары. Аның функциясе халыклар арасында каршылык тудырудан түгел, ә уртаклык һәм бердәмлек төзүдән гыйбарәт.

Рифат КАЮМОВ.
intertat.tatar

КИЛӘЧӘККӘ ТӨБӘЛГӘН МӨНӘСӘБӘТЛӘР

Бүген зур спортта гел дә сәясәтсез булмый, күрәсең. Пекинда кышкы Олимпиада ачылуга багышланган тантаналар алдыннан Кытай һәм Россия лидерлары Си Цзиньпин һәм Владимир Путин, форсаттан файдаланып, бүгенге чорның актуаль проблемалары хакында өч сәгатьлек сөйләшү үткәргән. Алар шулай ук яңа чорда халыкара мөнәсәбәтләр һәм тотрыклы глобаль үсеш турында кешелек киләчәге өчен мөһим белдерү кабул иткән. Анда исә халыкара мөнәсәбәтләрдә ике як та яңа кагыйдәләрне АКШ гегемонлыгыннан башка күзаллавы турында әйтелә. Ә COVID-19 инфекциясенең килеп чыгу проблемасын алар фәнни яссылыкта ята дип саный, аны сәясиләштермәскә чакыра. Мәскәү һәм Пекин НАТОның киңәюенә дә каршы. Алар аны, салкын сугыш синдромыннан арынып, башка илләрнең дә суверенлыгын, иминлеген һәм ихтыяҗларын хөрмәт итәргә өнди. Документ шулай ук атом-төш коралына ия барлык илләрне дә салкын сугыш менталитетыннан арынырга, дәүләт иминлеген тәэмин итүдә бу коралның ролен киметергә, чит илләрдә урнаштырылган андый коралны аннан чыгарырга, шулай ук ракеталарга каршы глобаль саклану системасының да чамасыз үсешенә чик куярга чакыра. Анда Кытай-Россия мөнәсәбәтләренең бүген салкын сугыш чорындагыдан ышанычлырак булуы, дуслыкның чикләрне белмәве, хезмәттәшлектә исә тыелган зоналар булмавы турында да әйтелә.

Әлбәттә, Кытай һәм Россиянең идарә ысулларында уртаклык зур (икесендә дә алар тоталитар системага корылган). Демократиянең гомумкешелек кыйммәте таныла, әмма аны һәркайсы үзенчә шәрехли. Әйтик, төп халыклары үз хокукларын парламентта яклау мөмкинлегеннән генә түгел, туган телләрендә белем алу хокукыннан да мәхрүм ителгән Россиядә демократия турында нинди сүз булырга мөмкин?! Шуңа күрә сәяси система анда аны имитацияләүгә генә корылган. Бу ике илдә халыкара хокук нормаларын шәрехләү белән дә шундый ук хәл. Шуңа да карамастан, эш нәтиҗәләрендәге һәм ил үсешендәге аерма аларда – гаҗәпләндерерлек. Зур аерма ике илнең тышкы сәясәтендә дә ярылып ята. Дөнья тотучылар кулында гомер-гомергә «сәясәт коралы» һәм «туп азыгы» булып хезмәт иткән Россия бүген дә шуны ук дәвам итсә, Кытай исә читләр эшенә тыкшынмый, барлык илләр белән дә гармонияле мөнәсәбәтләр урнаштыру яклы. Аерма Тайвань һәм Кырым проблемаларына мөнәсәбәттә дә күренә: Россия Тайваньны Кытайның аерылгысыз өлеше дип таныса, Кырым мәсьәләсен Кытай танымый. Икътисадка да күз салыйк. Россия өчен мөһим стратегик бурыч - Кытай белән мөнәсәбәтләрдә Себер һәм Ерак Көнчыгышны социаль вә икътисади яктан күтәрү. Менә хәзер дә бу төбәкләрдән Кытайга нефть һәм газ сату турында килешүләр төзелде. Кытай өчен бу отышлы, чөнки изоляция шартларында да акча эшләү өчен, Мәскәү чималны арзанрак бәягә, әмма күпләп сатарга мәҗбүр.

Игътибарны Кытай-Россия дуслыгының геосәяси ягы да җәлеп итә. Бу җәһәттән, күмәк Көнбатышның Россияне Кытай кочагына этәрүе бик үк аңлашылып та бетми кебек. Тик беренче икесенең зур сәясәттә капма-каршы яктан, әмма уртак максатларда эш итүен искә төшерсәк, барысы да үз урынына баса: Россиягә әлеге геосәяси уеннарда «засланный казачок» (рәсми рәвештә агент булып саналмаган, ләкин разведка тарафыннан дошман ягына аны үзләренә агент итеп «вербовка»ласыннар өчен җибәрелгән зат, ике яклы агент) роле бирелә. Стратегик һөҗүм кораллары (СНВ) буенча сөйләшүләргә АКШның Кытайны җәлеп итү теләге дә ул чакта яхшы аңлашыла: АКШ, Россия һәм Кытай арасында өчьяклы яңа килешү төзелгән очракта, хәрби яктан стратегик өстенлек кемдә булачагы шик уятмый. Моны Пекин да яхшы аңлый, күрәсең. Шуңа ул Россия белән хәрби берлек төзүдән читләшә һәм СНВ буенча да килешүләрдә катнашырга җыенмый.

Хәлбуки, Кытай-Россия хезмәттәшлеге ныгу Татарстан өчен дә яңа мөмкинлекләр ача. Ул аңа үз икътисадына – Кытай технологияләрен, ә М-12 трассасының (ә ул Европа – Көнбатыш Кытай халыкара транспорт коридорының бер өлеше булачак) Казанга караган өлешенә һәм эчке агломерацияләргә бу илдән инвестицияләр дә җәлеп итү мөмкинлеге бирә, «Татарстан Республикасы» дигән үзҗитешле агломерация формалаштыруда җитди адым була ала. Ике арада милли-мәдәни багланышларны кытай һәм татар җырларындагы аһәң вә пентатоника уртаклыгын, шулай ук тарихи традицияләрне дә исәпкә алып ныгыту исә бу халыклар арасында гармонияле мөнәсәбәтләр урнаштыруга да хезмәт итәчәк.

Фоат УРАЗАЙ.

Галимнәр дә тартылырга тиеш

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Е.К.Завойский исемендәге Казан физика-техник институтында булды. Анда ул яшь галимнәр белән аралашты һәм аларның проектлары белән танышты. Очрашуда туган телне өйрәнү, татар телен үстерү мәсьәләсе дә күтәрелде.

«Бу безнең өчен иң авырткан тема. Татар теле генә түгел, чуаш, мари, удмурт һәм башка телләр дә бик мөһим. Аңлашыла ки, без барыбыз да рус телен яхшы белергә тиеш, әмма безнең халыкларның туган телләрен дә онытырга ярамый. Тик бер методика белән генә ярдәм итеп булмый, телне өйрәнү теләге булырга тиеш. Теләк уятырга кирәк. Гаиләләрдә аралашсыннар өчен, туган телләрне популярлаштырырга кирәк», – диде Татарстан Президенты. Берничә телне белү – ул белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның көндәшлектә зур өстенлеге, бигрәк тә «кеше фәнгә барганда», дип ассызыклады ул.

«Цифрлы мөмкинлекләргә килгәндә, без ресурслар бирергә әзер, бу бик мөһим. Чынлыкта, оят, хурлык. Без өйрәтәбез, ләкин полилингваль мәктәптә дә татар теленең дәрәҗәсе мактанырлык түгел. Әмма башка милләт вәкилләре дә үз үзенчәлекләрен, мәдәниятен саклап калырга тели, ә тел – ул иң мөһиме», – дип билгеләп үтте республика җитәкчесе.

Россия Фәннәр академиясе Казан фәнни үзәгенең гуманитар лабораторияләрендә Идел буе халыклары телләренә һәм башка телләргә дисциплинарара тикшеренүләр үткәрәләр. Хәзерге вакытта татар теленә өйрәтүнең инновацияле методикаларын эшләү бара, заманча дәреслек эшләнә.

Моннан тыш, Казан фәнни үзәге галимнәре инглиз, кытай һәм башка чит телләрдә татар теле дәреслекләре һәм үзлегеңнән өйрәнү китаплары булдыру турында да уйлана. Белгечләр шулай ук татар теле өлкәсендә цифрлы продуктлар, мәсәлән, кушымталар рәвешендә цифрлы экспресс-курслар, татар телен өйрәнү өчен персонализацияләнгән полилингваль платформалар, виртуаль класслар эшләргә тели.

Рөстәм Миңнеханов бу эшләнмәләр белән кызыксынды һәм аларны Татарстан Республикасы Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе җитәкчесе Марат Әхмәтовка өйрәнергә кушарга вәгъдә бирде.

Театрны булдырганчы, тарихны белү кирәк

Камал театрының архитектура концепциясен эшләү буенча Ачык халыкара бәйге кысаларында театрның youtube-каналында татар мәдәнияте турында лекцияләр куелды. Барлыгы 3 лекция, һәркайсы 30-40 минут дәвам итә.

Лекцияләр циклын булдыру идеясе архитектура концепциясенә халыкара бәйге үткәрү барышында барлыкка килде. Татарстан тарихчылары һәм мәдәният белгечләре конкурсантларны татар мәдәнияте белән таныштырып кына калмыйча, аларга ниндидер милли идея дә бирергә тиеш иделәр.

Бәйгедә катнашучы 14 ил архитекторлары экспертларның ярдәмен югары бәяләде, үз проектларын эшләү өчен бирелгән белемнәрнең кыйммәтен таныды һәм татар халкы дөньясын ачу мөмкинлеге өчен рәхмәт белдерделәр. Нәтиҗәдә барлык материалларны да киң катлау тамашачыларга аңлаешлы итәргә, мәдәният белән кызыксынучыларга белем һәм эшләнмәләр белән уртаклашырга карар кылынды. Цикл түбәндәге лекцияләрдән тора:

1. Камал театры: тарих һәм киләчәккә караш. Лекциянең авторы – театр тәнкыйтьчесе Нияз Игъламов. Алып баручы – Камал театры артисты, Татарстан Республикасының атказанган артисты Рамил Вәҗиев.

2. Татарларның сәнгати мәдәнияте. Лекциянең авторы һәм алып баручысы – сәнгать фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең сынлы һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге мөдире, татар театры һәм сәнгать тарихы турында китаплар һәм мәкаләләр авторы Рауза Солтанова.

3. Перформанс һәм мәдәниятне деколонизацияләү турында. Лекциянең авторы һәм алып баручысы – философия фәннәре докторы, Тарих институты директоры урынбасары, Амстердам университеты ассистенты-профессоры Альфрид Бустанов.

Казан – яшьләр башкаласы да

Быел Казан Ислам дөньясының яшьләр башкаласы була. Шул уңайдан ел дәвамында Татарстан башкаласында масштаблы проект кысаларында дистәдән артык зур җыен-тантаналар узачак.

Алар арасында иң мөһиме – Ислам дөньясы илләре яшьләр эшләре буенча министрларның глобаль саммиты булачак. Ислам дөньясының яшьләр башкаласы статусы төрле елларда Истанбул (Төркия), Шираз (Иран), Путражая (Малайзия), Фәс (Марокко), Доха (Катар) кебек эре шәһәрләргә бирелде.

Бу статус химаясендә, нигездә, мәгариф юнәлешендәге чаралар узачак. Март аенда Казанның Ислам дөньясының яшьләр башкаласы буларак инаугурация тантанасы планлаштырыла. Тантаналы чара вакытында Татарстан башкаласына Дакки шәһәре (Бангладеш) символик алтын ачкыч тапшырырга тиеш.

Шулай ук ел дәвамында шәһәрдә Коръән уку бәйгесе, спорт ярышлары (ат чабышлары һәм киберспорт буенча яшьләр чемпионаты), халыкара яшьләр форумы, заманча мөселман мәдәнияте фестивале һәм башкалар узачак.

Яшьләр эшләре буенча министрлар саммиты төп вакыйга булачак, анда ислам дөньясы илләреннән 56 вәкил катнашачак.

Казанның яшьләр башкаласы итеп сайлануы турында хәбәрне онлайн-элемтә аша Ислам хезмәттәшлеге оешмасының Яшьләр форумы җитәкчесе Таха Айхан раслады.

«Мәдәни җомга» газетасына февраль-март айларында 2022 елның II ярты еллыгы өчен ташламалы бәядән язылып куя аласыз. Татарстанда газетага язылу индексы – П2355. Язгы ыгы-зыгылы вакытка калдырмыйча, бүген үк язылып кую уңайлы да, отышлы да. Безнең белән бергә булыгыз!

1 нче биттә – Кышкы Олимпия уеннарында команда беренчелегендә алтын медаль яулаган милләттәшебез Камилә Вәлиева.

Матбугатчыларның хисап утырышы

Узган атнада Казан каласының IT-парк бинасында «Татмедиа» матбугат һәм гаммәви багланышлар буенча Республика агентлыгының 2021 ел йомгакларына багышланган киңәйтелгән коллегия утырышы узды.

Анда Республика агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев, «Салават күпере» журналының баш мөхәррире Зиля Хөснетдинова, «Диалог» яңалыклар агентлыгының генераль директоры урынбасары Андрей Цепелев, Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының матбугат үзәге җитәкчесе Әлфия Хәсәнова, Россия нәшриятчылар Ассоциациясе президенты, «Ак шәһәр» сәүдә йортының генераль директоры Константин Чеченев, «Интернетны үстерү институты»ның пиар-директоры Александр Ляпин докладлары тыңланды.

Киңәйтелгән утырышта Татарстан Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сафәров та катнашты һәм чыгыш ясады. Матбугат алдынгыларына мактаулы исемнәр һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырылды.

Чыгышларга караганда, Россиядә бүген нәшриятлар эшчәнлеге һәм китап сәүдәсе иң аяныч хәлдә. Илнең нибары 12 шәһәрендә генә дәүләт нәшриятлары эшли, тик алар да авторларга совет чорындагыдан ун тапкыр кимрәк тә каләм хакы түли алмый. Милли республикалар арасыннан фәкать Татарстан, Башкортстан һәм Якутиядә генә китапларны дәүләт хисабына чыгарырга мөмкинлек бар. Ә илнең меңәрләгән башка шәһәрләрендә гомер итүче яшь талантлар язган әсәрләрен үз акчаларына чыгарырга мәҗбүр. Әле шулай итеп санаган чагында да илдә яшәүче һәр кешегә узган елда 0,15 данә генә китап чыгарылган. Татарстан китап нәшриятында 154 исемдәге китап чыгарылса да, аларның гомуми тиражы 228 меңнән артмый.

Илдәге нәшриятлар эшчәнлеге 1913 ел түгел, хәтта Бөек Ватан сугышы чорында чыгарылган китаплар саны белән дә чагыштырырлык түгел. Икс-чиксез сандагы калалар буенча соңгы 20 елда гына да 28 мең чиркәү төзелгән, алар өчен миллиард сумнарча акча коелган. Ләкин чиркәү идеология дә булдырмый, Россия кешеләренең әхлакый йөзен дә тәрбияли алмый. Гасырлар буена кешелек горурлыгы һәм белем чишмәсе булган Галиҗәнап Китапның бу рәвешчә читкә тибелеше җәмгыятьне яктылыкка илтми.

Яңа фонд оешты

Татарстанда «Игелек-Доброта» дип аталачак җәмгыятьнең рухи-әхлакый үсешенә ярдәм итү Республика фонды оештырыла. Бу хакта указга Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кул куйды.

Документта әйтелгәнчә, яңа оешманың максаты – «җәмгыятьнең рухи-әхлакый үсешенә, Татарстан Республикасы халыкларының гореф-гадәтләрен һәм традицияләрен саклауга ярдәм итү, шулай ук төбәкнең фәнни, мәдәни, интеллектуаль һәм туристлык потенциалын үстерү».

Фондны гамәлгә куючы эшен һәм вәкаләтләрен Татарстан Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы башкарачак. 2022 елдан башлап оешма эше республика бюджеты хисабына финансланырга тиеш.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Хөкүмәте фондка нинди милек тапшырыласын билгеләргә һәм аны Казанда урнаштыруны тәэмин итәргә тиеш. «Игелек-Доброта» фондының кузәтчелек һәм попечительләр советлары составына республиканың дәүләт, җәмәгать, мәдәни һәм бизнес эшлеклеләре кертелгән. Күзәтчелек советын – Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, попечительләр берлеген (килешү буенча) – Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов җитәкләячәк. Совет составына шулай ук Татарстанның Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе Иван Гущин да керә. Казанда Җәмигъ мәчетен төзү шушы фонд аркылы башкарылырга мөмкин.

Укытучылар борчыла

Фән популяризаторы, математик Алексей Савватеев үзенең фикердәшләре белән Россиядә мәктәпләрне коткару таләбе белән имзалар җыя башлаган. Әлеге мөрәҗәгать Россия президентына, Россиянең хөкүмәт рәисенә һәм хакимиятнең башка вәкилләренә атап язылган.

Петиция авторлары әйтүенчә, Россиядә мәктәптә белем бирү тирән кризиста. Мәктәпләрне коткару өчен ашыгыч адымнар кирәк. Мәктәпләр кызганыч хәлдә булу сәбәпле, башкалада урнашмаган югары уку йортларына башлангыч нигезләре дә булмаган студентлар укырга килә.

«Безнең мәктәп укучыларының БДИны уңышлы бирүе берни хакында да сөйләми. Бөтен куелган көчләргә карамастан, илнең белем бирү системасының деградациягә йөз тотуын үзгәртеп булмый», дип яза петиция авторлары.

Шулай ук алар мәктәптәге цифрлы һәм дистанцион технологияләр, БДИның максатчанлыгы, шулай ук авылларда аз укучы булган мәктәпләрне ябып, авылны таркату кебек темаларга хакимиятләр белән бәхәс башларга ниятли. Имзалар җыю Citizen.go. порталында бара. Ул инде 40 меңнән артык имза тупланган.

Җыр эзли «Яшь йөрәкләр»

«Яшь йөрәкләр» бәйгесендә катнашырга теләгән үзешчән җыр авторларыннан гаризалар кабул итела башлады. Бәйгегә җибәрелгән җырларның авторлык хокукларын оештыручылар үзләренә алмаячак.

«Авторлык хокуклары безгә кирәкми. Бәйгедә җиңгән җырларны без алга таба җырчыларга тәкъдим итәчәкбез. Ошатсалар, җырның авторы белән таныштырабыз. Алга таба алар үзләре хезмәттәшлек итә башлый. Фестивальдән соң авторларның җырларын алган җырчылар булды», – диде продюсер Җәүдәт Гыйльманов.

Ж.Гыйльманов әйтүенчә, эшләр һәвәскәр композитор һәм шагыйрьләрдән кабул итела. «Көй әзер текстка яки, киресенчә, әзер көйгә шигырь язылган булырга тиеш. Бәйгегә киң аудиториягә танылмаган үзешчәннәр чакырыла. Кабул ителгән җырларны күренекле автор-башкаручылар бәяләячәк».

Продюсер фестивальнең онлайн узачагын әйтте. Гаризалар 1 сентябрьгә кадәр кабул итела. Эшләрне «Яшь йөрәкләр» сайтына җибәрү сорала. Жюри әгъзаларының җырларны сайлап алуы, бәяләүләре онлайн трансляциядә барачак. Җырларны сайлап алуда халык та катнашачак – интернетта онлайн тавыш биреп булачак. 10-15 авторны сайлап алу ниятләнә. Сайлап алынган авторлар – җиңүче булып санала һәм гала-концертка чакырыла.

«Җиңүчеләргә «Яшь йөрәкләр» сыннын бүләк итәчәкбез һәм аранжировка ясату яки яздыру мөмкинлеген бирәбез», – диде Җ. Гыйльманов.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

Мондый бәйге булганы юк иде

Татарстан Президенты карамагындагы Татар телен саклау комиссиясе ярдәме белән үткәрелгән ябык әдәби конкурска йомгак ясалды, «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында матбугат очрашуы узды. Жюри рәисе Ркаил Зәйдулла конкурсның Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов инициативасы белән үткәрелүен ассызыклады.

«Әлеге ябык конкурс гайре табигый итеп кабул ителергә тиеш түгелдер. Әмма мондый масштаблы һәм мондый приз фонды конкурсның татар әдәбияты тарихында булганы юк», – диде Ркаил Зәйдулла.

«Безнең кәгазьгә язылмаган бәяләү бизмәне дә бар – бу әсәрне «Казан утлары»нда бастырып буламы. Җиңгән әсәрләр барысы да бу журналда чыгарылырга лаеклы», – диде ул. «Романнар» жанрында җиңеп чыккан әсәрләрнең икесе – I урын алган Зөлфәт Хәким романы һәм III урын алган Равил Сабыр әсәре быел «Казан утлары»нда басылачак. Фирдүс Гыймалетдиновның II урын алган «Үзбәк хан» романы киләсе елга басылыр дип көтелә. Чөнки быел шул ук авторның башка романы басыла башлады.

Бәйгедә җиңгән әсәрләрнең авторлары 21 февральдә – Халыкара туган телләр көнендә бүләкләнәчәк.

«Балалар һәм үсмерләр әдәбиятына әсәрләр чагыштырмача аз килде һәм аларның сыйфаты да без теләгәнчә югары түгел иде», – диде Язучылар берлеге рәисе. Ул ноябрь-декабрь аенда үткәрелгән Роберт Миңнуллин исемендәге конкурсны да искә алды. Анда әсәрләрнең чагыштырмача аз килүен һәм күбесенең сыйфаты да түбән булуын әйтте. «Без комикс һәм скетч жанрларын да керткән идек. Скетчның нәрсә икәнен безнең язучылар онытып та җибәргән, ахрысы», – диде ул.

«Балалар әдәбияты безне борчыган тема булып кала бирә. Бу турыда уйларга һәм нинди дер юлларын табарга кирәк. Балалар үзләренә адресланган әдәбиятны укымый икән, безнең киләчәктә укучылар азая дигән сүз», – дип нәтиҗә ясады Р. Зәйдулла.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

● Россия Умартачылык фәнни-тикшеренү институты мәгълүматлары буенча, илдә ун ел эчендә бал кортлары 40 процентка кимегән. АКШта кыргый умарталарның 90 проценты юкка чыккан. Алга таба да шулай дәвам итсә, 2035 елга бал кортларын бөтенләй үлеп бетәргә мөмкин. Бу очракта бүген игелә торган агрокультураларның өчтән берен үстерү тукталачак, чөнки үсемлекләрнең 75 процентын бал кортлары серкәләндерә. Альберт Эйнштейн: «Умарта кортлары юкка чыкса, кешелек дөньясы дүрт елдан артык яши алмаячак», – дип әйтеп калдырган.

● Дөньяда барлыгы 50 миллионнан артык корт күче исәпләнә, алар елына миллион тонналан артыграк бал җитештерә. Бер умарта күче сезонга уртача 27-45 килограмм бал туплый. Бер кашык балны 200 корт көн буе җыя. Умарта күчендә 15 меңнән 80 меңгә кадәр бал корты булырга мөмкин. Эшче кортлар җәен 3 атнадан 6 атнага кадәр яши һәм шул вакыт эчендә бер кашык бал җыеп өлгерә.

МУСА ҖӘЛИЛ - ИЛҺАМ ШАКИРОВ атналыгы

15 февраль халкыбызга ике бөек затны - патриот шагыйрь Муса Җәлил белән дөньяга мәшһүр җырчы Илһам Шакировны бүләк иткән. Халкыбыз, Илһам Шакиров үзе исән чагында, аның бөеклеген танып, аңа ихтирамын күрсәткән булса, Муса Җәлилнең 1956 елда «Моабит дәфтәре» илгә кайткач, каһарманлыгы турысынча танылып, аны ил Советлар Союзы Герое һәм Ленин исемендәге дәүләт премиясе белән зурлады. Бу – дөнья күләмендә бердәнбер очрак. Ике шәхесне аларның иҗатындагы «Җырларым» да бергә бәйли. М.Җәлил белән И.Шакировның туган көннәре бергә туры килүе – аларны дөнья күләмендә бер иҗади күтәрелеш белән искә алу өчен зур форсат. «Җиһангирлар» төркеме, «Гөлзада», «Аксу» студияләре, Мәгариф һәм Мәдәният министрлыклары, «Җыен» фонды, «М.Җәлил музей-фатиры» вәкилләре, галимнәребез Фаяз Хуҗин, Миләүшә Хәбетдинова, Татарстан Дәүләт Советы депутаты, «Бала сити» полилингваль балалар бакчасы җитәкчесе Альбина Насыйрова катнашында узган утырышта бу уңайдан 14-20 февраль көннәрен «Муса Җәлил-Илһам Шакиров» атналыгы итү турында тәкъдим белән чыкты. «Бу көн татарлар өчен мәшһүрләребезне хәтерләү, алар белән горурлану, үзара туплану көннәре булып узарга тиеш», – дип билгеләп үтте Гөлзада Сафиуллина.

«Бу эшкә Яшьләр эшләре министрлыгы, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе, Татарстан Язучылар берлеге дә бик теләп кушылырга теләк белдерде», – диде «Җиһангирлар» төркеме җитәкчесе Хәлил Гайнетдинов. Әлбәттә, И.Шакировның Николаев урамындагы бишенче йортка куелган мемориаль тактасына һәм М.Җәлил һәйкәленә чәчәкләр салу тантанасын оештыру мәслихәт. Х.Гайнетдинов бу көннәрне марафон формасында уздырырга кирәклеген искәртә. Мәктәпләрдә, урта һәм югары уку йортларында, балалар бакчаларында, мәдәният йортларында һ.б. оешмаларда М.Җәлил белән И.Шакировны искә алу чаралары уздырылуы, атна дәвамында мәгариф һәм мәдәният учреждениеләрендә һәм радиолар аша Илһам ага җырлары, Җәлил шигырьләре яңгырап торуы мәслихәт. Планнар да, ниятләр дә бик матур. Бу көннәрдә балалар бакчаларында, мәктәпләрдә, мәдәният йортларында И.Шакиров башкаруындагы җырлар яңгырап торса, Җәлил шигырьләрен укулар үткәрелсә, бала бакчага килгәндә аларны җыр каршы алса, шәхесләребез дә ул-кызларыбызның хәтерендә калачак. Шул ук вакытта мәчетләребездә дә М.Җәлил һәм И.Шакиров рухына Коръән укылуы һәм багышлануы күз алдында тотыла. Утырышта катнашучылар бу көннәрдә һәр татар гаиләсенең дә балалары, оныклары белән бергәләп мәшһүр җырчыбыз башкаруындагы җырларны тыңлап, патриот шагыйрь шигырьләрен укыну гадәт итүенә дә ышаныч белдерде. Рәссамнар да мәһшүрләребезгә игътибарны арттырырга тиеш. Моннан тыш һәркайсыбыз бу көнне бөек затларыбызны искә төшереп зурлауда кулыннан килгәнне эшләп, Җәлил шигырьләрен укып, шуны видеога төшереп, фотолар белән бизәп, Ютуб каналына, социаль челтәрләргә урнаштырса, алар бар дөньяга таралачак һәм гомерлеккә шунда калачак.

«М.Җәлил музей-фатиры» директоры Нәзирә Фәттахова Җәлил исемен мәңгеләштерүдә төрле конкурс-фестивальләр үткәрелүе турында сөйләде. Бөтендөнья татар конгрессы быел дүртенче тапкыр «Җәлил укулары» Халыкара әдәби бәйгесен уздырып килә. Сентябрь аенда ук игълан ителгән конкурс быел да уңышлы узды. Атналык көннәрендә аның җиңүчеләрен дә игълан итү планлаштырыла.

28-29 гыйнварда Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләре базасында «Поэт и музыка» («Шагыйрь һәм музыка») дигән Халыкара фестиваль башланып киткән. Анда музыка мәктәпләрендә, музыка училищеларында укучы балалар һәм студентлар катнаша. Аның төп оештыручысы – М.Җәлилнең кызы Чулпан ханымның оныгы Татьяна Михайловна. Ул, Мәскәүдән дәрәҗәле музыка мәктәпләрендә укыган балаларны алып килеп, осталык дәресләре үткәрүне дә оештыра. Ике мәйданчыкта да фестиваль концертлары югары дәрәҗәдә узган, конкурста шигырь укучылар да катнашкан. Көйләр төрле музыка коралларында башкарылган, татар музыкасы да еш яңгыраган. Концертның чираттагысы 18 февраль көнне Милли музейда, 19ы көнне С.Сәйдәшев исемендәге зур концерт залында булачак. Фестивальнең йомгаклау концерты Мәскәү шәһәрендә узар, дип тәгаенләнә.

Ә 15 февраль көнне традицион рәвештә Милли музейда сакланган «Моабит дәфтәре»нең төп нөсхәсе күнә үтә. М.Җәлил музей-фатирында көндезге сәгать икедә республиканың 2021 елда М.Җәлил премиясе лауреатлары кунакта була. «Төрле өлкәләрдә эшләгән иҗат әһелләренең халыкка, балаларга әйтер сүзләре бар», – диде Н.Фәттахова.

Филология фәннәре кандидаты Миләүшә Хәбетдинова яшьләрне җәлеп итү өчен аларның теле, стиле белән гамәлләр башкару, креатив булу кирәклеген дә искәртте. Ул бу уңайдан Театр училищесында зур иҗади мөмкинлеккә ия татар төркеме булуын, аларның бик оста миниатюралар куюын искә төшерде. Шулай ук Кариев театры директоры Луиза Янсуар, шагыйрә Йолдыз Миңнуллина, артистлар катнашында да куелышлар эшләнгәндә, отышлы булачагы әйтелде.

Тарих фәннәре докторы Ф.Хуҗин белдергәнчә, галимнәр дә бу эшкә катнашып китә ала. Әминә ханым элеккерәк елларда М.Җәлилнең архивын Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты мирасханәсенә тапшырган булган.

Бу көнне шулай ук И.Шакиров музеен ачу мәсьәләсенә дә кагылып үтелде. Дөрестән дә, Татарстанга чит илләрдән, Россия төбәкләреннән килүчеләрнең Илһам абыйның рухын тоеп, аның истәлекләрен күрсәсе, җырларын ишетәселәре килә, шуңа да Казанның үзәгендә мәшһүр җырчыбызның кадерле ядкәрләре сакланган музей булуы кирәк. «Җыен» фонды директоры Фуат Рәфыйков үзенең офисында Илһам абыйның ноталарын, китапларын, альбомнарын, видео материалларын саклавын әйтте. Ул шулай ук Илһам аганың фатирында калган күп кенә истәлекләренең юкка чыгу мөмкинлеген искәртте. Әйтик, җырчының «Сандугач»ны башкарганда кигән ак костюмы инде чүплеккә ташланган. Моннан тыш Илһам абыйның фатиры сатуга куелган. Аның яңа хуҗасына җырчының мирасы, киемнәре, диван, чынаяк-тәлинкәсе, урындыгы, өстәле, юбилейлары белән котлаган папкаларының һ.б. берсе дә кирәк булмаячак. Ф.Рәфыйков музейның Татар бистәсендә экскурсия юлында иркен бинада урнашкан итеп күз алдына китерүен әйтә. «Музейның 200 квадрат метрлы залы, җырчының дисклары, татар халкының күренекле шәхесләренең, әдипләребезнең хезмәтләре, әсәрләре куелган китапханәсе, концерт залы булуы мәслихәт. Килүчеләрне исә Илһам аганың җырлары каршы алса, билгеле ки, тирән тарихлы, әдәбиятлы, гыйлемле, бай мәдәниятле татар халкының кунакчыллыгы да чагылачак.

Сөембикә КАШАПОВА.

«Ач кешедә шигырь кайгысы булмый»

Башкортстанның халык шагыйре Марат КӘРИМОВ әдәбият, сатира-юмор, бүгенге вәзгыять турында фикерләре белән уртаклаша.

– Марат абый, бүген җәмгыятьтә әдип сүзенең көче бармы?

– Әдәбиятның көче элек бар иде. Хәзер ул вакыт узды. Үземнең яшем, ягъни 92 не тутырып 93кә киткән биеклектән караганда, шигърият ташып торган, әдәбиятның көче булган заманнар булды. Татар-башкорт шигърияте чәчәк аткан вакытларда яшәдек. Элекке шагыйрьләр сүзләре белән дә, үзләре дә күңелгә якынрак. Безнең шигърияткә, тормышка, дөньяга фикерләребез туры килә иде. Без бер идеаллар белән, бер юнәлештә яшәдек, шул чор бик сагындыра. Хәзер башка заман. Элек шагыйрьләр авылга килсә, бар халык клубка җыела иде. Ә хәзер андый очрашулар да юк, кем шагыйрь, кем шагыйрь түгеллеген белеп тә бармыйлар. Марсель Галиевнең «Халык мине белмидер дип уйлыйм» дигән бер әңгәмәсен укыган идем. Чынлап та, белмиләр, хәтта язучылар бер-берен белми. Заманында Язучылар берлеге әгъзасы булу бик авыр иде. Бүген хәреф таныган кешеләрне көтү-көтү алып бетерделәр, әдәбиятның бәясе бик түбән төшеп китте.

Язучылар турында белешмә китабын актарып утырам, анда мин белмәгән күпме кеше бар! Без белмәгәнне халык ничек белеп бетерергә тиеш? Балалар татарча, башкортча китап укымый, алар телевизор, интернетка капланган. Бу да әдәбият үсешен туктата. Балалар урыслашып бетеп бара, татар, башкорт авылларында да алар русча аралаша. Берчак Кәтибә Кинҗәбулатованың туган ягы – Чиләбе өлкәсе Аргаяш районының Мәүлит авылына барган идек. Мәктәпкә барырга кирәк иде. Бер баладан: «Мәктәбегез кайда?» – дип сорадык. «Что такой мактэп?» – ди бу. Школа дигәч кенә аңлатып җибәрде. Шулай әкренләп юкка чыгып, йотылып барабыз. Урбанизация дә үз эшен башкара.

– Шагыйрь ач булырга тиеш дигән фикер бар. Килешәсезме?

– Акча ул үзмаксат түгел. Акча булса, кеше җан асрый ала, чит илләр күрә, чагыштыра, рухиятен киңәйтә ала. Шагыйрь ач кына түгел, ялангач та булырга мөмкин. Ач кешедә шигырь кайгысы булмый, ул ашау турында уйлый. Ач шагыйрьдән нинди шигырь көтәсең? Бүген иҗат кешене ашатмый. Шигырь белән генә тамак туйдырып булмый, чөнки гонорар юк. Дәрдемәндне алыйк. Ул миллионер булса да, шигырьләр яза. Ул гына да түгел, халык өчен журналлар чыгара, сәләтле яшьләрне чит илләрдә укыта.

Минем иң акчалы чагым «Һәнәк» журналында эшләгәндә булды. Чөнки анда гонорар эшләү мөмкинчелеге булды. Мин бик күп яздым. Гонорар хезмәт хакыннан берничә тапкыр күбрәк була иде.

– Тормышта принциплардан тайпылырга туры килдеме?

– «Һәнәк»тә мөхәррир булган елларны. Шунда «Шайтан котыртты» дигән хикәям чыккач, обкомнан идеология секретаре Таһир Ахунҗанов (1967-1987 елларда КПССның Башкортстандагы обкомында идеология секретаре) аны үзе турында дип кабул иткән һәм мине эштән алдылар. Әсәрләремне басмаска, китапларны китапханәләрдән алырга дигән әмер биргән. Мәскәүдә һәм Уфада чыгарга торган китапларым тыелды. Башкортстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Әсгать Мирзаһитов киңәше белән берничә ай Якутиядә яшәп кайттым. Кайткач «Башнефть»нең фәнни-тикшеренү институтында инженер вазифасын үтәдем. Алар турында газеталарга мәкаләләр язып тордым. Аннан Динис Бүләков телевидениегә әдәби редакциягә эшкә алды. Эзәрлекләүләр дүрт-биш елга сузылды. Мин принципларыма тугры булдым, бервакытта да яраклашмадым, үзем булып калдым.

– Халык шагыйре исемен халык бирми. Бу исем дөрес бирелә дип уйлыйсызмы?

– Халык шагыйре булырга теләүчеләр күбәеп китте, көчәнеп халык шагыйре булырга йөриләр. Алар халык шагыйренең кем икәнлеген белми, дан артыннан кумакчылар, югыйсә, ул исемнең дә дәрәҗәсе күптән төште. Җәмгыять хәзер икенче. Бүген флейтада уйный торган заман түгел, чаң суга торган, кешеләрне уята торган вакыт җитте. Шагыйрь үзенә күрә таң әтәче булырга тиеш. Ул халыкта ватандашлык хисе уятырга тиеш. Гаделлекне күрсәтергә, дөресен әйтергә тиеш, шигырьнең көче шунда. Үз сүзен әйтә торган язучылар бик сирәк туа. Салтыков-Щедриннар вакыты яңадан кайтты, «История одного города» бүген дә кабатлана, Угрюм-Бурчеевлар терелеп чыктылар, алар йөгәнне кулга алып, халыкны көтү куган кебек куалар.

– Сатира-юморның торышын ничек бәялисез?

– Сатира-юмор бергә култыклашып йөри, шуңа аерым фикер белдермим. «Һәнәк» журналы шаулап тора иде. Тиражы да зур – 60 меңнән артык иде. Шуннан уйлап кара – көче бармы, юкмы? Анда чыккан тәнкыйтьне бүген түрәләр бар дип тә белми. Бүген сатира-юмор журналлары бетүгә барса да, ул драматургиядә яши ала. Эстрадада көлкеле монологлар, скетчлар кирәк. Бүген сатира-юмор шул рәвешле яши ала дип уйлыйм.

– Кешедә картая-картая маразм башлана. Сездә яшь барса да, юмор хисе сүрелми. Шуның сәбәбен беләсе иде.

– Юмор – ул балалыктан килә. Юморга өйрәтеп тә, аңа укытып та булмый. Ул акыл зирәклеге җимеше. Акылың зирәк булса – юмор бар. Сөйләшкәндә үк ул үзеннән-үзе туа. Мәсәлән, бер заман партия җыелышында Башкортстандагы сатира торышын тикшерделәр. Тимер Арслан анда урысча чыгыш ясады. Тәнәфескә чыккач: «Мин сине моңа кадәр Тимер Арслан дип йөрсәм, син Тимер Урыслан булып чыктың бит», – дидем. Ул шуңа бик нык үпкәләде. Икенче бер чыгышында аңа: «Әдәбиятта классик булмаса да, сатирада көләссик булды», – дигәч, аның үпкәсе бетте.

Яшьлек – сатира-юморга бай вакыт. Бу жанрда эшләү өчен күңел байлыгы, зирәклек кирәк. Мин кеше өчен иҗат иттем. Фельетоннарны күп яздым. Укучылар фактик материал бирә, мин шуннан фельетон эшлим. Аларны хикәя кебек укып була. Мин аларны 15ләп псевдоним белән чыгардым. Бәлки тел, каләм чарлау өчен алар файдага булгандыр? Тукай бар гомерен иҗатка биргән. Бүген алай тамак туйдырып булмый.

Соңгы чордагы язганнарым әллә басыла, әллә юк. Чөнки алар редакторларны куркытырдай шигырьләр. Аларда урам җыеннарына чыгучыларны тукмау, үз фикерен белдергәннәрне эзәрлекләү кебек темалар күтәрелгән. Андый әсәрләрне газета-журналлар басмый. Заман үтеп, дөньялар үзгәргәч, аларның да ташка басылыр вакыты килер. Ләкин әдәбиятның көче үз вакытында басылуында. Югыйсә, туй узгач дөмберә дигәндәй. Шигырьнең көче – кирәк вакытта яңгырау, кеше күңеленә керү.

– Туган телдә язу гына милләткә хезмәт итү була аламы?

– Юк, эш телдә генә түгел, ә фикердә. Телне, милләтне саклауда шагыйрьләрнең урыны бик чамалы. Сәбәпләре – куркудан. Тәнкыйть белдергән, үз фикерләрен әйткән кешеләр чит илләргә чыгып китәргә мәҗбүр, аларны төрмәләргә утырталар. Газета-журналларда да төп цензор – курку.

– 100дән соң теш чыга диләр.

– Әйе, шул чакларны күрергә иде. Миңа сатира язу өчен теш бик кирәк. Иң хөртие – күз күрмәү. Бер күзгә операция ясаттым. Ләкин барыбер бик укып булмый. Күз үткәннәрне әйбәт күрә. Хәзергесе, киләчәге караңгы.

– Бәлки бүгенгене күрмәү хәерледер?

– Язучы Әмир Әминевкә очраган идем. «Хәлләр ничек?» – дип сорый. «Күз күрми, колак ишетми», – димен. «Әйбәт булган, әйбәт булган», – ди. «Нигә алай дисең?» – дип сорыйм. «Барыбер ишетеп шатланырлык, күреп куанырлык бернәрсә дә юк», – дип җавап бирде.

– Киләчәк караңгы дисәк тә, тоннель башында ут бардыр әле?

– Шәм яктылыгы булса да, күренсен иде дә ул...

– Үкенечләр бармы?

– Үкенечләр күп булды. Язылмаган вакытлар – әрәм булган вакытлар. Сәләт ташып торганда аны файдаланып калырга кирәк. Агач гел чәчәктә генә утырмый бит, бер көн ул коела. Чәчәк аткан чакта язып калырга кирәк.

– Гомерегезнең кайсы чакларын сагынасыз?

– Балачакны сагынам. Ач, ялангач чакларны. Мин мәктәпкә йөргәнче үк укырга өйрәндем. Мәктәп янында комда уйнап утырганда укытучылар мине чакыртып алып 3-4 сыйныф укучылары алдына чыгарып бастыралар иде. Чөнки анда иҗекләп кенә укучы балалар бар. «Хәзер укырга төшмәгән баланы тыңлап карагыз», – дип миннән укыталар. Мин тыныш билгеләренә дә карамыйча пулемет кебек сиптерәм. Тыныш билгесендә туктасам, бу белми туктап тора дип уйларлар дип куркам.

Без гаиләдә «Коммуна» (әлеге «Кызыл таң»), «Правда», «Учительская газета» һәм башка газета-журналлар алдырдык. Әти Казанда, Уфада чыккан китаплар алып кайта иде. Ике телдә дә укып үстем. 7 нче сыйныфтан соң Оренбург өлкәсендәге татар-башкорт педучилищесына укырга киттек. 80 чакрым җәяү йөрибез. Икенче елны Зилаердагы рус педучилищесына күчтек. Мин анда тәүге диктантта ук «берле» алдым. Стипендия бирмәделәр. Чөнки сүзләр аңлашылып бетми. Берничә айдан миңа да стипендия бирә башладылар. Ярты елдан инде «бишле»гә яза башладым, Зилаер кызлары күчерү өчен минем янга күчеп утыра иде.

– Киләчәк буынга нәрсә әйтер идегез?

– Киләчәк буын без күргәннәрне күрмәсен. Без күргәннәр дә җиткән. Без әллә ничә буын күрәсен күрдек. Кардан тау башлары ачылгач, көтү көттем. Җәй балтырган, какы, юа, җиләк җыеп узды. Янәшәдә генә Сүрән, Ямашлы елгалары ага. Кармак белән балык тотып кайта идем. Элек балык күп иде. Хәзер химия балыкны бетерде. Сирәк кенә ятьмә белән тотабыз, сөзгән саен бер чиләк балык чыга. 13 яшемдә Сүрәндә сплавта – агач агызу эшендә йөрдем. Кишәрлекләр бүлеп бирделәр. Миңа начары – борылышлы урын эләкте. Берзаман агачлар килеп тыгылды. Агачлар 2-3 чакрым агудан туктады. Мин тамырга эләккән агачны багор белән чак-чак кузгатып җибәрдем. Бар агачлар дәррәү кузгалып китте, мин суга егылып төштем. Минем өстән бер-берсенә тиеп агачлар үтә, чыгарга араларында ачыклык та юк. Тегеләй карыйм, болай карыйм, беттем дигәндә арада яктылык күреп, шуннан килеп чыктым. Чыккач ярда бер сәгать хәл җыеп утырдым. Шулай үлемнән калдым. Безгә ул эш өчен хезмәт хакына камбала балыгы бирәләр иде. Андый яньчек балыкны элек күргән юк иде. Бергә эшләүче Әхәт дигән дусның: «Моның яртысын бригадир кисеп алып калган бит», – дигәне истә.

Тагын бер вакыйга. Район үзәгендә эшләгәндә авылга кайтасы килә. Бер кызга гашыйк та булып йөргән чак. Шимбә кайтып киттем. Февраль ае, төн уртасы. Исәнгол һәм Тазлар авылы арасында бер урын бар. Карыйм, бер карачкы утыра. Якынлашкач карасам – бүре! Кире борылсам, арттан ташланыр дип уйлыйм. Чеховның «Крыжовник» дигән хикәясен укыган идем. Анда берәү бүренең теленнән тотып ала. Мин дә моның телен тотарга кулымны әзерләдем. Узып киттем, ул әз генә кузгалгандай булды да, урынында калды. Үтеп киттем дә, арт белән алга барам. 100 метр узгач аяклар ташка әйләнде, атлый алмый башладым. Кулларым белән берәм-берәм аякларны тотып атлатам, шуннан әкрен генә язылып киттеләр. Бүре утырып калды.

ПОШАМАН

Бүген күктә йолдыз җиле уйный,
Яңа гына туган Ай йөри.
Шул нур балкышларын йолкый-йолкый,
Котырына шайтан өере.

Күңелләрне талкый шушы мизгел,
Иләс-миләс итә шушы мәл.
Уйларымда шуңа тынгылык юк,
Шуңа күрә рухым – пошаман!

Йолдызлары бар иде бит әле,
Моңсу, әмма Ае бар иде.
Әнә инде – җанга җылы җитми,
Урамнарда – салкын кар иле!

Көрт астында ята җылы кырлар,
Чәчәкләр дә көйгән, боеккан.
Иделләр дә дулкынланмый инде,
Дәрьялар да шактый саеккан!..

Җиргә төшеп, адәмнәрнең
Җаннарына кагыла!..

Кылкаләм буйый да буйый
Күргәнне, күрәсене...
Нигәдер сагышлы чыга
Татарның бу рәсеме.

Рәссам эшенә бар дөнья
Багып тора тын гына.
Тел дә юк, дин дә юк монда,
Монда тоташ моң гына...

Әйе, язмышның сурәте –
Бер тоташ яра сыман.
Шул рәсем өскә калкына
Дәверләр арасыннан!

...Буяуларны чәчрәтеп,
Заман җилләре исте.
Әллә кылкаләме тузган,
Әллә төсләре иске?

ТАРИХ

Мин татарча елыйм икән, дуслар,
Мыштым гына елыйм, елый калсам...
Мин барыбер татар, "Туган тел"не
Җырлаганда үксеп елый алсам.

Мин татардыр – әнә җаным елый,
Күз яшьләре аша көлгән булам.
Мәңгелеккә килгәнемне тоеп,
Туасымны белеп... үлгән булам.

Мин көлгәндә елыйм, елаганда
Шашып көләм!..
Минем ТАРИХ шундый.
Иң кискен бер мәлдә, яшьне сөртеп:
"Син – чын татар!" – диеп УЛ пышылдый.

* * *

Алтатар, мылтыгым да юк,
Юк минем кылычым да.

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ

Хаталардан торган бу гомерне Акка күчерәсе бар кебек...

Их, табигать матурлыгын җырлап
Йөрер идем,
Борчу – шыг(ы)рым!..
Берни эшли алмыйм, – үксез телем,
Денем хакында бу шигырем...

КАРАЛАМА ГОМЕР

Шундый тойгы: бу яшәлгән гомер –
Караламасы күк тормышның.
Сизеп яшим: дөнья тоныклана,
Җете төсе кими карашның.

Алдагысы – кинәт гашыйк булган,
Әмма сөелмәгән яр кебек.
Хаталардан торган бу гомерне
Акка күчерәсе бар кебек.

Курыкмыйча, шикләнмичә яшим, –
Бу – соңгысы түгел гомернең.
Яңасына күчкән чакта, хәтта
Кабер ташларымны үбәрмен...

Яңа гомер яши башлармын күк,
Бәхет булып алсу таң атса...
Тик... нишләрмен икән, карашларым
Якты көннең төсен онытса?..

ТӨНГЕ ТУЛГАК

Төн. Күңелем офыкларын
Нindидер уй актара.
Галәме дә тап-тар калган,
Төсләре дә кап-кара...

Нindидер татлы уй йөри,
Әллә газаплы уймы?
Әле Кояшны эзләнә,
Әле сагына Айны.

Нинди уй ул – әйтә алмыйм,
Серле дә, сихерле дә...
Акылы – йөз яшьлек карттай,
Үз яше – егермедә!

Нindидер өр-яңа фикер,
Моңарчы булмаган уй.
Бәхеткә дә ирешмәгән,
Гөнаһ та кылмаган уй...

Шул уйдан мәгънә табарга
Тырышам, булдыралмыйм...
Тулгак тоткан бу төнә дә
Таңны һич тудыралмый...

КОШ ОЧА

Бер кош оча, оча-оча...
Болытларга тиеп оча.
"Кайсын сайлыйм: Җирнеме соң,
Күкнеме соң?" – диеп оча.

Шатланамы, әрниме ул,
Киереп канат каккан саен.
Әрнеп югалтадыр Җирне,
Сөенәдер, тапкан саен.

Әллә Күккә, әллә Җиргә
Бер егылыр кебек бу кош?
Сандугачмы, тургаймы ул,
Әллә ялгыз, ятим байгыш?..

Җаным шулай талпынамы?
Әллә... Ходай ишарәсе?
Күпме гомер кичелгән дә,
Күпме калган кичерәсе?..

Әллә бу кош – яшьлегемдә
Табылмаган сөюемме?
Чакырыйммы яннарыма:
"Соң булса да сөй!" – диимме?

Оча бер кош, оча-оча...
Күңелемне таң калдырып...
Хыялымның офыгында
Җан яндырып, кан тамдырып...

Күпме очар икән бу кош,
Бер югалып, бер табылып?
Яшьлегем күк, китәр микән
Болытларга бер тагылып?..

Сизәм дә соң... бер көн аны
Җилләр егып төшерәсен...
Тик... аныңчы... бар әле, бар
Озын гомер кичерәсем.

РӘССАМ

Язмыш язам, каләм манып,
Милләтем ярасына...
Нинди генә төс алсам да,
Рәсемем кара чыга.

Рәсемем кара чыга шул,
Язмышым авыр чыга...
Кулымдагы кылкаләм дә
Ярсына, тыпырчына!..

Нишләргә белми, очына,
Болытларга тагыла.

ДУСЛАР КИТӘ

Бер-бер артлы дуслар китеп бара,
Хушлашмыйча гына китәләр.
"Кадеребезне белдегезме?" – диеп,
Әрвахлары җавап көтәдер.

Әйтәлмичә кала җылы сүзләр,
Кылынмыйча кала изгелек.
Хисләр, уйлар кала, ятим булып,
Йөрәк-бәгырьләрне өзгәләп...

Бер-бер артлы дуслар китеп бара,
Һич туктатып булмый үзләрен.
Күңелләр дә куып җитә алмый,
Җитә алмый җылы сүзләрем...

Бер-бер артлы дуслар китеп бара,
Хәтеребездә генә калалар.
Тоныкланып кала күңел күге,
Ерагая бара аралар.

Бер-бер артлы дуслар китеп бара,
Күңелемдә барыбер тереләр.
Газизләре, якыннары гына
Хәтер буйлап кайтып йөриләр...

БАШКАЧА

Бала чакта күргәннәрне
Башкача күрәм бугай.
Яктырак яна Кояш та,
Моңсурак карый бу Ай!

Башкача чәчәк ата күк
Бакчада үскән сирень...
Ничекләр генә белергә
Шушы "башка"ның серен?

Башкача моңлана кылган
Мең еллык таныш кырда.
Башкача ага елгабыз,
Бүтән көй таныш ярда.

Урманы да башкачарак –
Тып-тын калган шикелле.
Кызлары чибәр, чибәр... Тик
Башкачарак сөйкемле...

Кая киткәндер ямь-яшел
Чык ерып йөргән диңгез?
...Әйтәсе генә килми,
Без бит
Үзебез үзгәргәнбез!..

Дошманнарым да юк минем,
Ә дөнья... кыл очында.

Кече итәм кечеләрне,
Олылыйм олысын да.
Йөрәгем дөньяга ачык,
Ә дөнья... кыл очында.

Дога укып, сәҗдә кылам,
Башкарам йоласын да.
Күңелдә изгелек кенә,
Ә дөнья... кыл очында.

Сөюем гомерлек, бәхтем?.. –
Менә ул – кул очында.
Бәхеткә җитәр идем дә,
Дөньясы... кыл очында.

Бәгырьгә алдым халкымның
Бар үксез баласын да.
Милләт юлын язмыш иттем,
Дөнья бит кыл очында!

Бөтен борчу – йөрәгемдә,
Бар дөнья – колачымда.
Барысы да әйбәт булыр, –
Гомерем... кыл очында.

ЧЫГЫП КЕРДЕМ

Эчтән йозак элеп, тәрәзәдән
Чыгып киттем гүя... Шундый халәт.
Барып кердем дөнья урамына,
Анда бары рәнҗеш, хөсет, әләк.

Кояшы да шул ук, күкләре дә,
Кошлары да элеккечә сайрый.
Яшәү хакын хаклап, бурычларны
Кат-кат түлим, заман тагын сорый...

Дөньялыкта, ай-һай, тыныч түгел,
Яшәү өчен ризык табу авыр.
Барган саен авырая күңел,
Ач, ялангач йөрәк кенә сабыр...

Һәрбер хискә язмыш белән түлим,
Бәхет хакы ачы сагыш икән.
Яшәү гүя бер шаукымлы уен,
Кешелекнең гаме табыш икән!

Кай арада юшкын катты тәнгә,
Ташлап калдырасы ничек йөкне?!
Керле җанны куеныма кысып,
Өйгә кереп киттем. Ишек бикле!..

Сәйдәш һәм биш

Салих Сәйдәшев музее 2016 елдан ишекләрен япты. Биредә Сәйдәш яшәгән, шушы ишегалдына чыгып, театр ягына озаклап моңсуланып карап торган. Тинчурин театры белән тоташкан флигель, аның зур булмаган диварлары әле дә Сәйдәш рухын, моңын сагына кебек. Монда ул иҗат иткән, монда аның тормышында иң сөенечле мизгелләре булган…

Бик күпне хәтерли бу флигель, теле булса, без белмәгән әллә никадәр серне чишеп бирер иде. Ачылып бетмәгән серләрне белер өчен, музей җитәкчесе Эльвира Низаметдинова белән сөйләштек.

– Эльвира ханым, музей мөдире һәм музыка белгече буларак, Сез Сәйдәш турында күпне сөйли аласыз. Истәлекләрдә аның диңгез кебек зәңгәрсу һәм уйчан күзләре, бөдрә чәчләре, йомшак һәм тыныч манерасы турында язалар. Сезнеңчә, Сәйдәш тагын нинди булган?

– Салих абый теләсә кайсы кеше белән исәнләшкән. Хәтта балалар белән дә. Кесәсендә нәниләр өчен һәрчак конфитләр йөрткән, ул аларны сыйларга яраткан. Үзенең бөек булганын белсә дә, беркайчан да үзен югары куймаган. «Минем носкиларым тишек бит әле», – дип борчылып йөрмәгән. «Өйдә ашарга юк», – дип тә уйламаган, баш-аягы белән эшкә чумган. Көне-төне эшләп йөрүне төп бурычы дип санаган.

Тормыш авырлыклары булуга карамастан, күтәренке кәефтә йөрергә тырышкан, мәзәкләр сөйләргә яраткан, шәхес буларак гаҗәеп акыл иясе булган. Кемнән генә сорама, барысы да аның турында: «Матур һәм зыялы, артыгы белән намуслы һәм саф күңелле кеше иде», – дип искә ала. Хатын-кызлар аңа үлеп гашыйк булган. Репрессия чорында иҗатташ дуслары атып үтерелгәч, өендә кунмаган, ышанычлы дусларында кунып йөргән. Аннары Бөек Ватан сугышы башланган, шуңа күрә дә исән калгандыр ул.

– Иҗат кешеләренең үзенә күрә бер сәерлекләре була…

– Бер сәерлеге дә булмаган. Гади иҗат кешесе. Талант аңа Аллаһы Тәгаләдән бирелгән.

– Татар халкында җыр дәвамында басып, кул чабып торган бер генә композиция бар – «Совет Армиясе маршы». Ләкин шулкадәр хөрмәткә лаек булган әсәрнең авторын җитәкчеләр дә, түрәләр дә яратып бетермәгән. Нигә?

– Сәйдәш, даһи булуына карамастан, тыйнак холыклы була. Кайбер кеше: «Миңа исем, дәрәҗә, җылы кәнәфи бирегез», – дип тигәнәк кебек соранып йөри. Хәтта гаделсезлек белән 1948 елда Татар дәүләт академик театрыннан азат ителгәннән соң да, гаделлек барыбер калкып чыгар дип, чын күңеле белән ышанып яши ул.

Аннан соң ул «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем алган, дини рухта тәрбияләнгән. Бернинди партиягә дә кермәгән, ә бу совет заманында җитди рәвештә хокук бозу дигәнне аңлата. Партиясез икәнсең, димәк, син партиягә каршы. Композиторлар берлеге рәисе Нәҗип Җиһанов та аны күп мәртәбә партиягә керү өчен гариза язарга үгетләп карый. «Ул-бу була калса, мин сине яклый алмаячакмын», – ди. Сәйдәш партиягә керүне дини кануннардан ваз кичү дип кабул итә, алай гына да түгел, өйдә дингә ышанган ике әби – үз әнисе Мәхүбҗамал Сәйдәшева һәм җизнәсе Шиһап Әхмәровның әнисе Зөләйха Әхмәрова яшәгән.

– Дини рухта тәрбияләнгән, дидегез. Алай да хатынлыкка рус кызы Валентинаны сайлый. Алар никах укытканмы?

– Валентина Мухина – Әхмәровлар гаиләсендә еш кунак. Җизнәсе Шиһап Әхмәровның улы Үзбәк белән рус теле һәм математикадан репетиторлык белән шөгыльләнә ул. Аннан тыш, Валя пианинода да бик яхшы уйный. Кыз бик зыялы гаиләдән. Яшьләр бер-берсен ихластан ярата. Ул аның фикердәше, якын дусты була. Берзаман болар икесе дә юкка чыга – композитор Мансур Мозаффаровның дачасына киткән булалар. Аннан соң ЗАГСта язылышалар. Бу 1925 ел. Аңлашыла, ул аның белән никах укытмый. Югалып торганнан соң өйгә бергә кайтып кергәч, яшьләргә каршы килмиләр.

Моның бер сәбәбе дә була: Казахстаннан Бернияз дигән хәрби кеше Шиһап Әхмәровның бертуган сеңлесе Зәйнәпнең кулын сорый. Ул башка диндә булу сәбәпле, туганнар каршы чыга. Шуннан соң Бернияз үзен дә, Зәйнәпне дә атып үтерә. Валентинага каршы чыксалар, Сәйдәш тә берәр нәрсә майтарыр, дип курка алар. Бер елдан соң Валентина бала таба – улларына Альфред дип исем кушалар. Ләкин бала тапканнан соң бер атна үткәч, каны зарарланып, Валя гүр иясе була.

«Валя үзенең үлеме белән бөтен гомеремне харап итте», – дип әйткән булган Салих абый. Валентина үлеменнән соң башка аны композитор буларак кадерли, хөрмәтли торган (Кабалевский, Рахманинов хатыннары кебек иҗатларын бөртекләп җыеп баручы) якын кешесе булмый.

– Алай да, Әмирхан ага Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе» повестенда язылганча, Сәйдәшнең беренче мәхәббәте Фатыймаи-Зөһрә булган. Кыз әти-әнисе каргышыннан курыкмаса, Сәйдәшнең биографиясе бөтенләй үзгә булыр иде. Сез шулай санамыйсызмы?

– Фатыймаи-Зөһрә аның укучысы гына булган, Сәйдәшев аңа үлеп китеп гашыйк булмаган, алар арасында мәхәббәт булмаган дип уйлыйм. Әйе, Сәйдәш аңа үзе белән бергә китәргә тәкъдим иткән. Фатыймаи-Зөһрә өеннән качып, соңрак (Сәйдәш теләгәнчә) артистка булса, бәлки бергә булырлар иде. Мәхәббәт өчен бернинди киртә дә юк.

Сәйдәшев – яшь, мәһабәт гәүдәле егет. Үзен гади тоткан, йомшак сөйләшкән. 18 яшьлек егет 16 яшьлек кызны фортепианода уйнарга өйрәтү дәресләре генә биргән, шул чорда ул Шәрык клубына йөри башлый, җаны-тәне белән иҗатка бирелеп эшләгән. Баштан азмы-күпме фортепианода уйный белгән Фатыймаи-Зөһрәнең сәләтен күреп алган, ә инде киләчәктә аны артистка булырга өндәгән. Кыз чынлап торып Салих Сәйдәшевне ярата, ул бөтен әйберен ташлап, Сәйдәш белән качып китәр иде.

Сәйдәшкә бөтен хатын-кыз гашыйк булган, диләр. Матур егет өенә килеп дәресләр биргәч, ничек аңа сокланып карамыйсың, ди? Дини тәрбия алган, әти-әнисе каты торган Фатыймаи-Зөһрәнең, тәрәзәсеннән карап утырудан тыш, Сәйдәштән башка егет күргәне булмагандыр. Бу мәхәббәт түгел, бу гашыйк булу гына дип саныйм. Сәйдәшнең исә зур мәхәббәте – беренче хатыны Валентина Мухина. 1926 елда Валя үлгәннән соң ул 1929 елга кадәр өйләнми. Йөрәк ярасын басар өчен эшкә чума, музыка белән генә шөгыльләнә.

– Икенче хатыны – София Альняева белән 1929 елда өйләнешкәннәр. Уртак балалары булуга карамастан, София белән аерылышкан. Сәбәп нидә?

– Икенче хатыны Ветеринария институтын тәмамлый, базарда ветеринар табиб булып эшли (бу эш акчалы дип саналган). Соңрак ул театрга кассир булып урнаша. София Альняева – үз-үзен генә карап йөргән, актрисалардан бер дә ким булмаган, табигатьтән матур хатын-кыз. Ул кара-көрән төлке мехыннан тегелгән тун киеп йөргән, диләр.

● Эльвира Низаметдинова.

Әлбәттә, ул да үлеп Сәйдәшкә гашыйк булган. Әмма беркем дә (якыннарыннан кала) Сәйдәшнең көне-төне музыка язып, өч тиенлек хезмәт хакы алып яшәгәнен чамаламагандыр шул. Ә София ханым үз дәрәҗәсен белгән: матур булгач, матур киенәсе, бизәнәсе килгән. Гомумән, ул яхшы шартларда яшәргә ияләшкән. Сәйдәшкә кияүгә чыгып, дан һәм акча өстендә йөзәчәкмен дип уйлаган… Нинди акча? Ул бит гонорар өчен эшләмәгән. Кайчак хезмәт хакын да алырга оныткан. Бөтен җирдән куылгач, 3 сумлык гонорарын түләмичә, радиокомитеттан да куып чыгарганнар.

София белән Салихның өч балалары туа: Нәүфәл, Реләф, Эмиль. Реләф Мәскәү елгасында батып үлә. Төпчек баласы Эмиль музыкага бик сәләтле малай булган, диләр. Хәзерге Боратынский музее бинасында урнашкан беренче музыка мәктәбенең авырлык белән ачыла торган ишегенә башы белән бәрелеп, баш мие тышчалары ялкынсынып, вафат була. Шул ишеккә зур озын пружина беркетелгән булган. Хәтерлим, аны балалар көчкә ачып керә иде.

Көннәрдән бер көнне өйгә кайтып керешкә Сәйдәш хатынының башка бер артист белән чуалганын күреп ала. Бу ачы хыянәтне авыр кичерә ул. Аерылышканнан соң, София шул артистка кияүгә чыга. Алай гына да түгел, фатир алганчы барыр урыннары булмаганлыктан, Сәйдәш аларга күршедәге бүлмәдә яшәргә урын бирә.

Ә Салих беркайчан да бер бармагы белән дә хыянәт иткән хатынына, аның яңа иренә орынмый, бер сүз әйтми. Гадәттәгечә, күргән саен «Исәнмесез» дип исәнләшә торган була. Аларны мөмкин кадәр сирәк күрер өчен дусларында кунып йөри. София балаларын алып китә. Сәйдәш янә ялгызы кала…

– Өченче хатынына иптәш булсын дип өйләнгәндер инде…

– Асия Казакова – танылган сәүдәгәрләр Апанаев-Йосыповлар нәселеннән. Аларның җирләрен тартып алган булганнар. Асия ханым да Сәйдәшевнең данына кызыгып, 1949 елда аңа кияүгә чыга. Сәйдәшкә иң яхшы пәлтә һәм пианиноны нәкъ менә ул сатып алып бирә. Сәйдәш күбесенчә театрдагы фортепианода уйнаган, кайвакыт пианиноны арендага да алган булган. Хатыны буларак, ашарга пешереп ашаткандыр, керләрен югандыр… Кияүгә чыгып, бергә тормыш итә башлагач, шулай ук байлыкта йөзмәячәген аңлаган.

Салих Сәйдәшевкә Мәскәүдә яман шештән операция ясагач, дүрт көн аның янында саклап торганнан соң, бишенче көнне яныннан кунакханәгә кунарга китеп барган. Шул төнне Сәйдәш үзе генә торып чыкмакчы булган. Тирә-яктагы кешеләрне борчымыйм дип, ярдәм сорамаган һәм ахыр чиктә егылган. Операциядән калган төзәлеп бетмәгән яра ачылган һәм күп итеп кан аккан. Аны коткарып кала алмаганнар. Хатыны Сәйдәшне өзелеп яратса, аның яныннан кайтып китәр идеме? Шикләнәм.

– Эльвира ханым, халыкта таралган имеш-мимешләр бик күп бит ул. Имеш, эчкән, тәмәке тарткан…

– Тәмәкене күп тарткан. Берсе миңа килеп, Сәйдәшнең киртә артында эчеп үлгәнен исбатларга тырышты. Зинһар, бу сүзләрне беркемгә дә сөйләмәгез дип үтендем. Халык нигәдер аны күп эчәргә яраткан дип әйтә иде. Кешеләрнең фантазияләренә шаккатам.

Израильгә күченгән бер Казан режиссерының әнисе Кекин йортында буфетта эшләгән. Аның сөйләүләре буенча, Сәйдәш буфетка кереп, ашап чыга торган булган. Өендә ул, гаиләгә ашарга калсын дип, аз тукланган. Ашаганнан соң кешедән калган рюмканы иреннәренә китереп, бераз гына иснәп алырга гадәтләнгән. Кырыйдан карап торган кешеләр моны эчә дип уйлаган. Хезмәт хакы түләнмәгән композитор ничек эчеп йөри алсын?

Туганнары сөйләве буенча, Сәйдәшне бер тапкыр да исерек килеш күрмәгәннәр. Ә аның турында теләсә нәрсә сөйләп йөргәннәр. Димәк, һавадан алган имеш-мимешләрне чыгарып яту кем өчендер файдалы булган.

елга сузылган ремонт

– XVII–XVIII гасырларда яшәгән Бах кадәр Бахның да кульъязмалары сакланып калган. Моннан өч ел элек Ренат Еникеевның Сәйдәш мирасы турында ачынып сөйләгәне хәтердә калган. Мирасы турында ниләр билгеле?

– Сәйдәшев мирасы мәсьәләсе бик четерекле. Ул 600дән артык әсәр язган. Бүгенге көндә 200гә якын әсәре генә билгеле. Колхоз, партиягә багышлап язылган спектакльләр дә булган, сүз юк. Мәсәлән, «Кандыр буе» спектакле. Аны беркайчан да куймаячаклар, чөнки спектакль татар авылларының электрофикациясе турында. Ул актуальлеген югалтты. Татар авылларына интернет керде, дип кенә үзгәртсәләр инде. Ләкин музыка бар, ул яши.

Башка очраклар тагын да аянычрак: пьесаны төшереп калдырып, пьесага атап язылган нота кәгазьләрен дә чүплеккә ташлаганнар. Ноталы җыентыкларны Казанда 1950 елларда гына нәшер итә башлаганнар дип беләм, аңа кадәр партитураларны барысын да кулдан язганнар. Сәйдәшев язып биргән кәгазьләр дә спектакль барганда кулланылган, ә аннан соң аны җыеп бармаганнар. Кем ташлаган, кем югалткан...

Аның кульъязмалы ноталарында селедка балыгы куеп кискәннәр, теләсә нәрсәне сөрткәннәр… Кыскасы, көндәлек кирәк-яракларга кулланганнар. Шуңа күрә дә әсәрләре, караламалары сакланып калмаган. Кайбер кульъязмалары консерватория сандыгында аунап яткан дип тә әйтәләр иде.

Ренат Еникеев Салих Сәйдәшевнең мирасына битараф калмады, күп тырышты. Радиокомитетка рәхмәт, алар безне үзләренә чакырды. Музей хезмәткәрләре Сәйдәшнең билгеле булмаган кульъязмаларын тапты. «Бишбүләк» операсының беренче пәрдәсе ноталарын тулаем таптылар. Ул ноталарны беркем белми иде. «Зәңгәр шәл» спектакленең төрле вариантларын ачыкладык. Нәшер ителмичә калган әсәрләрнең өзекләре һ.б. килеп чыкты. Моннан тыш, Салих Сәйдәшев оркестрында скрипкада уйнаган музыкант Мөхәммәт Яушевның Сәйдәш әсәрләрен күчереп алган ноталарын таптык. Ул – Сәйдәш әсәрләрен басма ноталар белән күчерә барган бердәнбер музыкант. Аннан кала, бездә Сәйдәшевнең барлык фотографияләре диярлек саклана. Үзе исән чагында ясалган, аның автографы куелган бердәнбер портреты бар.

Хәзер без архив өстендә эшлибез, Сәйдәшнең фәнни биографиясен әзерләячәкбез. Мәсәлән, аның Үзбәкстанның Китаб һәм Каттакурган шәһәрләре театрында баш режиссер булып эшләве ачыкланды. Ул җәйләрен шунда барып эшли торган булган. Тинчурин актерлары театрга барып кергәч, Сәйдәшнең зур портретын күреп шаккаткан. Бу безнең композитор бит дигәч, юк, ул безнең театрның режиссеры иде, дип аңлаталар. Менә шундый фактлар да бар.

Ул аның якыннары язып калдырган истәлекләрдән чыгып туплана. Без эзлеклелекне саклап, вакыйгаларны көнен-көнгә (хәтта сәгатен-сәгатькә) язарга тырышачакбыз. Туганнан алып, вафатына кадәр. Аны тәртипкә салып, бизәлешен генә ясыйсы калды. Нәшер дә итәрбез дип уйлыйм. Ул композиторның бердәнбер фәнни биографиясе булачак.

– Мирасына шундый мөнәсәбәт булгач, үзенә дә елмаеп тормаганнар дигән караш туа.

– 1940 елларда Салих Сәйдәшевне һөнәри яраксызлыгы, консерватория белеме булмавы һәм симфония, кантаталар яза белмәве өчен Татарстан Композиторлар берлегеннән чыгаралар. Шул заманда композиторлар берлеге әгъзалары белән төшкән фотога карыйм да, бер белмәгән-ишетмәгән фамилияләр килеп чыга… Музыка белгече булсам да, аларның язган әсәрләрен ишеткән юк, ә алар Сәйдәшне берлектән чыгарып ата. Нәрсә бу? Алар кайда йөргән? Әсәрләре кайда яңгырый?

Салих Сәйдәшев татар халкында хор оештыра. Ул татар музыкасына берничә тавышка уйнау һәм җырлауны кертеп җибәрә. Һәр уен коралы үзенең партиясен уйный башлый. Музыка яңа төсмер ала, байый, чөнки Сәйдәшев көнбатыш Европа мотивлары үрнәкләрендә белем ала. Жорж Бизеның «Кармен» әсәре – аның иң яраткан операсы була.

Сәйдәш музыкаль драма жанрына нигез салган, ә хәзер аның ачышы белән бөтен дөнья кинематографиясе куллана. Шунысы парадокс – музыкаль драма жанры хәзерге вакытта юк. Моның өчен композитор, драматург һәм режиссер бергәлектә, тыгыз тандемда эшләргә тиеш. Репрессияләргә кадәр Сәйдәшев Кәрим Тинчурин белән дус була, Тинчурин – драматург та, режиссер да. Алар икәү бер дулкында иҗат белән кайнаша. Татарстанда барлыкка килгән жанрны Татарстанда ук күмеп тә куйдылар.

Тагын шунысы аяныч – заманнан калышмыйбыз дип тамырларыбызны онытабыз. Пятницкий исемендәге хор, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле беркая да юкка чыкмады. Алар элекке традицияләрне саклый. Ни өчендер театр моннан читә башлады. Пәрдә ачылгач, сәхнәдә матур татар авылы өе, бакчасы торыр иде, карап туймаслык кызык иде ул декорацияләр. Хәзер нәрсә? Пәрдә ачыла – ике табурет, бер өстәл тора. Бернәрсә аңлашылмый… Шушы әйбер музейларга да кагыла.

– «Сәйдәш. Йокысызлык» спектаклен кабул итмәүчеләр булды.

– Спектакль белән мин бик яхшы таныш, Луиза Янсуар безнең музейда башын да күтәрмичә сценарий язды. Луиза фәнни биографиягә нигезләнеп эшләде. Мин аңа Сәйдәшев турында башка беркем дә белмәгән фактларны сөйләдем. Ул Сәйдәш тормышы белән рухланды. Театр яңа дәрәҗәгә күтәрелде – яңа жанрга чыкты һәм төп нөсхәне саклап калды.

Спектакль беткәннән соң «Ярый әле алдан экскурсия оештырдыгыз, аңлашылмас иде», – диючеләр булды. Кемдер экскурсиянең татар һәм рус телләрендә булуыннан канәгать калмады. Спектакль С.Сәйдәшев тууына 120 ел тулуга багышланган иде, ул репертуарда тора алмый.

Начар спектакль булса, игътибар да итмәсләр иде, ә болай ул игътибар үзәгендә булды. Мактаганнары да, яманлап сүгүчеләр дә булды. Халык бәхәсләшә икән, димәк, бу яхшы! Яхшы спектакльне күбрәк аңлыйсы, кабат-кабат карыйсы килеп тора.

«Зәңгәр шәл» спектакле – моның ачык мисалы. Ул бара да бара, анда уйнамаган артист калмагандыр. Мәйсәрәне уйнаган актриса өлкәнәя төшкәч, ишанның хатынын уйный һ.б. Буыннар алмашы бара.

● Икенче хатыны Сафия Альняева, уллары Нәүфәл һәм Эмиль белән.

Музейда да зәңгәр шәлләрне экспонат буларак куеп чыгарга уйлыйбыз. Залдан залга шәл дә үзгәрә: зурая, калыная… Бу буын алмашын күрсәтер иде.

– Салих Сәйдәшевнең туганнары белән мөнәсәбәтегез ничек?

– Без аларны чакыргалап торабыз. Килгәне килә инде, ләкин без аларның музейга ремонт ясалган вакытта килүләрен теләгән идек. Хәзер ремонт тәмамланмаган вакытта да килеп күрсеннәр иде, әмма килеп караучы юк.

– Үпкәләмәгәннәрдер бит?

– Нәрсәгә үпкәләп була? Алар өчен һәрчак ишек ачык. Теләсә кайчан кабул итәргә әзербез. Сәбәбен белмим. Мөмкинлегегез бар икән, килегез, карагыз, фикерләрегезне җиткерегез дип торам, экспозициягә бирелмичә калган тагын шәхси әйберләре бардыр, дим. Узган ел Сәйдәшев яшәгән бүлмәнең планын ясадык, быел беренче залны ясап чыгарга ниятлибез. Туганнарына бәлки ни дә булса ошамас? – дип сөйләде музей җитәкчесе.

Шәхсән үземә Сәйдәшев яшәгән йортта йөрү дулкынландыргыч та, гаҗәп тә булды. 1857 елда төзелгән бинаның әлегәчә сакланып калуы гаҗәп, ә Салих абыйның биредә торуын, дуслары, гаиләсе белән кич утыруларын, фортепианода уйнавын күз алдына китерәм дә, дулкынланам. Их, бер генә секундка алар яшәгән чорны күреп булса икән! Салих абыйның импровизацияләп уйнап утыруын карап, ләззәткә күмелеп тыңлап утырсаң икән ул!

Ә хәзер йорт, дөресрәге, музей бинасы буш тора, ремонттан соң күп нәрсә үзгәргән: идәнгә берничә кат җәелгән паркет куптарылып алынган, аның өстенә такталар җәелгән. Сәйдәш бүлмәсен Советлар Союзында чыккан чәчәкле обойлар белән ябыштырганнар, берничә бүлмәдә эленеп торган лампаларны калдырганнар, бүлмәнең бер өлешендә шушы бинадан табылган, революциягә кадәрге керамик плитка җәйгәннәр.

Гипсокартонны алуга һәр бүлмәнең киңлеге 70 сантиметрга киңәйгән. Черегән идән такталарын алып, ике катның да идәнен ныгыткач, бинаның биеклеге 30 сантиметрга түбәнәйгән. Килеп керүгә кунакларны вокзал декорациясе фонында «Совет Армиясе маршы» каршы алачак. Халык тынлы һәм кыллы уен коралларын аерым залларда карап чыга торган була дип күзаллыйлар.

Музейның беренче катында сул якта аерым затлы бер бүлмә бар – ул очрашулар, күргәзмәләр өчен ясалган. Бүлмә ремонтка кадәргесеннән нык аерыла – искесендә ут кабызсаң да тонык, караңгы кебек иде, чыгыш ясаучылар өчен акустика юк диярлек.

Хәзер рәхәтләнеп, микрофонсыз, көчәнмичә җырларга була. Бүлмәнең бер башында баскан кеше бер сүз әйтсә дә, ул икенче башка аермачык ишетелә. Эльвира ханым аңлатуынча, акустика дивардагы гипсокартонны алып, идәндәге ламинатны сүтеп, аның урынына паркет җәю нисбәтеннән һәм түшәмнең урта җирен күтәрүдән барлыкка килгән. Зал 50 кешегә исәпләнгән. Идән төсендә витрина кую планлаштырыла.

Эльвира ханым 150 мең сумлык электропианино тапкан. «Бәлкем, ул кем өчендер тиен генәдер инде, шуны музейга алыр өчен иганәче эзли ул. «Таба алмасам, акча бүлеп бирелгәнне көтәчәкбез», – диде җитәкче.

…Кыскасы, музейга килеп керүгә син вакыт машинасына утырып, 1950 еллардагы сәнгать әһелләре коммуналкасына кире әйләнеп кайткандай буласың. Галия Кайбицкая, Марсель Сәлимҗанов, Рада Нигъмәтуллина, Шәүкәт Биктимеров, Ринат Таҗетдинов һ.б. сәнгать кешеләре монда яшәгән.

Ремонт әлегә 80 процентка төгәлләнгән. Кимчелекләргә килсәк, икенче каттагы ак ишекләрдә инде ярыклар ачылып килә – яңадан буярга вакыт җиткән. Бинага кергәндә касса өчен аерым бүлмә ясалмаган. Декорацияләр кую, дивар бизәү эшләре һәм, ниһаять, экспонатларны урнаштырасы калган.

Эльвира ханым ремонт барышын үзе контрольдә тоткан, музейдагы һәр детальне энә күзе аша үткәргән, үзе сайлап, үзе төзәттереп йөргән кеше буларак, без күрмәгән тагын әллә күпме вак-төяк эшләрне белә. Ничек кенә аяныч яңгырамасын, музейга яңадан ремонт ясарга кирәк булмагае…

Музей кайчан ачылыр?

Ярар, музейны ничек бар, шулай калган килеш тә, экспонатларын тезеп чыгып, бер төс кертеп булыр иде. Ләкин алты елга сузылган ремонт кайчан да булса төгәлләнергә тиештер бит? Эльвира ханымнан музей ачылу өчен нәрсә комачаулаганы турында сораштым.

– Барысы да акчадан тора. Витриналарны сатып алу, музеефикация өчен дә аерым акча бүленергә тиеш иде… Ярты техниканы өемнән алып килдем. Акча гына бирегез, барысы да була, дим.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

intertat.tatar

Рауль МИРХӘЙДӘРОВ

Спрут заманы

Артур Александрович Шубарин инде сигезенче аен Германиянең Мюнхен шәһәрендә заманча банк хезмәтен өйрәнә иде. Аның Германияне сайлап алуы очраклы түгел. Мәктәптә ул немец телен, ә институтта инглиз телен өйрәнгән, һәр ике телдә дә әйбәт кенә сөйләшә, ләкин болар төп сәбәп түгел иде. Кайчандыр ул, прокурор һәлак булганга кадәр, Азларханов белән икътисади хәлләр турында сөйләшеп утыргач, алар безнең илгә теләсә нинди финанс һәм кредит системасы ярамас, хәтта алга киткән илләрдәге алымысуллар да нәтиҗә бирмәскә мөмкин, Россия белән элек-электән географик, тарихи, икътисади, сәяси, мәдәни бәйләнешлары, үзара аралашып үрелгән гореф-гадәтләре булган илләрнең тәҗрибәләрен алырга кирәк, дигән фикергә килгән иде. Шубарин карашынча, бу җәһәттән иң уңай илләр Европада, шул ук вакытта ул Америка, гаҗәеп Япониядә Азия илләрен дә исәптән бөтенләй сызып ташламый, ләкин банк хезмәте, валюта эшләре нигезенә бары тик Европага хас система гына салынырга тиеш дип саный.

Европада Россиянең күп кенә илләр белән меңләгән бәйләнешлары бар, әйтик, иң әүвәл Франция белән. Әмма Шубарин Германиягә барырга карар кылды, чөнки ул аңлый: немецләрнең ике ягы бергә кушылгач, Европада гаять зур мөмкинлекләре булган яңа дәүләт барлыкка килде. Якын елларда әнә шул яңа Германиянең икътисади көч-куәте Япониясен дә, Американы да дөнья базарыннан кысрыклап чыгаруы мөмкин. Европада моны иң беренче булып инглизләр үз җилкәләрендә татый башлады, аңысы инде исәпкә алынырга тиешле тарихи чынбарлык. Америкага һәм бөтен Европа илләренә шулкадәр озак каршы тора алган безнең дәүләтебезнең дә, күпләрнең гаҗәпләнүенә каршы, коялы бик тиз баеды бит.

Тевтон рыцарьлары заманыннан бирле Россия белән Германия күп тапкыр сугышкан булса да, аларны шактый нәрсә берләштерә, хәтта хакимиятне үз кулларында тоткан Габсбурглар һәм Романовлар династияләре дә берничә гасыр буена үзара туганлашып яшәгән, ә Екатерина II (Әби патша) заманыннан башлап немецләрне Россиягә төпләнеп яшәргә чакыра торган булган, хәзер дә илдә алар ике миллионнан артык. Соңгы елларда үзләренең тарихи ватаннарына кайтып китү бик көчәйсә дә, алар әле Россиядә күзгә күренерлек милләт. Германиягә банк хезмәтен өйрәнергә киткәндә Шубарин моңысын да искә алган иде. «Туганлыкны белмәгән Иван» әйтеме бары тик русларда гына, башка телләрдә аңа охшаш әйтемне эзләп табып булмастыр. Ә Германиядә исә Россиядә яшәүче милләттәшләрен беркайчан да онытмаганнар һәм онытмыйлар.

Үзенең шәхси банкын ачарга ниятләгән Шубарин башта ук аның Германия белән ныклы элемтәдә булуына йөз тотты. Казахстан, Кыргызстан, Үзбәкстан җирләрендә укмашып яшәгән немецләр арасында да үз банкының филиаллары булыр дип өметләнә иде. Аннары алар аша немец эшмәкәрләрен һәм банкирларын турыдан-туры җәлеп итеп, үз ватандашларына шушында ук төрле предприятиеләр, зур булмаган, әмма бик файдалы заводлар төзергә ярдәм итсәләр, Россиядән Германиягә күчеп китү дә тукталыр иде. Бу мәсьәлә бит һәр ике ил өчен дә четерекле булып кала бирә. Шубарин Германиядә бу җәһәттән үзенә фикердәшләр тапты.

Әле теге «торгынлык» дип яманаты чыккан елларда ук Шубарин Көнбатышта еш була иде, аның дус-ишләреннән кемнеңдер бер сүз әйтүе дә җитә – барлык ишекләр дә ачыла иде. Шуңа күрә дә ул һәрвакыт кайтып-китеп йөри алды. Ул заманда бит бер генә нәрсәдән куркалар – теге кемсә, чыгып китеп, кайтмый калмагае, янәсе. Ә Артур Александрович Шубарин өчен курыкмаска була, аны Көнбатышта бернәрсә белән дә кызыктырып калдыра алмыйсың. Барып, күреп, өйрәнеп кайту – ярый торган эш, ә шунда калып яшәү – урыс җанлы Шубарин кабул итә торган гамәл түгел иде.

Үзгәртеп коруның беренче, буталчык елларында ул, теләсә, башкалардан күп алда үзенең байлыгын чит илгә күчереп өлгергән булыр иде, әмма ул моны да эшләмәде. Аның компаньоннарыннан күпләр әле җитмешенче елларда ук Көнбатышка китеп барды, әмма, баесалар да, үзләре янында финанс даһие Шубарин булмауны юксыналар иде. Аларга аның эчке сиземе, тимердәй нык кулы, искитәрлек инженерлык белеме җитмәде. Алар аңа уртак эшләр тәкъдим итеп карады, янәсе, Японец (аны үзара шулай атап йөртәләр иде), байлыгын саклап һәм ишәйтеп, алар ягына чыга алыр иде. Хәзер Көнбатышта гөрләшеп яшәп ятучыларның байтагы Шубаринга бурычлы: кемнәрдер аның тирәсендә «ипигә май ягып» яшәде, икенчеләренә ул йә акча белән, йә киңәшләре белән, ешрак һәр икесе белән дә ярдәм итеп килде. Ә кемнәрнедер, үзенең дус-ишләре ярдәмендә, үлемнән дә йолып калды – шуны онытырга мөмкинме соң? Аның Германиядә иканлегене ишетеп-белеп алгач, әле үзләренең рус гореф-гадәтләрен югалтып бетермәгән бу кемсәләр аның янына Мюнхенга да еш килеп йөри башлады. Ял көннәренең бик сирәген генә Мюнхенда үткәрә башлады ул: дуслары килә, йә Германиягә, йә Швейцариягә, йә Австриягә утыртып алып та китә.

Аңа банк курсларында укуны оештырган фирма Шубаринга укырга йөри торган җиреннән ерак та түгел бер әйбәт районнан җиһазландырылган фатир да алып бирде, ул шуннан чиста-пөхтә бакча-парк аша гына укырга йөри иде. Ләкин бүген ул дәрәҗәле Кайзерштрассе урамындагы биш йолдызлы «Рица» отеленә өч кенә көнгә күченеп торды. Мюнхенның «Бавария» футбол командасы уенын карарга һәм аның белән көрешергә дип, күптәнге дусты, инде унөч ел АКШта яшәүче Мәскәү грузины Гвидо Лежава (хәзер – мистер Лежава) киләсе иде. Дөрес, Лежава Америкадан түгел, ә Португалиядән килә, анда аның үз шөгыле бар, Лиссабон тирәсендә диңгез буендагы атаклы Эшториаль комлыгына якын гына, шәп йорт сатып алган. Лиссабонны да ул сәер генә итеп Лизбон дип атый. Көнбатышта да Гвидоның күптәнге мавыгуы үлмәгән – ул футбол ярата, үзе Тбилиси «Динамо»сы белән Мюнхен «Бавария»се өчен янакөя икән. Бу юлы да ул «Бавария» белән Португалиянең «Бенфика» клублары арасында Европа чемпионнары кубогына финал уенын карарга килгән, ә яраткан клубы уенчылары янына үз өенә кайтып кергән кебек кереп йөри. Гвидо «Рица» отелендәге шәп ике номер өчен дә, футбол уенын карау өчен иң шәп урыннар кулдан меңәр доллар торса да, аларын да үзе түләп алган.

Мюнхенда элекке танышлары булгач, Артур Александрович акчага аптырамый, курсташлары һәм банк җитәкчеләре карашынча, бик иркен-мул яши иде. Ул, өстәмә түләп, ике бүлмәле фатирын өч бүлмәлегә алмаштыручы бердәнбер кеше булды – иркенлекне ярата торган күптәнге гадәте җинде. Килеп бер атна үтүгә, актан-ак «Мерседес» сатып алды, еш кына Франкфуртка опера, Штутгартка балет карарга йөри башлады. Аны инде Мюнхен эшмәкәрләре ябык клубларга да бер генә чакырмады, үзләре атаклы Бавария банкына тәҗрибә тупларга килгән бу рус баен игътибар белән күзәтә-өйрәнә иде.

Көнбатыш эшмәкәрләре гадәтле бу рус бае, чит илдә дә бик тиз үзләшеп, ышаныч һәм хөрмәт казана башлады. Аңа соңгы вакытларда киңәш сорап бик дәрәҗәле кешеләр килә, андый кешеләр белән танышу җаен башкалар еллар буе көтә, ә болар аны үзләре кунактан-кунакка дәшеп кенә тора – бергә сәяхәтнең иң зур уңышы да шунда, ә бит ул үзе бергә килергә кыенсынып кына җыенган иде. Кайвакытларда Шубарин: «Көнбатыш эшмәкәрләре өчен Россия базары буенча киңәшләр бирүче генә булсам да, күптән баеп беткән булыр идем инде», – дип уйлый. Әмма Россия өчен дә кояшлы көннәр килер әле, анда да үзенең тәҗрибәсе һәм белеме кирәк булыр, дип ышана.

Ул «Рица» отеленә, Гвидо килеп җитәргә берничә сәгать калганда ук, үз «Мерседесе»ндә җилдереп килеп туктаган иде инде. Бирелдә менә дигән бассейн һәм массаж бүлмәләре барын белә, инде икенче атна теннис кортына да бара алмый, рәхәтләнеп йөзәргә дә җай юк – көннәре бик тыгыз булды шул. Үз исемен әйтеп, сигезенче каттагы бүлмә ачкычларын алгач, хезмәтче аңа тагын бер жетон калай тоттырды да:

– Сезнең өчен отельдә һәр җиргә юл ачык, моны мистер Лежава эшләде, шушыны гына күрсәтегез. «Рица»да ял өчен һәммәсе дә бар, вакытыгызны күңелле үткәрегез, – диде.

Йөзеп туйгач, бераз саунада да утырып, массажчыда һәм чәчтараштта булганнан соң, ул үз бүлмәләренә кайтты. Ташкент һәм Мәскәү белән сөйләшеп алмакчы иде дә, өлгермәде – телефон шылтырады, трубкада Гвидо Лежава тавышы иде.

– Исәнме, Артур. Мин Германиядә инде, аэропорттан шылтыратам. Биредән «Рица»га кадәр бер сәгатьлек юл, әмма бүген барлык юллар да дыңгычланган, мин моны һавадан ук күреп килдем. Немецләр стадионга, мөселманнар кәгъбәгә ашыккандай, ашыга. Әйе, «Бенфика»га бүген авырга киләчәк.

– Ярар, егетләр сынатмас дип ышанам, – диде Шубарин.

– Аска төшеп, итальян ресторанын эзләп тап, ул уң канатта булыр. Русча итеп яхшы кабымлыклар, туклыклы ашлар белән өстәл әзерләт, ә андагы эчемлекләр безнең грузиннарныкы кебек, син аларны аера беләсең, хәтерлим әле... Сине бик сагындым, төнге сөйләшеп утыруларны, мәҗлесләрне... Биредә бөтенләй башкача яшиләр, өч мәртәбә миллионер булсаң да, аларга күнегә алмыйсың... – дип сүзен сүрән генә бетерде ул.

Атаклы «Бавария» футбол клубы стадионына алар гадәттәгедән озаграк барды, юкса Шубарин шәһәрне дә яхшы белә иде. Мюнхен урамнарында тоташ машиналар агымы, монда кайлардан гына, нинди генә машиналар юк: итальян, француз, грек, төрек... Бары тик безнең ил машиналары гына күренми, бездә хәзер футбол кайгысы түгел шул. Болар, машиналарны шактый еракта калдырып, халык ташкыны арасында җәяү генә әле тагын ярты сәгатьләп барды һәм уен башлануга гына килеп өлгерде.

Уен бик киеренке, каты булды, беренче унбиш минутта ук арбитр һәр ике яктан да берәр уенчыны куып чыгарды, ләкин уенның кызуы сүрелмәде, мәйдан хуҗаларының өстенлеге сизелсә дә, беренче таймның исәбе тигез – 1:1 булды.

(Дәвамы бар).

Себернең иманлы сәүдәгәрләре

Татар халкы революциягә кадәр исемнәрен халыкка ишеттергән сәүдәгәрләре белән хаклы горурлана ала. Алар Россиянең барлык төбәкләрендә бар. Әйтик, Казанда - Апанаев һәм Кәримовлар, Екатеринбургта – бертуган Агафуровлар, Иркутскида – Шәфигуллиннар, Троицкида – Яушевлар, Себернең Тара шәһәрендә – Айтыкиннар һ.б. Күптән түгел Бөтендөнья татар конгрессы төбәкчеләр оешмасының Омски өлкәсендә «Себер, Идел-Урал һәм Евразиянең башка төбәкләрендә урнашкан шәһәрләрнең татар бистәләре һәм авыллары халкы бердәмлегенең төп нигезе, милли мәдәниятне һәм заманча икътисадны саклап калу һәм үстерү. Үткәннәр, бүгенгебез һәм үсеш перспективалары» дигән темага үткәргән гыйльми җыенында булып, Тара шәһәрен дә күрергә туры килде. Фәнни-гамәли конференциядә Айтыкиннарның оныгы Роза Нурмөхәммәт кызы Әхмәдиева (әнисе Айтыкиннар кызы була) белән танышып аралашу бәхете эләкте.

● Роза Әхмәдиева.

● **Абдулфәттах Айтыкин (сулда) Тубыл сәүдәгәрләре Мөхәммәд Сафар һәм Тохтасын Аймөхәммәтов белән.**

Октябрь инкыйлабына кадәр Тара шәһәрендә Айтыкиннар иң хөрмәткә ия, дәрәҗәле кешеләрдән санала. Алар үзләренең чыгышын Көнбатыш Себердә ислам диненә беренче өндәүчеләреннән булган, Тарада Бохара бистәсен нигезләгән Дин-Али хаҗи Ярымовтан башлап исәпли. Күчем ханның гаскәре Искер янында Көнбатыш Себер ханлыгын тар-мар иткәннән соң, Дин-Али хаҗи Ярымов 1594 елда Тара шәһәреннән берничә дистә чакрым ераклыктагы Сәет (Хуҗавыл) авылына күченә. Аның уллары һәм оныклары Себердә, ислам динен тарату белән бергә, сәүдә итүне дә җәелдереп җибәрә. Айтыкиннарның сәүдәгәрлек эшчәнлеге XVIII йөзнең икенче яртысында аеруча югары үсеш ала. Алар бу вакытта Кытай белән алыш-биреш итә башлый. Айтыкиннар Кояш чыгышы иленнән фарфор һәм фаянс савыт-саба, ефәк һәм йон тукымалар, чәй алып кайта торган була.

Дин-Али хаҗи Ярымовның XIX гасырда яшәгән оныклары – Тара сәүдәгәрләре – Нияз белән Кармышак 1827-1828 елларда Омскидан Кокандка туры юл ача. Нәселнең дүрт абый-агасы арасында Нияз исемлесенең сәүдәгәрлектә аеруча уңышка ирешүе теркәлеп калган. Ләкин аның матди хәле бу вакытта җәмгатьчелек арасында бик үк әһәмияткә ия булмый әле. Әмма Айтыкиннар XIX гасыр уртасында зур дәрәҗәләргә ирешә. Аларның дәвамчылары исә Кяхта, Верный, Павлодар, Семипалатинск калаларында сату иткәннәр, «Ирбит пароходчылыгы»нда исәпләнгәннәр, «Работник» һәм «Тара» дигән пароходлары булган, Ирбиттан Томскига кадәр кышкы юл ачканнар. Ниязның бер улы Насретдин фарсы, гарәп, немец, француз, инглиз телләрен белгән, китаплар җыйган, Мәккәгә хаҗ кылырга барган, Мәдинә шәһәрендә дә булган, алдынгы житештерү предприятиеләренең эше белән танышып, тәҗрибәләрен өйрәнгән. Ниязның дүртенче улы Абдулфәттах XIX гасыр уртасында Тарада күн остаханәсен бар итә, 1852 елда анда өч мең тире иләнә. 1870 бу остаханә күн заводы итеп үстерелә. Озакламый Айтыкиннар постау фабрикасы һәм пыяла заводын да төзеп өлгертә. 1886 елда Рәхмәтулла Нияз улы Айтыкин Тараның берничә сәүдәгәре белән бергә Төмәннән 53 чакрым ераклыктагы Успение авылында язу кәгазе (писчебумажный) фабрикасын эшләтеп җибәрә. Соңрак төбәкнең Төмән, Екатеринбург, Томск, Иркутск кебек зур шәһәрләрендә складлар челтәре дә җәйга салына.

1856 елда сәнәгатьне үстерүдәге хезмәтләре, дәүләт заказын үтәүләре – хәрби ведомстволы армия солдатларына шинель һәм аяк киеме тегү өчен постау (сукно) һәм күн белән тәэмин иткәннәре өчен, Ниязның уллары Абдулфәттах, Насретдин һәм Рәхмәтулла нәселләренә Мактаулы гражданнар исеме бирелә. Рәхмәтулла Айтыкин 1 нче гильдия сәүдәгәре дәрәҗәсенә ирешә. Бертуган Рәхмәтулла һәм Насретдин Айтыкиннарга патша тарафыннан көмеш медальләр тапшырыла. Өченче туганнары Нәҗметдин орденга ия була.

Айтыкиннар төбәкнең рухи һәм мәдәни тормышында да тирән эз калдырган. Айтыкиннар ярдәме белән Иртыш буендагы татар авылларында мәчетләр салына, XVIII йөзнең беренче чирегендә халык үтенече белән Көнбатыш Себердә беренче таш мәчет төзелә. Берничә дистә елдан соң Тарада һәм якын-тирә авылларда яшәүче татарлар һәм бохаралылар өчен яңача белем бирә торган мәктәп һәм мәдрәсә ачыла. Айтыкиннар тырышлыгы белән шулай ук шәһәрдә китапханә булдырыла һәм ипподром көйләнә. Чөнки Тара сәүдәгәрләренең ул елларда Төмән, Тубыл, Омски шәһәрләрендә яшәүчеләрнекенә караганда атлары шактый күп була, аларны ипподромнарда узыштыралар.

Россиядәге 1917 елгы инкыйлаб сәүдәгәрләрнең эшчәнлеген дә юкка чыгара. Шул ук вакытта флот, пристаньнар, судноларны төзәтү предприятиеләре дә дәүләтнекенә әверелә, хәтта Айтыкиннарның атаклы чабышкылары да армия өчен конфискацияләнә. Пыяла һәм постау заводларында җитештерелгән товарлар хәрби максатларга тотылганлыктан, алар Совет хакимияте вәкилләре җитәкчелегендә эшләвен дәвам итә. Айтыкиннарның затлы йортлары барлык ярдәмче корылмалары белән тартып алына, анда татар балалары өчен элекке мәдрәсә күчenә, аның XX гасырның 70 нче елларына кадәр эшләве мәгълүм. Нәтиҗәдә Айтыкиннар мал-мөлкәтсез кешеләр булып кала. Әмма бу елларда Тарада әле Айтыкиннар шәҗәрәсенең берничә тармагы яшәве мәгълүм. Алар мөселманнар җәмгыяте, мәдрәсә һәм мәчет өчен җаваплы була.

Айтыкиннарның күбесе инкыйлабтан соң тиз генә Урта Азия якларына күченеп киткән. Чөнки аларның Павлодарда һәм Семипалатинскида сәүдә йортлары булган, Верный, Бохара, Коканд шәһәрләрендә дә вәкиллекләрен тотканнар.

Бүгенге көндә Айтыкиннарның XIX гасырда салынган ике катлы йорты исән, әмма ул, мәдәни мирас объекты итеп теркәлгән булуына карамастан, череп, җимерелеп бара. Аның беренче каттагы тәрәзәләре такталар белән кадакланган. Шәһәр сазлыклы урында урнашканлыктан, бинаны язларын су баса. Шуңа күрә дер идәннәре дә кубарып атылган. Йортны шәһәрнең 425 еллык юбилеена әзерләнгән вакытта да ремонтлау турында уйлап карамаганнар. Кайчандыр Россия Армиясенә кием-салым өчен постау һәм күн, кирәк-яраклары пыяла җитештергән, патша хөкүмәте тарафыннан зурланган Айтыкиннарга өлкәнең шундый мөнәсәбәтен һич кенә дә аңлап булмый. Бәлки төбәкне өйрәнүче тарихчылар килгәч, уңайсызланырлар дигән уй да юкка чыкты. Форумда Омски өлкәсенең Тара районы башлыгы Евгений Лысаков чыгышыннан соң җирле хакимият йортны яңарту чараларын күрә башлар дигән өметкә урын калмады.

Е.Лысаков үз чыгышында Тара татарларын иң борчыган мәсьәләне – Айтыкиннар йортын төзекләндерү кирәклеген дә телгә алды, әмма болай дип өстәде: «В Таре много памятников археологии и архитектуры, относящихся к татарской культуре. Многие десятилетия эти историческое и культурное наследие не изучалось, не сохранялось, не продвигалось. И сейчас пришло время обратить внимание самим представителям татарской диаспоры на сохранение, реконструкцию, поддержанию памятников археологии и архитектуры, восстановлению культурных ценностей и традиций».

Тарада яшәп калучы Айтыкиннар да хәтсез булган. Репрессияләрдән исән калганнарының бер өлеше Бөек Ватан сугышыннан әйләнеп кайтмаган.

(Дәвамы 23 нче биттә).

● **Айтыкиннар төзеткән мәчет.**

● **Тарада Айтыкиннар йорты.**

Мәдәни җомга
11 февраль
№5, 2022

Тарих җанлы

Пенза каласында яшәүче рәссам Илдар Акъегетне тарихи темаларга алынган кылкаләм остасы буларак хөрмәт итәбез. Хәер, аның иҗатында пейзажлар да, натюрмортлар да күп. Илдар Акъегет – җәмәгатьчелеккә яхшы таныш рәссам, тарихчы, язучы Кадир Акъегет улы.

● «Париждагы намаз. 1812 ел» («Мәдинә» нәшрият йорты тупланмасыннан).

“Әтием Кадир Акъегет – Пенза сынлы сәнгать училищесын тәмамлаган рәссам, 1990 елларда Пензадагы “Якташлар” җәмгыятенә нигез салучы. Аңа Казанга да еш барырга туры килә иде, – дип искә алды сүз башында әңгәмәдәшем. – Әйтик, 1992 елда Бөтендөнья татарлары конгрессының I корылтаенда катнашты. Пенза татарлары тарихын өйрәнеп, китаплар да нәшер итте һәм әлегәчә дизайнерлык һөнәрендә.

Мин 1984 елда Пензада тудым. Биш-алты яшемнән әтием остаханәсенә барып йөрдем. Ул төсле фломастерлар, кәгазь битләре бирә, мин аларга машина сурәтләре сызгалап ташлый идем. Билгеле, балалар бакчасындагы традицион: “Үскәч кем булачаксың?” дигән сорауга да җавабым әзер иде: “Рәссам булам!” Бу теләгемә әнием Рәшидә дә каршы килмәде”.

Футбол уйнарга яратса да, Илдар гомерлек һөнәре итеп рәссамлыкны сайлый. Ул татар телендә камил сөйләшә, Пензада татарлар бик аз булуына сыкрана. “Әти-әнием минем белән гел татарча сөйләште. Ана телемне беләм, яратам. Бер кыз үстерәбез, Ләйсән дә татар телен белеп үсә!” – ди. Илдар сынлы сәнгать мәктәбен, аннары 2004 елда Пенза сынлы сәнгать училищесын тәмамлый. Бу училище рәссам Г.К.Савицкий исемен йөртә, аның ачылуына инде 123 ел, борынгы, бай тарихлы уку йорты атмосферасын Илдар әле дә хәтерли. Соңыннан ул югары белем алу өчен Мәскәүгә юнәлә. Әле ректор И.С.Глазунов исән чакта белем ала. Ә бу рәссам – рус милләте тарихын алгы планга куючы шәхесләрнең берсе. “Илья Глазунов үз милләтенең патриоты булса да, мин рус темасын сурәтләүгә алынмадым. Тарихи-дини тематиканы, портретлар язуны үз итмичә, пейзаж ясау остаханәсенә юнәлдем, анда өч ел буе өйрәндем. Бу академиянең искиткеч китапханәсе әле дә исемдә, минем күп сәгатьләрем шунда китаплар укып үтте”. Мәскәү – төрле колачлы мәдәни чаралар үтә торган үзәк. Башкалада сәнгать эшлеклеләренә булышлык итә торган фондлар, оешмалар да җитәрлек. Илдарның студент еллары да бихисап мәдәни чараларда, бәйге, күргәзмәләрдә катнашу белән үрелеп бара. Мондый активлык зур нәтиҗәләргә дә китерә. Илдарның 2010 елгы диплом эше – “Архангельская утары” игътибар җәлеп итә. “Бу теманы мәшһүр байлар – Йосыповлар династиясе белән бәйле булганы өчен сайладым, – ди иҗатчы. – Диплом язу өчен бер ел вакыт бирелде. Шуңа күрә бу мохиттә еш булдым, күп эскизлар ясадым. Мин үзем рәссам С.Ю.Жуковский иҗатына мөкиббән. Әлеге оста башкалардан үз техникасы белән дә аерыла һәм ул шул гасырның минор күңел халәтен исәпкә алып яза белгән... Ә бу, Көмеш эпохага хас халәт миңа да якын. Төрле парклар табигатен, борынгы утарлар рухын язуны ошатам...”

2004 елны Илдар Пензаның үзе укыган “Гармония” балалар сәнгать мәктәбендә беренче шәхси күргәзмәсен ача, балаларга акварель сәнгате буенча осталык дәресе дә үткәрә. Аннары инде ул катнашкан күргәзмәләр саны елдан-ел арта бара: 2007 елда “Россия шәһәрләре” күргәзмәсе кысаларында аның картиналары – Мәскәү, Лондон, Копенгагенда, 2008 елда “Россия образы” кысаларында Мәскәү һәм Лондонда экспозицияләнә. 2008 елны Санкт-Петербург меценаты В.Карцев инициативасы буенча оештырылган күргәзмәдә дә катнашып, “Культурное достояние” фондының яшь рәссамнарга тәгаенләнгән грантына, I дәрәҗәдәге дипломга лаек була. 2009 елны әлеге оешма аны сынлы сәнгатьтәге уңышлары өчен фондның алтын билгесе белән зурлый. В.Карцев рәссамнарга булышлык йөзеннән биш мең картина сатып алган. Илдар язган пейзаж да шул әсәрләр рәтенә кергән. “Шул ук елда Парижга бардым, Черногориягә сәяхәт иттем. 2009 елда исә “Помощь отечественному искусству” мәрхәмәт фонды оештырган күргәзмә-бәйгедә эшләрем янә Мәскәүдә һәм Лондонда күрсәтелде. Черногориядәге V Халыкара пленэрда булдым. Италия каласы Лоретода узган “Молодая российская культура в регионе Марке” фестивалена чакырылдым. Аннары инде төрле калаларда оештырылган күмәк күргәзмәләргә дә үз өлешемне керттем. 2012 елны картиналарым белән Венециядә үткән “Молодая российская культура в Италии” фестивалендә, Саранскида узган “Зур Идел”дә катнаштым. 2012 елда Россия Рәссамнар берлегенә кабул ителдем. Канны шәһәрендә үткәрелә торган VIII һәм X Яшьләрнең рус мәдәнияте фестивалена дә чакырылдым. 2013 елда Тарквиниядә узган шул ук фестивальдә дә булдым. 2017 елда Мәскәү оештырган “Гаилә – Россия җаны” бәйгесендә җиңдем”, – дип саный оста. Боларга өстәп, Илдарның картиналары 2018 елны И.Тургеневның тууына 200 ел тулу уңаеннан Берлин, Люксембург, Брюссель, Страсбург, Париж, Баден-Бадендагы гомуми күргәзмәдә булуларын, 2019 елны Пенза өлкәсе Федераль куркынычсызлык хезмәте идарәсендә шәхси күргәзмәсе ачылуын да искәртик. Илдар “И.С.Тургенев тууына 200 ел” истәлек медаленә, Пенза губернаторының Рәхмәт хатына лаек булган. Рәссам кайбер шәхси күргәзмәләрен Пенза китапханәләрендә дә ачырга өлгергән. Аның тагын бер уңышы – 2018 елны галим Бәшир Искәндәр улы Рәмиевнең тууына 100 ел тулу уңаеннан оештырылган портрет бәйгесендә тамашачылар мәхәббәте призын яулавы.

● «Соңгы очрашу».

И.Акъегет иҗатындагы тарихи тематикадагы картиналарга аерым тукталырлык. Ул бу колачлы теманы бик яратып сурәтли. “Тарихи темаларга алынуым Пенза сынлы сәнгать училищесын, И.Глазунов академиясен тәмамлап, Татарстанда яшәп иҗат итүче рәссам Рөстәм Хуҗин тәкъдиме белән бәйле. Аның иҗади эшләрен, портретларын без укыган академиядә бар студентлар өчен үрнәк итеп күрсәтәләр иде. Рөстәм академияне 2002 елны ук тәмамлаган, аның белән мин соңрак таныштым. Ул: “Син дә татар тарихын сурәтлә, чөнки бу юнәлештә иҗат итүчеләр аз”, – диде. Шулай итеп 2016 елда “Ибн Фадлан илчелегенең Болгарга килүе. 922 ел” картинасын ясарга алындым. Картинам күп кенә гомуми һәм шәхси күргәзмәләргә эленде, мактаулы бәяләмәләргә дә лаек булды. Сезгә, татарстанлыларга, җиңел. Бар тарихи экспонатлар, тарихи китаплар янәшә. Пензада исә татар тарихы һәм мәдәнияте темасына туры килердәй экспонатларны табу авыр. Әйтик, татар милли кием-салымнарын бөртекләп җыям. Милләт – ул язмыш! Үз милләтемне бик яратам! Моңа минем әти-әнием биргән тәрбия дә йогынты ясады, билгеле.

2010 елда мин “Париждагы намаз. 1812 ел” картинасын ясый башладым. Игътибарымны янә тарих сәхифәләренә юнәлттем. Безгә бик мәгълүм булмаган тема бит бу. Ул елларда кызу канлы, батыр татар һәм башкортлар медальләргә дә лаек булган. Төрле милләт полклары арасында алар аерылып торган. Әлеге Ватан сугышында рус халкы гына кан койган дип сөйләү дөреслеккә хилафлык китерә, күп чыганакларда татар-башкорт ирләренең каһарманлыклары да искә алынган. Аларның хәтта матур

● «Ибн Фадлан илчелегенең Болгарга килүе. 922 ел».

Акъегет

● «Прованс урамы».

өс-башларын рәсемгә төшереп калырга да ашыкканнар. Әйтик, француз рәссамы Георг Эммануэль Опиц та үз литографияләрен шушы темага багышлаган. Бүген рәссамнарның күбесе аның рәсемнәренә дә таяна. Китап кибетендә актарына торгач, "Казаки в Париже" китабына да тап булдым. Татар солдатларының патриотик рухын күтәрү өчен җаваплы полк муллалары да булган. Картинама бик күп тырышлык салдым. Укытучым Павел Рыженко да бу теманы хуплады. Картинамның беренче вариантын Самара өлкәсе губернаторы сатып алды. Аның икенче вариантын ясадым. "Париждагы намаз. 1812 ел" картинасының икенчесе Мәскәүдәге "Мәдинә" нәшрият йортында саклана".

Илдарның тарихи темадагы тагын ике хезмәте –"Батый. 1237 ел" һәм "1312 елда Алтын Урдада, Наручат шәһәрендә ислам кабул итү" картиналары Мәскәү Ислам институты тупланмасында урын тапкан. 1312 елда Наручат шәһәрендә Үзбәк ханның ислам динен дәүләт дине буларак кабул итүен, Алтын Урда әләмендәге Батый йорты тамгасы янына ярымай сурәте өстәлүен тасвирлаган ул. 2021 елны Казахстанда, Нурсолтанда Алтын Урда оешуга 750 ел тулу уңаеннан нәшер ителгән "Алтын Урда" альбомына егерме дәүләт рәссамнары әсәрләре урнаштырылган һәм бу басмага эңгәмәдәшемнең "Батый. 1237 ел" картинасы репродукциясе дә кергән.

"Моннан кала әле 2008 елда иҗат иткән "Мөселманнар анты" дигән картинам да бар, – ди Илдар Кадир улы. – Бу эшкә I Бөтендөнья сугышы кинохроникасын караганнан соң керештем. Махсус китаплар укыдым. шуларның берсендә кайсыдыр полкның патшага ант бирүе тасвирланган. Ватанны сакларга, батыр булып сугышырга вәгъдә биргән алар... Ак эскәтер ябылган өстәлләр янына төрле дин әһелләре килеп баскан, алтынчы өстәл артында гына беркем дә булмаган. Бу сугышта катнашкан мәҗүсиләр дә үзләренә күрә ант биргән. Алтынчы өстәл – әнә шуларныкы. Ә андыйлар... нибары ике гренадер. Алар кесәләреннән агач сынчыклар чыгарган, аларны өстәлгә куйган, ант сүзләрен кабатлаган... Мөселманнар исә кулларына Коръән китабын алып ант иткән. I Бөтендөнья сугышында Россия армиясе составында яуга күтәрелгән мөселман сугышчылары саны – 1-1,5 миллион кеше... Бу канкойгыч, һичкемгә кирәкмәгән сугышта күпмеләре һәлак булган да, күпмеләре соңрак авырып, имгәнеп, гарипләнеп кайткан, аларының гомерләре дә озын булмагандыр. Бик кызганыч... Бабамның әтисе, Фәхрислам бабам да әлеге сугышта катнашып, күкрәгенә орден тагып кайткан. Аның шул вакыттагы фоторәсеме бабамнар өендә сакланган".

Илдар Акъегетнең Бөек Ватан сугышы темасына багышланган берничә хезмәте бар. Ватан өчен сугыш темасы аңа нәсел тарихы буенча да якын. "Бу сугышны сизгәннәр, билгеле, ләкин ул барыбер көтмәгәндә башланган... Минем бабам Муса 1941 елның 22 июнендә армиягә алынган. Әбием Сара шул вакытта йөкле булган, шуңа карамастан ире белән хушлашыр өчен, башкаларга ияргән, ат арбасына утырып, район үзәгенә – Каменкага киткән. Хушлашу өчен аларга нибары биш минут биргәннәр. Кире кайтканда, әбием борчак кырында икенче баласын таптап кан. Ике нарасый белән сугыш чоры михнәтләре аша узган. Бабам батырларча сугышып, яраланган. Кызыл Йолдыз орденына, "Батырлык өчен" һәм "Севастопольне алган өчен" һ.б. медальләргә лаек булган. Бөек Ватан явы аның өчен Белоруссиядә тәмамланган. Сугыш хакында ул миңа бик аз сөйли иде. Картиналарымның берсен килчәгебез хакына фашизм белән көрәшкән татар ир-атларына багышладым", – дип искә алды рәссам.

2019 елда Илдарга "Сәләт"нең Биләрдәге җәйге форумында катнашып, андагы балаларга осталык дәресләре бирергә туры килгән. "Анда ял иткән оланнарга картиналар ясау серләрен аңлаттым, алар белән пленэрларга да чыктым. Шәхси күргәзмәмне дә ошатып карадылар. Күргәзмәгә "Ибн Фадлан илчелегенең Болгарга килүе. 922 ел" әсәремне дә элдем. Гомумән, Татарстан Рәссамнар берлеге белән даими хезмәттәшлек итәм. Рәссам Мөдәррис Минһаҗев әйди торгач, 2019 елда "Шәһри Биләр" пленэрына барып, киндергә хан улын сурәтләдем, – диде рәссам. – "Шәһри Биләр" кысаларындагы эшем "Илһам хан балдагы"-дип аталды. Мин 1236 елны утыз меңлек монгол гаскәре Биләрне кырык ике көн камаганда, бу хәлнең хәерсез тәмамланачагын аңлаган Илһам хан улын үз янына чакыруы һәм аңа үз балдагын биреп, каладан чыгып китүен үтенүе хакында белдем. Аның улы берникадәр вакыттан соң калага әйләнеп кайткан һәм шул балдакны, бирегә тагын кайтыр өчен бер ырым буларак, коега ташлаган. Замана археологлары әлеге балдакны тапкан икән. Аны Биләр музеенда күреп була".

И. Акъегетнең тагын бер хезмәте "Ш.Мәрҗани һәм Х.Фәезханов" дип атала. Ике тарихи шәхесне янәшә сурәтләгән картина "Мәдинә" нәшрият йорты заказы буенча язылган. Безгә Ш.Мәрҗанинең фотосурәте буенча язылган күп портретлар таныш, ә бу эш – бераз үзгә. "Мин шуңа басым ясар идем, – диде Илдар. – Матбугатта мөгаллим, тарихчы, археолог, каллиграф Хөсәен Фәезхановның тормышы, аның эшчәнлеге азрак яктыртыла кебек... Шуңа күрә әлеге картинам булуына шатмын".

И.Акъегет 2020 ел ахырында этнодизайнер һәм рәссам-конструктор Илдар Гатауллинның "Millihasite" берләшмәсе тарафыннан әзерләнгән татар милли костюмнарындагы сылуларны – Мөнирә һәм Альбинаның сурәтләрен киндергә бик илһамланып төшергән. "Илдар Гатауллин белән Надежда Шәйхелисламованың 2020 елны Пензабызда татар автономиясе оештырган "Татар кызы – 2020" бәйгесе этабына килүе минем өчен зур шатлык булды! – ди ул. – Чөнки моңа кадәр борынгы татар милли киемен бирeдәге мәктәп музейлары аша гына әзли идем, тик алар анда бик аз. Бу оешма иҗат иткән борынгы татар милли костюмнары, зиннәтле һәм зәвыклы бизәнгечләр, баш киемнәре халкыбыз тарихын горурланырлык итеп күрсәтер дәрәҗәдә дип саныйм. Алар теләсә кайсы рәссамга илһам бирә ала. Әлеге эшләрем яңа, "Пенза җире халыклары" сериямне башларга этәргеч бирде. Ул халыклар дуслыгына, Пензада гомер итүче башка милләт вәкилләренең милли киемнәрен тасвирлауны күздә тота. Мин рус, чуаш, мордва-мокша, мордва-эрзя милли киемле хатын-кыз образларын ясадым".

2012 елдан башлап Илдар үзе укыган Г.К.Савицкий сынлы сәнгать училищесы студентларын рәсем ясау сәнгатенә, сынлы сәнгатькә, композициягә өйрәтә. "Уку йортыбызда эшләргә бик тели идем. Училищебыз һәрвакыт йөрәк түремдә булды. Alma-mater... тукландыручы ана бит! Эшемнән бик канәгатьмен. Хөрмәтле укытучыларым белән беррәттән гыйлем бирүем белән горурланам. Хәзерге студентлар без укыган еллардагыдан аерыла. Без укыганда кесә телефоннары, хәзерге кебек бай интернет юк иде, шуңа күрә рәссамлык буенча мәгълүматлар туплау әкрен барды. Хәзер бу нисбәттән алар бәхетле, чөнки уку процессына әзерлек гадиләште. Китаплар күп, ә безнең вакытта тәбрикнамә итеп нәшер ителгән картина күчермәләрен карап, рәссамнар иҗаты белән танышу бәхеткә тиң иде. Дүрт ел укыган шәкертләрем Мәскәүгә, Санкт-Петербургка юнәлә..."

Илдар пейзаж жанрына мөкиббән рәссам буларак, пленэрларга ел әйләнәсе чыга. Иделне, Иске Сураны, өлкәнең татар авыллары табигатен, мәчетләрен теләп сурәтли. Аның быелтыр яз Кырым, Бакчасарай, И.Гаспринский музее бакчасы табигате төшерелгән эшләре бар. Әңгәмәбез барышында рәссам иҗатын сугыш темасы белән дәвам итәчәге хакында әйтте: "Мин Бөек Ватан сугышында катнашкан татар каһарманнары сурәтләгән яңа серия ясаячакмын. Бу нисбәттән дә татар тарихын өйрәнәм. Геройларыбыз күп! Аннары кинохроника буенча 1945 елда, Мәскәү җәмигъ мәчетендә узган Корбан бәйрәме кадрларын карап илһамландым. Герой солдатларыбыз җыелышып утырган... Арада татар милләтлеләре дә бар. Мулла татар телендә сөйли, мөселман догаларын укый. Искиткеч дулкынландыргыч кинокадрлар! Шуларны карап, яңа картиналар ясарга булдым".

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

ТАЛАНТ

Вахит ИМАМОВ

1975 елның гыйнварында язмыш мине Балык Бистәсенә илтеп ташлады. Күргән-белгән ягым түгел, әмма «Октябрь юлы» газетасы редакциясенә эшкә килдем. Газетаның редакторы Харис абый Әшрәфҗанов белән Казан каласыннан ук таныш идем. Ул чакырды.

Харис абый редакция коллективы белән таныштыра:

– Монда гаҗәеп талантлы бер шагыйрь эшли бит, малай. Кадыйр Сибгатуллин. Ишеткәнең бармы?

Миңа әле 21 яшь кенә, шигърияттән шактый ерак торам. Кадыйр Сибгатуллин шигырьләрен дә укыганым юк.

Харис абый өстәл тартмасыннан яшел тышлы китап тартып чыгарды.

– Гаҗәеп шигырьләр, малай, миңа тыңла!... Мәхәббәт турында болай итеп безнең татарда бер кешенең дә язганы юк әле! Менә, икенчесен тыңла:

Дулкынга ташланган
кызлар күк,
Кырларым күмелгән рәшәгә.
Шагыйрь дә, җырчы да
булма, ди,
Монда үс, монда ту, яшә дә!

Шигърият дәресе шул рәвешчә тагын күпме вакыт дәвам иткән булыр иде, билгесез. Көтмәгәндә ишек шалт итеп ачылды да кабинетка төскә-кыяфәткә бик үк дан булмаган ир-егет килеп керде! Харис абый үзе дә капылт югалып калды сыман.

– Ә, ни, Кадыйр, әйдә, кер, малай. Менә, егеткә синең шигырьләреңне укып утырам әле. Әйдә, танышыгыз. Бездә эшләячәк Вахит Имамов шушы була инде. Ә монысы, менә, Кадыйр абзаң.

– Ә, бик әйбәт булган, – диде дә Кадыйр абый әллә кайчангы танышы сыман авызын ерды һәм нык иттереп минем кулны кысты.

Кадыйр абый белән Харис абый – яшьтәшләр. Миннән унбер яшькә өлкәннәр. Кадыйр абый ишекле-түрле йөри. Кулларын күкрәгенә кушырган. Өстендә якалары бераз кайтарылган куе кызыл төстәге свитер. Чәчләре шактый мул, алар үзе шикелле үк бик пырдымсыз, ахры, чигәләренә салынып төшкән. Кадыйр абый иртән кырынып торуны кирәксенмәгән, ахры, сакал-мыегы каралыбрак тора. Ә бәлки... теләк тә булмагандыр. Бераз бәйрәм иткән кичә Кадыйр абзый. Эче янадыр, шуңа бер урында утыра алмый бугай. Тәрәз буена килеп басты да Камага текәлеп әйтте-салды:

– Сәгать унбер тулсын, авызыңа йөз грамм да аракы кермәсен, адәм тәганәсе!

Харис абый белән иелә-бөгелә дәррәү көлештеләр. (Соңыннан гына белдем, гаять җор телле редакторның репертуарындагы дежур шаяртуларның берсе икән бу.)

Мине редактор урынбасары Ислам абый Ильясовның кабинетына кертеп утырттылар. Ислам абый авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире икән. Әллә ничә сәгать буе иске гәзит төпләмәләрен актарып утырдым. «Корректура укырга кирәк, тегесе-монысы кирәк», – ди-ди корреспондентлары да, тәрҗемәчеләре, корректорлары, машинисткалары, хәтта, майлы кулын куртка итәгенә сөртә-сөртә, шоферына хәтле минем белән танышып чыкты. Ярар, утырам шулай. Редактор райком тирәсендә йөри, диләр. Кунар җирем юк, өмет Харис абыйда. Көтә-көтә көтек булгач, кичке дүртләр тулгач, кабинетка Кадыйр абый килеп керде.

– Давай, киен, киттек.

Ислам абыйга карыйм. Ул мыек астыннан гына елмаеп, әзер полоса корректурасын укып маташа. Кая алып бара икән мине Кадыйр абый, берәр эше бармы? Сүзсез генә хатлар бүлеге мөдиренә иярәм. Редакциянең икенче катыннан төшсәк, ишек төбендә үк «Газик» тора. Руль артында таныш шофер Марсель. Арткы утыргычта дәү гәүдәле ир утыра. Анысы фотокорреспондент Гомәр Әмитов икән.

Мине алга утырттылар. «Сине танымыйлар. Казан кунагы дип уйласалар, бигрәк тә шәп. Андый-мондый гайбәт чыкса, Харис җавап бирер».

Минем эшкә килүне «юдык». Беренче көнне үк Балык Бистәсенең фирменный закусскасыннан авыз иттем. Җиде ел буе яшәү дәверендә киптерелгән балык минем үзәккәйләремә нык үтәчәк әле...

Кадыйр абый белән менә шулай «җылы» таныштык без. Икенче көнне ул миңа тәүге «кайнар» сабагын да бирде.

«Тик тормаган сыртта бәла бар» дигән сыман, Кадыйр абыйдан эш сорадым.

– Хатлар юкмы соң, ичмаса, шуларны эшкәртер идем!

Алты-җиде хат сайлап бирде бу. Мин аларны тиз генә төзәткәләп, «матурлап» кире кайтардым. Унбиш-егерме минут чамасы да вакыт үтмәгәндер, Кадыйр абый бик кырыс йөз белән артымнан кереп тә җитте. Кулында мин «эшкәрткән» бер хат, шуны болгый.

– Синең балаң бармы?

Мин аптырап киттем. Миңа әле егерме бер генә бит, нинди бала ди ул?

– Юк, – мин әйтәм.

– Ә шулай булгач, син ни кишеремә дип миңа болай язасың?

«Фәлән авыл халкы бик тиздән шәфкать туташын үз баласыдай якын күрә башлады». Ничек инде чит-ят кешене үз балаңдай якын күреп булсын? Үз балаң – үз балаң бит ул. Син башта аны яса, тап, үстер, интек, аннары асылына төшенерсең. Аңладыңмы? Мә, киредән төзәт...

Бер мәкаләдә «Басу юлыннан артына дүрт тәгәрмәчле арба таккан, тимер кабиналы трактор килә» дигән җөмлә җибәргәнмен. Ә безнең редакциядә берәр олы бәйрәм алдыннан стена газетасы чыгару кебек бик тә тәрбияви, күркәм бер гадәт бар иде. Исеме дә шәп, «Төтен»! Вәт менә шуның бер санына минем теге «шедевр» җөмләне китереп чәпәмәсеннәрме! Һәм сораулар тезелеп киткән: трактор юлдан түгел, күктән дә йөримени? Арбаны тракторның алдына да тагып буламыни? Арбаларның өч, биш, алты тәгәрмәчлесе дә бармыни ул? Вахитларның авылында трактор кабиналары агачтан да ясала микәнни соң? Һәм башкалар. Миңа шактый гына кызарырга туры килде. Әмма үпкә сакламадым. Чөнки Кадыйр абыйлар мине әнә шулай итеп ипкә-сапка кертте.

Бүгенгәчә аларга рәхмәтлемен...

Миңа Кадыйр абый белән Балык Бистәсендә, аннары Чаллыда унбиш елдан артык бергә яшәргә насыйп булды. Хатирәләр... Хатирәләр...

Шагыйрь кеше бит, көннәрдән бер көнне ул бер сатучы хатынга гашыйк булды. Көненә әллә ничә тапкыр бара тегенең янына, бөтерелеп йөри, ә тегесенең исе дә китми. Шулай да, ниһаять, бер кичтә, Рыбныйның шактый гына пычрак урамында (ә алар анда бүген дә бихисап), җитмәсә, ерымлы бер җирендә очрашырга ризалык биргән бит хыным. Ыспай гына киенеп, кесә фонаре тотып, кичке сәгать җиделәрдә чыгып киткән инде Кадыйр абзыебыз. Пычрак ерып барып җиткән бу, ерымга төшкән, пышылдашкан тавышлар ишетеп, ут яктысын шунда юнәлткән. Ә тегендә... сатучы хатын белән... Кадыйр абыйның үз хатыны Фәүзия апа тора ди. Аллага шөкер, сугыш-мазар чыкмаган анысы. Кадыйр абый икесен дә култыклап алып киткән тегеләрнең.

Язу-багышлау димәктән, тагын бер хәл. Фәүзия апа көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинатында кассир булып эшләп йөри иде. Хатын-кызны беләсез бит инде, гайбәт-фәлән дигәндә дөньяларын онытa, итәк җыеп йөрү гадәтен дә белми. Фәүзия апа да кайсыдыр бер бүлмәгә кереп киткән дә касса аппаратын ачык калдырган, һәм шул чагында, гонаһ шомлыгына каршы, ике шалапай яшүсмер кассадагы акчаны эләктергән дә чыгып сызган. Әле ярый акчасы күп булмаган, унҗиде-унсигез сум. Билгеле, милиция бүлегенә хәбәр иткәннәр. Каракларны тиздән эләктергәннәр. Акча кире кайткан, урыс әйтмешли, «шито-крыто» бит инде, югыйсә. Юк шул, Кадыйр абый бу турыда район газетасына язып чыкты... Ә югыйсә... Фәүзия апаның Кадыйр абыйга күрсәткән изгелекләрен, ул күрсәткән кадер-хөрмәтне беренчи бизмәннәр белән дә үлчәпбәяләп бетерерлек түгел...

Кадыйр абыйның гаилә, тормыш өлкәсенә килеп кергәч, аларның яшәү шартлары турында да әйтеп үтим инде.

Мин Балык Бистәсенә килгән чакта алар ике катлы таш йортның беренче катында, ике бүлмәле тар гына фатирда яшәп ята иде. Төзүчеләр «шәп», йортны мәңге кипмәс сыман сазлыклы җир өстенә салып куйганнар. Аз гына яңгыр явып үттеме, ишек алдына аяк басмалы түгел. Язгы-көзге баткаклыкны әйтеп тә торасы юк. Фатир дымлы, караңгы һәм салкын. Кадыйр абый иҗат итәр өчен аерым почмак та, бер генә уңайлык та юк. Ә бит аның иҗаты тыйгысыз чишмә урынына кайнап торган чаклар.

Район җитәкчеләре алдында йөз суын түгеп йөри торгач, алар гаиләсенә, ниһаять, чистарак урында, шундый ук таш йортның икенче катыннан өч бүлмәле яңа фатир бирделәр. Элек монда райком әһеле яшәгән, шуңа күрә бу фатир беркадәр кадер-хөрмәт күргән иде. Ат арбасына төяп, гаилә «малын» бергәләп яңа фатирга күчердек.

Кадыйр абый иҗат өчен аерым бүлмә турында хыяллана иде. Йөзәрләгән китаплары өчен шунда үз куллары белән бик тә матур киштәләр ясап куйды. Түшәк, урындыкларын урнаштырды. Агач чүбеннән ябыштырып эшләнгән җиһазларны һич яратмый иде. Бәхетенәдер, күрәсең, беркөнне халык суды бинасында иске, әмма шактый зур өстәл күреп кайткан. Суд рәисенә ялына-ялвара торгач, тәки алу

бәхетенә ирештек без аны. Әле революциягә кадәр үк ясалган, әллә нинди матур бизәкләр, бик тә сирәк тимер тоткычлар белән баетылган иске өстәл иде ул. Фатирына алып кайтуга ук Кадыйр абый аны әүвәл сүтеп ташлады. Өстенә матур яшел сукно тарттырды. Бизәкләрен кыргычлар белән чистартып, аларны лаклап чыкты... Шуннан соң ул иске өстәлне танырлык та түгел иде инде. Балык Бистәсеннән Чаллыга күченгән чагында да үзеннән калдырмады ул аны. Хәзер бу истәлекле «суд» өстәле Кадыйр абыйның өлкән малае Марста саклана...

ничарадан бичара, машинага кереп утырдым. Райүзәктән унбиш-егерме чакрымдагы Урахча авылы читенә барып туктадык. Ауга дип шәп җыенган болар. Йөкне бушаталар, мин шаккатып торам. Ике чиләк бәрәңге, өч-дүрт буханка икмәк, дүрт ярты «ак», бетмәс-төкәнмәс консервлар, суган, яшелчәләр. Бу хәтле арсенал булгач, ауга барып йөрисе дә юк бит. Юк, ахырдан болар ике ау мылтыгы, кырык-иллеләп патрон чыгарды. Бәйрәмхан белән Кадыйр абый ауга китте. Дөресен әйтим, бу – тыюлык зонасы, монда балыкка һәм кош-кортка

ЯЗМЫШЫ

И, ул хатирәләр! Август аеның бер көнендә редактор ашыгыч рәвештә колхозга куды мине. Балык Бистәсеннән Котлы Бөкәшкә китә торган юл читендә машина көтеп торам. Бәрәкалла, берзаман минем каршыга район халык контроле комитетының «уазигы» килеп туктады. Руль артында шофер Петр Шлыков, артта милиционер Бәйрәмхан, ә начальник урынында – отпускта исәпләнгән Кадыйр абый.

– Нишләп торасың? – ди.

– Редактор командировкага куды, – мәйтәм. – Ашыгыч рәвештә көзге сөрү турында репортаж кирәк икән.

– Кит, җүләр, – дип көлә бу. – Репортаж язар өчен колхозга барып тору кирәкмени? Синең басу күргәнең юкмы да, трактор күргәнең юкмы? Инде фәлән ел буена эшләп йөрисең бит. Репортажларны телефон аша язарга өйрәнергә вакыт. Үзем өйрәтермен. Ә хәзер, давай, утыр, безнең белән ауга киттек. Үрдәк атарга.

Репортаж өчен янып эчтән генә дер-дер калтырансам да, гаҗәеп бай күлләр... Табеев белән Усманов кебек тузларны гел шушында алып киләләр. Петр белән минем өмет зурдан, «мәргәннәр»дән сый көтәбез. Җитмәсә, ике мәртәбә мылтык аткан тавыш та ишетелде. Ике сантый түгел, диген инде, Петр белән ашыга-ашыга ярты чиләк бәрәңге әрчеп куйдык.

Ярар, хуш, аучылар үзләре дә күренде. Йә Ходаем! Бәйрәмхан трусикчан, мәгәр башында милиция фуражкасы, култык астында төрелгән кием. Ә Кадыйр абый! Күлмәге белән майкасы шыр ләм, колакларында әллә нинди үләннәр... Бераздан соң сөйләп бирде болар. Бәйрәмхан – милиционер бит, ул, чыннан да, һавадагы бер үрдәкне чүкеп төшергән. Үрдәк камышлыкка төбәп төшә башлауга Кадыйр абыйга зәһәр кычкырган бу: «Сикер, чум!» Кадыйр абый белә: үрдәк исән көе төшсә, су төбенә чумачак, томшыгы белән камыш сабагын әләктереп үлсә-үлә, ләкин өскә чыкмаячак. Кадыйр абый – шагыйрь кеше, тыңлаучан, беркатлы шул. Өстендә ни булса, шуның белән сикергән инде бу. Үрдәк илле метр читкәрәк килеп төшкән...

Тәтемәдә үрдәк. Аның каруы, көлә-көлә, ярты сәгать буе җирдә тәгәрәп йөрдек.

Ярар, монысы да хуш. Мәгәр «күңел – урыс, ул маржа сорый» дигәндәй, хыял һавада эленеп калды бит. Үрдәк ашарга дип килдек, инде чәп тә итми кире кайтабызмы? Күңел риза түгел. Кайсыбызның теленнән ычкынгандыр, ул хәтлесен белмим. Киттек без якындагы бер авылга. Нәкъ уртада ясалма күл. Күл читендә каз һәм үрдәк көтүләре. Машинаны буа өстендә туктатып утларын сүндердек тә, әйдә, ауга. Кадыйр абый казлар куып йөри, мин суга чумып иң симезен эләктермәкче. Кадыйр абый белән икебез тиң ләмгә батып беттек...

Җитмеш бишенче елның ноябрендә армиягә китәргә җыенып йөрим. Хезмәттәшләрне «сбежи» итле аш белән сыйлыйсы килә. Фәүзия апа өстәлләрен хәзерләп көтеп утыра. Ә без, Кадыйр абый белән икәү, һаман да шул үрдәк-фәлән булмасмы дип, үз йортлары белән яшәүчеләр урамын әйләнергә чыгып киттек. Ниһаять, сиксән җиде яшьлек бер урыс картын көч-хәл белән күндерә алдык. (Читкә тайпылып шунысын да әйтим: Степан Петрович дигән әлеге карт унҗиденче елда Кышкы сарайда интендант булып хезмәт иткән. Ул Николай патшаны, Керенский, Ленин, Троцкийларны үз күзләре белән күргән, аралашкан кеше. Мин соңыннан әлеге карт турында газетага язарга да җыенып йөрдем. Ләкин иң уяу оешма вәкиле редакциягә килеп, мин яза башлаган кәгазь битләремне җыеп китте. «Иң кешелекле кеше» турындагы хатирәләре совет кысаларына сыймый иде картның). Симез бер әтәчне капчыкка салып өйгә йөгердек. Подъезд төбендә үк диярлек әтәчне хәл иттем дә Фәүзия апага кертеп бирдем...

Хатирәләр күп ул. Сөенечләре бар. Әйтик, Кадыйр абыйга Хәсән ага Туфан әледәнәле хатлар яза иде. Берсен Кадыйр абый көз көне, шыбырдап яңгыр яуганда, түбә астына кереп, елый-елый, миңа әллә ун мәртәбә укып чыкты. Ә анда: «Кадыйр! Синең кебек шагыйрьләр йөз елга бер туа. Кадереңне бик бел», – дигән гаҗәеп зур бәя.

Көенечлесе. Кадыйр абыйның беренче «Әманәт» исемле китабы 1974 елда ук дөнья күрә. «Гамь» 1976 елда чыкты. Мин ул вакытта армиядә идем, Кадыйр абый аны почта аша салды. Хаты да бар иде, әмма сөенечле сүз юк. Күренеп тора, Кадыйр абыйның кәефе ташка үлчим. Сәбәбе: Кадыйр абыйны һаман Союзга алмыйлар, ә ул үзе моңа бик гарьләнә иде. Алмауларының нигезендә бер сер ята: Кадыйр абый татар әдәбияты классигы булып йөргән бер кеше белән пычакка-пычак килгән. Әйе, Кадыйр абый гаҗәеп талантлы, аны Хәсән Туфан үзе Союзга тәкъдим итеп тора, ләкин теге «абзый» бик тә тешләк, шул хут бирми...

Кадыйр абыйның сәерлекләре дә байтак иде. Әйтик, ул түрәләрне бер дә сөймәде. Райкомның өченче секретаре белән әләгешкәне хәтердә.

– Син – кәнәфи колы. Бүген – секретарь син, ә иртәгә партиягезне себереп түгәләр икән, син дә чүплектә, – дип кычкыра Кадыйр абый. – Ә мин – бүген дә шагыйрь, иртәгә дә, хәтта үлгәч тә. Минем погоннарны бернинди партия дә йолкып ата алмый.

Әйе, вакыты-вакыты белән эчкерсез, беркатлы да, вакыты белән кырыс, җәйсез, усал да була белде ул. Әмма берчакта да икейөзле була белмәде, төчеләнмәде, яраклашмады, ялагайланмады, һәрвакытта үзе булып, олы шагыйрь булып кала белде.

Мин аның тормышындагы яшәеш-көнкүреш вакыйгаларына гына тукталдым. Ә аның Ходай Тәгалә тарафыннан бирелгән иң олуг миссиясе иҗат, шигърият иде бит. Кадыйр абыйның иң актив һәм сокландыргыч иҗат белән яшәгән чоры да туган ягында, Балык Бистәсендә үтте.

Аһ, Балык Бистәсендә ничек матур яшәдек без!

Анда иҗади көчләр бихисап. Рашат Мифтахов ике-өч көннең берсендә кыска-кыска хикәяләрен Кадыйр абый өстәленә «тондырып» кына тора. Нияз Акмалның шигърият Олимпына менеп барган чагы. Ул әле өр-яңа поэмаларын укып шаккатыра, әле фәлсәфи һәм лирик шигырьләре белән безне телсез итә. Болар Кадыйр абый белән икесе үзара ярыша-ярыша, якалаша-якалаша шигъри бәйге алып баралар. Мин фәкыйрегез дә Кадыйр абый өстәленә беренче нәсер һәм хикәяләремне ташый башлыйм. Кадыйр абый тетә, сүтә, туздырып ташлый, яңадан эшкәрттерә һәм ахырдан барыбер дә дөньяга чыгара.

(Дәвамы киләсе санда).

Атнаның сәяси мизгелләре

ЧҮБЕК ЧӘЙНӘП, МАЙ ЧЫКМЫЙ

Франция президенты Э.Макронның Мәскәүгә сәфәре күпләр өчен көтелгән нәтиҗә бирмәде кебек. Һәрхәлдә, Россия лидеры В.Путин белән 5 сәгатьтән артык дәвам иткән сөйләшүдән соң үткәргән матбугат очрашуында яклар аны (әдәп өчен дип уйлыйк) югары бәяләсә дә, эшләр әлегә "тарихи чишелеш"кә кадәр үк барып җитмәгән. Сүз анда төп ике проблема тирәсендә барган: Россия өчен – АКШ һәм НАТО тарафыннан кире кагылган иминлек гарантияләре буенча эшне җайлау һәм, Франция өчен – Украинадагы хәрби киеренкелекне деэскалацияләү. Күрәсең, сәяси алыш-биреш тә шулар тирәсендә барган һәм сөйләшү шуңа күзгә-күз үткән. Димәк, яшерер серләре бар. Ә иминлек гарантияләрен Мәскәү бөтен дөньяга ачып таләп иткән иде. Матбугат очрашуында исә В.Путин француз лидерының кайбер тәкъдимнәрен Украинада хәлне җайлауда нигез итеп алу мөмкинлеген әйтте. Э.Макрон да Европада тотрыклылыкны тәэмин итүдә яңа механизмнар кирәклеген искәртте, ә Киевкә булачак сәфәрен күздә тотып, якын көннәр деэскалация мәсьәләсендә хәлиткеч булырга мөмкин, дип тә сөйләде. Әлбәттә, капма-каршы карашларны якынайту яклардан ниндидер ташламаларга баруны да таләп итә. Чөнки, мәгълүм булганча, чүбек чәйнәп кенә май чыкмый. Макрон исә бу очракта үзенә, Мәскәү белән Киев арасында гына түгел, Көнбатыш һәм Россия арасында да арадашчы булу ролен алды. Әмма сөйләшү нәтиҗәләре, асылда, Киев таләпләрен тулысынча исәпкә алмауга кайтып калды.

Танырга кирәктер, тормыш чынбарлыгы бүген сәяси дилемманы шактый ук каттый куя: сөйләшүләр яки сугыш. Яклар әлегә беренчесен сайлый кебек һәм сөйләшүгә әзерлек чаралары да шуңа ишарәли. Э.Макрон һәм В.Путин узган атнада гына да телефон аша өч тапкыр сөйләшкән. Мондый әзерлек, күрәсең, Европа Берлеге Шурасында бүген Франция рәислек итүе, БМОда рәислек Россиягә күчүе белән дә бәйле. Тик Мәскәү карашларында әлегә берниндн дә үзгәреш сизелми. Әйтик, Кырымның үзенә кушылуын аклау өчен ул, әүвәлгечә үк, Украинада урын алган дәүләт түнтәрелешен искә ала. Өстәвенә, Мәскәү үзен Украинадагы низагта катнашучы як түгел, дип тә саный. Әмма үткән сөйләшүләр Украинадагы аяныч хәлләрнең төп сәбәпчесе нәкъ менә Мәскәү булуын күрсәтә дә инде. Француз лидеры Мәскәүгә сәфәре алдыннан биргән интервьюсында: "Россиянең геосәяси максаты бүген Украина түгел, ә НАТО яки ЕС белән янәшә яшәү кагыйдәләрен ачыклау", – дип әйткән иде. Әмма, зур сәясәттән чыгып карасак, Россия инде күптәннән, янәшәдә генә түгел, ә аларның эчендә яшәргә әзерләнә. Ә төрле форматтагы сөйләшүләргә альтернатива бүген хактан да юк. Әйтик, Украина буенча сөйләшүләр "норманд форматы"нда да дәвам итәргә мөмкин.

Фоат УРАЗАЙ.

«Гимназиядә атыш

2021 елның ноябрендә кабат үткәрелгән экспертиза Казанның 175нче гимназиясендә атыш оештыручының акылы сау дип тапты. Хокук саклау органнары системасында озак еллар буе тикшерүче булып эшләгән клиник психолог Иван МАТРЁНИН "Мәгариф" журналы баш мөхәррире Сөмбел ТАИШЕВА белән әңгәмәсендә әлеге фаҗиганең нигә килеп чыгуы, мондый аянычлы хәлләрне булдырмый калу мөмкинлеге һәм кем гаепле булуы хакында фикер йөртә.

– Иван Николаевич, бүген барлык ата-аналар, педагоглар, мәктәп директорлары мондый фаҗигаләрнең кабатлануыннан курка. Бинада нинди генә заманча саклану чаралары булса да, җинаятьче керү юлын барыбер табачак. Җитәкче белән педагогның җаваплылык дәрәҗәсе төрле булу аңлашыла, әлбәттә. Әмма аларның һәркайсы, бер кечкенә генә сәбәп тапса да, булган хәлдә бер-берсен гаепли ала.

– 175 нче гимназия директоры бу фаҗигане бик авыр кичерә, чөнки мәктәпне саклау өчен ахыр чиктә барыбер ул җаваплы. Хокук саклау органнары директорның гаепле булмавын дәлилләрлек фактлар тапкан очракта да, җитәкче барысын да үз йөрәге аркылы үткәреп борчылачак.

Бу фаҗигале хәлгә кадәр мәктәпләрне саклау ата-аналарның үз теләге белән бирелгән акчасы хисабына оештырыла иде. Әлеге гимназиядә ата-аналар түләүдән баш тарткан. Ихтимал, мәктәп директоры аларны акча бирүгә күндерә алмауда үзен гаеплидер, бу очракта бәлки фаҗига булмый калыр иде, дип газапланадыр. Җитәкче өчен мәктәп – үз йорты кебек бит, шунлыктан ул үз өендә нәрсәнедер карап бетермәгән хуҗа кебек үк кайгыра.

– Әлеге фаҗигадә педагоглар түгел, гимназия сагына акча бирүдән баш тарткан ата-аналар күбрәк гаепле, дигән фикер бар. Күп кенә башка уку йортлары җитәкчеләре исә, мәктәпләрне күбесенчә пенсионерлардан торган хосусый сак предприятиеләре түгел, бәлки Росгвардия вәкилләре сакларга тиеш, дигән фикердә. Ата-аналар исә уку йортларын саклау - дәүләт бурычы, дип саный, чөнки министрлык һәм ведомстволарны саклау өчен акча табыла бит. Фаҗигадән соң Татарстан мәктәпләрен саклауга 450 миллион сумнан артыграк акча бүленде. Гаеплеләрне кайдан эзләргә һәм киләчәктә мондый фаҗига кабатланмасын өчен нишләргә?

– Россия законнары һәм, кагыйдә буларак, вазыйфаи күрсәтмәләр буенча, җаваплылык нәкъ менә җитәкчегә йөкләнә. Кеше буларак мин гимназия директорын бик кызганам, чөнки әлеге фаҗигадән соң күп вакыт үткәч тә ул бик каты хәсрәтләнәчәк әле. Кем гаепле – катлаулы сорау. Мин суд хөкеменә кадәр гаеплеләрне атарга җөрьәт итмәс идем. Әмма бу очракта мәктәптә атучы гаепле дип саныйм. Ата-аналар да, педагоглар да, мәктәп директоры да түгел... Атучы һәм күпме кешенең гомерен өзүче гаепле!

– Казандагы фаҗигадән соң РФ Мәгариф министрлыгы төбәкләргә укыту учреждениеләрендә иминлек чараларын көчәйтү буенча хат юллады. Яңа тәкъдимнәрдә: "Кризисларны булдырмау командасы эшчәнлегенә аны оештыру, өйрәтү стадиясендә дә, гадәттән тыш хәл очракларында да тышкы консультант ярдәм күрсәтергә тиеш", – дип язылган. Мәктәпләрдә мондый хезмәт булмаганда моңа ничек ирешергә соң?

– Гадәттән тыш хәлләр очрагына теләсә кайсы укыту учреждениесендә эш планы булу зарур. Барлык штаттан тыш хәлләр коллектив белән өйрәнелергә тиеш. Төп бурыч – мондый шартларда эш-гамәлләр автомат дәрәҗәсенә җиткерелгән булу зарур. Куркыныч туганда кеше югалып кала. Әмма ул кирәкле гамәлләрне әллә ничә тапкыр кабатлап караган булса, барысын да дөрес эшләячәк. Хәзерге заманда мондый хәлләргә һәрвакыт әзер булу сорала. Тикшерүче булып эшләгән мин фәкыйрегез фикеренчә, бу мәсьәләдә җитәкчене җаваплылыктан тулысынча азат итәргә ярамый, бу законга каршы килә. Әгәр кеше җитәкче булырга ризалаша икән, димәк, ул яңа статус һәм яңа вазифасын гына түгел, бар нәрсә өчен җаваплылыкны да үз өстенә алырга әзер, дигән сүз.

– Җинаятьчеләр турында сөйләгәндә нәрсәне истә тоту зарур?

– Җинаятьчене, үз гаебен танып, үз гамәлләренең дөрес булмавын аңлап, камерада утырганда күрсәтергә ярый. Алайса яшьләр аны үзләре үрнәк алырлык "көчле" шәхес дип кабул итәчәк. Ә инде әңгәмә төрмәдә бара икән, тамашачылар аудиториясе җинаятьченең законлы җәза алуын күрәчәк. Казан гимназиясендә кан коючыны беренче сорау алу вакытында бәйләнгән һәм истерикада килеш күрсәткәндә, ул җирәнү хисе тудырган иде – бу шактый дөрес алым, чөнки җинаятьче герой түгел, бәлки күңел болгаткыч бер кабахәт сыйфатында тәкъдим ителергә тиеш.

Гимназиядә атыш оештырган әлеге адәм актыгын полиция хезмәткәрләре тоткарлады. Әмма аларның исемен кем атый ала? Гражданнарның күбесе завхозның исемен дә, җинаятьчене туктатырга маташкан педагогларның исемнәрен дә белми. Пермь университетында атыш оештыручыны тоткарлаган полицейский исеме гаммәви мәгълүмат чараларында еШрак телгә алынды. Менә бу – теманы дөрес яктырту үрнәге.

–Казандагы һәм Пермьдәге фаҗигаләр нинди дә булса секта белән бәйле түгелме икән? Яшерен-батырын түгел, халык арасында мондый фараз да йөри. Ихтимал, мондый шик туyда ике очракта да педагогларның үзләренең элекке укучыларын тыныч, күзгә бәрелми, низагка керми торган итеп сурәтләве дә гаепледер.

– Казан мәктәбендә җан кыючыны тоткарлауның тәүге кадрларын күргәннән соң, мин аны психик яктан сәламәт түгелдер, дип шикләндем. Мәскәү психиатрлары үткәргән беренче экспертиза җинаять кылган вакытында аның акылы сау булмаган, дигән фикергә килгән иде. Тикшерү мәгълүматлары буенча, җинаятьче баш миендәге шеш – менингиомадан интегә. (Соңрак тагын берничә экспертиза үткәрелде, соңгысы аның акылы сау булуын күрсәтте. – Ред.)

– Мәктәп җитәкчелеге генә түгел, ата-аналар да һаман еШрак телгә алган тагын бер проблема бар – мәктәп тормышында психология хезмәте кирәклеге. Бәлки, бүген штатта психолог булу гына җитмидер, психиатрлар катнашында медкомиссияләр үткәрү зарурлыгы бардыр?

– Мәктәпләрдә психиатр катнашында медкомиссияләр оештыру катлаулы булыр, дип уйлыйм. Моның өчен бөтен психиатрия системасын мәктәпләргә җәлеп итәргә туры киләчәк, бу очракта башка мөһим өлкәләр вакытында ярдәм алудан мәхрүм ителәчәк. Моннан тыш, ата-аналарның да бер өлеше моңа каршы чыгарга мөмкин. Бәхеткә, укучыга кагылышлы хәвефләрне ачыклау өчен, сыйныф җитәкчесе белән мәктәп психологының бергәләп эшләве җитә. Ниндидер шик туа икән, алар ата-анага балаларын психиатрга күрсәтергә тәкъдим итә ала. Әмма хәтта бик яхшы белгеч тә чын картинаны шундук ачыклый алмаячак. Әйтик, киләчәктә шизофрения диагнозы куелачак укучы кайбер фәннәрне бик яхшы үзләштерергә мөмкин. Ул кызыксынучан, үз сорауларына җавап табу өчен күп укый. Фикерләү үзенчәлеге ниндидер тайпылыш булуны күрсәтә, дигән сүз түгел әле. Кайвакыт бу даһилек билгесе дә булырга мөмкин, әмма мондый тәртип педколлектив һәм ата-ананы игътибарсыз калдырмаска тиеш.

Хәзер исә "Казан җанкыяры" хакында Интернетта пәйда булган мәгълүматны искә төшерик. Янәсе, җинаятенә ярты ел кала аңа хосусый клиникада диагноз куелган. Ул "энцефалопатия" диагнозы белән поликлиникада исәптә торган. Әлеге чир баш мие зарарлануы һәм аның күзәнәкләре үлү белән бәйле. Бу аның агрессивлыгын аңлата ала. Әмма шундый җитди диагноз турында мәгълүмат гомуми системага кертелмәгән. Дәүләт клиникасында исә аны психиатрлар күзәтер иде. Әгәр физик зат тиешле диспансерда исәптә тормый икән, кагыйдә буларак, корал сатып алуга белешмә һәм лицензияне бик җиңел кулга төшерә ала. Советлар Берлегендә психиатрия ярдәме күрсәтү күпкә яхшырак оештырылган була, ил таркалгач, бу системада да реформалар үткәрелә. Беркая да мөрәҗәгать итмәгән, чирләре беркайда да теркәлмәгән психик авырулар да бар. Бүгенге чынбарлыкта психиатриягә игътибарны арттыру зарурлыгын тану мөһим.

оештыручы гаепле»

– Күп кенә ата-ана, баласының тәртибендә бераз тайпылыш булуын сизсә дә, аны психиатрга алып барырга ашыкмый – бу киләчәктә балага зарар китерер, ул лаеклы эшкә урнаша, машина йөртү таныклыгы ала алмас, дип шикләнә, бигрәк тә аны махсус хастаханәгә ябып куюдан курка. Түләүле хосусый клиникаларда исә кабул итү һәм дәвалау анонимлык шартларында бара. Мин әңгәмәбез алдыннан шундый берничә клиникага шылтыраттым: ярдәмгә мохтаҗлар шактый күп, алардагы психиатрга эләгү өчен берничә атна алдан язылырга кирәк икән.

– Бик дөрес. Наркоманнар турында тиешле структураларга хәбәр итмәүче хосусый клиникалар бар икән, бездә наркотик кулланган килеш рульдә йөрүчеләр дә булачак. Ә инде алардан үзләрендәге мәгълүматны дәүләт органнарына бирүне таләп итсәң, шундук "күләгәдәге" клиникалар пәйда булуын көт тә тор. Бу вәзгыятьтә табиблек сере һәм коммерция клиникалары мәнфәгатьләре җәмгыять мәнфәгатьләре белән каршылыкка керә.

Җәмгыять өчен куркыныч чирлеләрне мәҗбүри теркәү һәм махсус исәпкә алу оештырылмаса, аларның кабат корал сатып алуы һәм фаҗиганең кабатлануы бик мөмкин. Бу – җәмгыять мәнфәгатьләренә кагылышлы системалы проблема һәм хәл итүне көтә.

– Укучыларның нинди тәртибе һәм кыланмышлары аларны яхшы белгән педагогларын сагайтырга тиеш?

– Психолог буларак, мине баланың тәртибе кискен үзгәрү, аның социумнан китүе сагайтыр иде. Һәркем белән теләп аралашкан үсмер кинәт үз эченә бикләнә икән, димәк, аны йә яшьтәшләре мәсхәрәли, яки гаиләдә җитди проблемалар бар, яисә бу аның психологик статусы белән бәйле.

Укучының дөньяга һәм әйләнә-тирәсендәге кешеләргә мөнәсәбәте үзгәрү, аның бик агрессив һәм мәрхәмәтсезгә әйләнүе дә сагайтыр иде. Ниндидер югары идея белән җенләнүе исә бигрәк тә игътибар сорый. Бу очракта сыйныф җитәкчесе, башка укытучыларның аеруча сизгерлеге мөһим. Әгәр укучы, мәсәлән, бөтен дөньядан үч алу теориясе белән мавыга икән, бу турыда мәктәп җитәкчелегенә хәбәр итү зарур.

Үсмер үзе аеруча якын иткән туганы белән даими аралашса һәм серләрен бүлешсә, яки берәр кызга гашыйк булып, бу дуслык аңа уңай тәэсир итсә, ул үзенең әллә нинди идеяләр белән җенләнүен онытырга да мөмкин. Мәктәп директорының тәрбия буенча урынбасары яки сыйныф җитәкчесенең, проблеманы башында ук күреп алып, үсмергә ярдәм итүенә мисаллар да шактый. Билгеле, сүз психиатрия турында бармаганда.

– Әңгәмәбезгә әзерләнгәндә, мин якын-тирәдәге 9, 38, 49 нчы мәктәпләргә кереп чыктым, аларның берсендә мин үзем укыган идем. Бу - Казанда бөтен илгә яманаты чыккан үсмерләр төркемнәре (группировкалар) вакыты. Шулай булса да, мәктәпләр һәм анда укучылар өчен берниндн куркыныч юк иде. Хәзер дә әлеге уку йортлары территорияләрендә тышкы яктан әллә ни үзгәреш юк, биек койма белән генә әйләндереп алынганнар.

– Без Сезнең белән яшьтәшләр. Ул төркемнәр чорында кайбер кешеләр кулында корал хәттин ашкан иде. Казанда, Чаллыда уннарча төркем бер-берсе белән сугышты. Әмма мәктәпкә бәреп керү беркемнең дә башына килмәде, чөнки "мәктәп" һәм "атыш" төшенчәләрен янәшә кую башка сыймаслык хәл иде. Хәзер исә, уку йортларындагы фаҗигаләрдән пиар ясаганда, акылы чамалырак кешеләр, "Менә бит шулай да була", дип уйлый башлый.

– Фаҗигаләрдә җинаятьчеләрнең ата-анасын гаеплиләр. Аларның эмоциональ халәтен күз алдына да китерү кыен, алар, һичшиксез, бу хәлләрдә болай да үзләрен гаепле тоядыр.

– Еш кына ата-ана баласының уй-кичерешләрен бөтенләй белми. Яшүсмер вакытта бала алардан күп нәрсәне яшерә башлый. Үскән саен, бала үзгәрә, ата-анасы исә аны һаман кечкенә сабый сыман кабул итә. Һәр әти-әни үз баласын иң яхшы дип санарга күнеккән. Укытучылар белән аралашып торсалар, бик шәп тә бит. Әмма еш кына ата-ана үзенең яраткан сабыен тәрбияләү өчен җаваплылыкны укытучыга йөкләмәкче була. Педагог исә баланың начар укуында ата-ананы гаепли һәм репетиторлар ялларга киңәш итә. Шул рәвешле, нәтиҗәдә бала өчен беркем дә җаваплы түгел булып чыга. Иң яхшы вариант – ата-ананың сыйныф тормышында актив катнашуы. Яшь үзенчәлекләрен дә исәпкә алу мөһим. 16-18 яшьлек чак – аклы-каралы фикерләү еллары, үсмергә аеруча агрессивлык хас. "Миңа яңа джинс чалбар кирәк", "Миңа яңа телефон алмасаң, тәрәзәдән сикерәм" кебек кискенлек гадәтигә әйләнә...

– Бу нормаль хәлме соң?

– Нормаль түгел, әмма шул яшькә хас. Бала ата-анасын истерика белән җиңәргә омтыла, шуңа суицид белән куркыта. Шулай да мондый белдерүләрне хәвеф факторы итеп карарга, бала белән аңлашырга кирәк.

Әгәр кеше бөтендөнья явызлыгы яки игелеге теориясе белән мавыга, ниндидер югары идеяләр белән җенләнә башлый икән, бу сагайтырга тиеш. Фәлсәфә сату 35-40 яшьлекләргә килешә ул, әмма 16-18 яшьлек үсмерләр эше түгел.

– Җинаятьчеләрнең ата-анасы балаларының дуслары аз булуы һәм аларның социумнан читләшүе хакында әйтә. Күбесе компьютер уеннары белән мавыга. Ә уенга мөкиббәннәр өчен чынбарлык һәм виртуаль тормыш арасындагы чикләр җуелу һәркемгә мәгълүм. Минемчә, уку йортларындагы чын җинаятьләр һәм компьютердагы атышлар арасында ниндидер охшашлык күзәтелә.

– Тикшеренүләр күрсәткәнчә, виртуаль кешеләргә виртуаль мылтыктан аткан чакта сәламәт кеше психикасы да зыян күрә – агрессивлаша. Әгәр инде психикасында ниндидер тайпылышлар булган кеше уйный икән, атканда ул киеренкелектән арына, аның чынбарлыкта кешегә ату ихтималы бик аз. Ә инде уенны чын кеше белән аралашудан артыграк күрүче исә чынбарлыкны аңламый башлаячак һәм уенга көннән-көн тирәнрәк кереп чумачак.

Менә нәрсә сагайтырга тиеш:

– үсмернең тышкы кыяфәтендә һәм тәртибендә ниндидер аермачык шапшаклык, җыйнаксызлык пәйда булу;

– икейөзлелек, эгоистлык, шәхси мәнфәгатьләр хакына гаделсезлеккә барырга әзерлек;

– балада әледән-әле сәбәпсез хәвефләнү һәм паника күзәтелү;

– баланың вакыт һәм пространствода буталуы, хәтере начарлану, контекстларны аңламавы;

– әледән-әле берниндн сәбәпсез агрессия күзәтелү, аның туганнарына һәм якыннарына юнәлтелгән булуы; көчле тәэсирләр таләп ителгәндә берниндн эмоциясез калу да шик тудыра;

– хисләрнең бик тиз кайнарлануы һәм суынуы;

– баланың еш кына йокысызлыктан һәм төнге саташулардан интегүе;

– баланың дәрес темасын һәм хәтта үзе белән сөйләшүне дә аңламавы, еш кына хафаланган кыяфәттә булуы, фикер һәм аңының чуалчыклыгы;

– үзенең яшәргә теләмәве турында белдерүе, мордар китү белән янавы һәм үзенә кул салырга маташуы.

Биредә шунысын әйтү мөһим: барлык бу билгеләр баланың психикасында һичшиксез үзгәрешләр бар, дигән сүз түгел. Яшүсмер чакта агрессия һәм эгоизмның артуы, серләр пәйда булу норма санала. Санап кителгән билгеләрдән берничәсе бик көчле икән, ата-анага психиатрга яки медицина психологына мөрәҗәгать итү мәслихәт.

Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА
тәрҗемәсе.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

12 февраль (шимбә). *Рәҗәб аеның 11 нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 11.27сәгатьтә калка, 6.18 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 9.26 сәгать.*

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

Балан сихәте (1)

Хроник ютәл интектергәндә, 1 әр аш кашыгы гөлҗимеш һәм балан җиләген, ромашка, тырнак гөл, андыз үләннәрен 1 литр кайнар суга салалар, сүрән утта 5 минут пешерәләр, 5-6 сәгать төнәткәч, сөзәләр, ашарга ярты сәгать кала 1 әр аш кашыгы эчәләр. Яхшы ябыла торган пыяла банкада саклыйлар. Ангина вакытында тамакны чайкау өчен, яртышар аш кашыгы балан чәчәге һәм җиләген 1 стакан кайнар суда 3-4 сәгать төнәтәләр, сөзәләр. Бер чайкаганда, ярты стакан төнәтмәне кулланалар, 1-2 аш кашыгын эчәләр.

13 февраль (якшәмбе). *Рәҗәб аеның 12 нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 12.21 сәгатьтә калка, 6.56 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 9.31 сәгать.*

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

Балан сихәте (2)

Тамак авыртканда, балан җиләкләрен изеп, әз генә җылы суга салалар, бал кушып, яхшылап болгаталар да, чиста тукымага сеңдереп, муенга урыйлар, 1 сәгать тоталар. Мондый компрессны көненә 2 тапкыр куярга кирәк. Йөрәк авыртканда, 3-4 аш кашыгы балан җиләген 1 стакан кайнар суда 4 сәгать төнәтеп, сөзәләр, көненә 3-4 тапкыр 1 әр стакан эчәләр. Балан кан басымын төшерә. Ярты кило җиләкнең согын сыгып алалар, калган түп өстенә 100 грамм су салып, 5 минут кайнаталар, сөзәләр, 100 грамм шикәр өстәп болгаталар, бераз суынгач, сокка кушалар. 1 аш кашыгы бал салып, яхшылап болгаталар. Ашарга ярты сәгать кала 2 шәр аш кашыгы эчәләр.

14 февраль (дүшәмбе). *Рәҗәб аеның 13 нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында,13.28 сәгатьтә калка, 7.28 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 9.35 сәгать.*

Авыр энергетикалы көн. Бүген кеше үз нәфесенең теләк һәм коткыларына бигрәк тә бирешүчән.Тыелгысыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

Балан сихәте (3)

Даими баш авыртуыннан котылу өчен, көн саен, тәменчә бал кушып, 1 стакан балан согы эчәргә кирәк. Бу сокка солы

(Дәвамы 18 нче биттә).

Хезмәткә хөрмәт бармы?

Нинди генә болгавыр заманнарда да туган авылым Иске Бәрән – Иске Рәҗәп халкы бердәм булып, зур сынау-яуларда сынатмыйча яши алган һәм бүген дә, Бөек Болгар дәүләте таркалганнан соң, беренчел килеп төпләнгән җиргә тугры калып яши бирә. Ул бары тик үз көченә таянган хәлдә, зур дәүләтләр тоткан борынгы болгар-бәрәнҗәрләрнең варислары булып кала.

Соңгы елларда туган авылыбыз күзгә күренеп матурайды: хан сараедай зур, иркен мәктәп, яңа мәдәният йорты, фельдшер-акушерлык пункты, балалар бакчасы, почта бүлекчәсе, янгын сүндерү посты, банк филиалы – авыл өчен кирәк булган барлык төр оешма-учреждениеләр дә бар. Һәрбер өйгә су, газ кертелгән, юллар төзек. Ирешелгәннәрнең нигезендә хезмәт ята. Болар – соңгы берничә дистә елда, күпмедер күләмдә яулап алынган мөстәкыйль яшәвебезнең җимешләре. Ләкин шул эшләрнең башында торучылар, аны тормышка ашыручылар – гади авыл кешесенең һаман да читтәрәк калуы күңелне нык әрнетә.

Югыйсә, авылларда дистә еллар дәвамында һәр эшне җиренә җиткереп башкаручы оста, тәҗрибәле кешеләр бар. Матбугат битләрендә алар турында элек тә күп язылды. Кызганыч, ләкин нигәдер шуннан ары китә алмыйча, зур хөрмәткә лаек авылдашларыбызның хезмәтенә күрә тиешле бәяне үз вакытында алмавы безне бик борчый. Әллә без үзебезнекеләрнең фидакарь хезмәтен өстәгеләргә тиешенчә тәкъдим итә белмибез, әллә һаман да шул көнчелек-хөсетлектән теләмибезме? Юкка гынамы, бөек Тукаебыз да «бармыни бездә гомумән чын кеше кадрен белү?!» дип ачынып язган иде. Әле тагын җитмәсә, зур урыннарда үзебезнең авылдан чыккан кешеләр дә эшли, мөмкинлекләре дә күбрәк, сүзләре дә үтә, тик вакытында алар белән дөрес юнәлештә булып, эшебезнең хаклыгын күрсәтә белү җитми.

Әйтик, ярты гасырлап гомерен китапханә эшенә багышлаган авылдашыбыз Флера Хәйретдинова. Шул еллар дәвамында төрле темаларны яктырткан берничә йөз мәкалә-язмасы республика һәм район газеталарында басылып чыккан. Атна саен оештырыла торган җирле радиотапшырулар өчен сценарийлар һ.б. Ни кызганыч, җирле матбугатның үз кимчелеге дә хәттин: беренче чиратта, ике телне камил белгән әдәби хезмәткәрләр җитешми. Матбугатка мәхәббәт тәрбияләү эшендә шушы төбәктән үсеп чыккан атаклы каләм осталарының исемнәрен мәңгеләштерү дә ярдәм итәр иде. Мисалга, районыбыз газетасының татарча варианты «Яңа тормыш»та күренекле якташыбыз, тарих фәннәре кандидаты, талантлы журналист Сәмигулла Хәйретдинов исемендәге премияне булдыру бик зарур. Ул олы җанлы, бик күпләргә ярдәмчел дус-остаз, ярты гасыр элек район газетасында авыл хәбәрчеләре белән эшләүдә зур өлеш керткән, татар матбугатында үз йөзен булдырып, тирән эз калдырган шәхес. Ул заманнарда авылыбызны республикага танытты, безне күп очракта аның язмалары аша беләләр һәм хөрмәтлиләр. Аның исемендәге премияне, һичшиксез, булдырырга иде.

Үз заманасында безнең үз фәненең профессорлары булган, хезмәтләре өчен мактаулы исемнәр бирелгән, орден-медальләр белән бүләкләнгән укытучыларыбыз бар иде. Менә кайберләре: Зөбәйдә Насыйбуллина – РСФСРның атказанган укытучысы, Рәүф Хәйруллин – Татарстанның атказанган укытучысы, Сания Гыйззәтуллина – Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, Фатыйма Хатыйпова III дәрәҗәле Хезмәт Даны ордены кавалеры, Татарстанның атказанган мәктәп укытучысы Зиннәт Гыйззәтуллин, СССРның һәм РСФСРның мәгариф отличниклары Усман Сафиуллин, Нариман Галимҗанов, Фаягөл Хәмитова, Гаммар Фәйзиев...

Вакыт та бик тиз уза тора, дөньялар да үзгәреш кичерде, ләкин алар аң-белем биргән яшүсмер балаларның күбесе остазлары юлыннан бик теләп киттеләр, үзләре үк бүген Иске Рәҗәп, район, республика күләмендәге билгеле укытучылар булып җитеште. Күңелне сөендереп, инде бүген алар тәрбияләгән укучылар төрле конкурс-бәйгеләрдә призлы урыннарны әледән-әле яулап тора, хәтта Мәскәүгә үк барып, Иске Рәҗәп мәктәбенең данын яклап чыгышлар ясый. Әмма республиканың мәгариф өлкәсендә мактаулы исемнәр алу, орден-медальләргә лаек булучылар исемлегендә Спас районы, шул исәптән безнең Иске Рәҗәп урта мәктәбе дә, соңгы елларда, нигәдер һич күренми. Без тормышта аттан артык эшләргә тырышабыз, күрсәтер уңышларыбыз да бар, әлеге дә баягы, ирешелгәннәрне бәян итеп, хөрмәткә лаеклыларны тәкъдим итә белмибезме? Безгә калса, 40ар ел гомерләрен балаларга белем-тәрбия бирүгә багышлаган укытучыларны «Татарстанның атказанган мәктәп укытучысы» дигән мәртәбәле исемгә тәкъдим итү һич артык һәм урынсыз булмас иде кебек.

Ришат ГЫЙНИЯТУЛЛИН.
Спас районы,
Иске Рәҗәп авылы.

Айга кырын карама

кайнатмасы кушып эчкәндә, эчәклекнең лайлалы катлавы ялкынсынуыннан да дәваланып була. Бавырны чистарту өчен, ярты кило балан җиләген, аз гына су өстәп, эмальләнгән савытта йомшарганчы пешерәләр, иләк аша издереп чыгарып, суынгач, 200 грамм бал кушалар, 14 көн буе иртән ач карынга һәм кичен йоклар алдыннан 2 шәр аш кашыгы кабалар.

15 февраль (сишәмбе). ***Рәҗәб аеның 14 нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында,14.45 сәгатьтә калка, 7.42 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 9.39 сәгать.***

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар булырга мөмкин. Килешүләр төзү уңай нәтиҗә бирә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

Балан сихәте (4)

Кан составын яхшырту өчен, 1,5 стакан вакланган гөлҗимеш җиләген 1,5 литр суда 10 минут пешерәләр, 1 аш кашыгы канлут үләне, 5 аш кашыгы шалфей өстәп, 8-10 сәгать төнәтәләр, сөзәләр. Ярты стакан изелгән балан җиләге, чирек стакан шикәр өстәп, яхшылап болгаталар. 3 атна буе, ашарга ярты сәгать кала, чирегешәр стакан эчәләр. 2 ел дәвамында һәр 3 ай саен шулай дәваланганда, кан составы яхшыра. Көн саен берәм-берәм 8-12 балан төшен йотканда бәвел һәм үт куыкларындагы ташлардан котылып була. Үтне куа торган төнәтмә әзерләү өчен, балан җиләге, бөтнек үләне, каен бөресен тигез микъдарда кушып, шуның 1 аш кашыгын 1 стакан кайнар суда ярты сәгать төнәтәләр, сөзәләр, ашаганнан соң 1 әр аш кашыгы эчәләр.

16 февраль (чәршәмбе). ***Рәҗәб аеның 15 нче көне. 17 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында,16.07 сәгатьтә калка, 7.56 сәгатьтә бата. 19 сәгать 56 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 9.43 сәгать.***

Мәхәббәт, иҗат, яшәү шатлыгы көне. Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Нерв һәм эндокрин системаларга, күзгә игътибарлырак булу сорала. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы.

17 февраль (пәнҗешәмбе). ***Рәҗәб аеның 16 нчы көне. 18 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында,17.29 сәгатьтә калка, 8.06 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 9.48 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Бизләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

18 февраль (җомга). ***Рәҗәб аеның 17 нче көне. 19 нчы Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында,18.52 сәгатьтә калка, 8.16 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 9.53 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, эчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

Балан куасы

Кан тамырларын киңәйтү өчен, балан һәм кызыл чөгендер куасы эчү файдалы. 300 г чи чөгендерне уып, стакан ярым суда пешерәләр. Икенче савытта стакан ярым суда 300 г баланны берничә минут кайнатып алалар. Аннары ике кайнатманы кушалар, өчтән бер стакан шикәр өстиләр, кайнатып чыгаралар да, суыталар. Сөзеп, салкын килеш эчәләр.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

11 февраль – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).
12 февраль – Зур залда – «Исәнмесез?!.» (М.Гыйләҗев). Кече залда – «Киек каз юлы» (И.Мөхәммәтгалиев).
13 февраль – Шәрык клубында 14.00 – «Бичара кыз» (Г.Ильяси). Зур залда – «Бабайлар чуагы» (И.Зәйниев). Кече залда – «Тамашачы тамашасы».
15 февраль – «Җәйнең бер көнендә» (Й.Фоссе).
16 февраль – «Зур залда – «Әтәч менгән читәнгә» (А.Гыйләҗев). Кече залда – «Тамашачы тамашасы».
17 февраль – «Санаулы кичләр» (А.Володин).
18 февраль – «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

30 гыйнвар – 26 февраль – Ф.Шаляпин исемендәге 40 нчы халыкара опера фестивале:
11,12 февраль – «Паяцы» (Р.Леонкавалло).
15 февраль – «Борис Годунов» (М.Мусоргский).
17 февраль – «Севильский цирюльник» (Дж.Россини).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

11 февраль – «Ядәч! Исемдә! Бер гаилә трагикомедиясе» (Й.Миңнуллина, М.Гафурова, А.Бикбулатов, Э.Дусаева).
12 февраль – «Кияү урлау» (С.Юзеев, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
13 февраль – «Гашыйклар тавы» (И.Юзеев).
15 февраль – «Алтын көз» (Ш.Фәрхетдинов).
16 февраль – «Гомер буе сине көтәм» (И.Гали).
17 февраль – «Галәм. Әгъләм» (М.Әгъләм).
18 февраль – «Син бит минем бергенәм» (И.Мәхмүтова).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

12,13 февраль – Премьера. «Матур City» (А.Әхмәтгалиева).
17 февраль – 13.00 – «Сәлам, Актәпи!» (А.Сальникова). 18.30 – «Тапшырыл...ган хатлар» (Г.Кутуй).
18 февраль – «Яратып туялмадым» (А.Әхмәтгалиева).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

11 февраль – Зур залда – «Волшебник изумрудного города» (А. Волков). Кече сәхнәдә – «Коза и овца» (Г.Тукай, Г.Рәхим).
12 февраль – Зур залда – «Волк и семеро козлят» (Э.Гыйлемханова инсценировкасы). Кече залда – «Кәҗә белән сарык» (Г.Тукай, Г.Рәхим).
13 февраль – Фойеда 10.00 – «Приключения пингвиненка Пинка» (А.Галиуллина). 11.30, 13.00 – «Не хочу, не буду» (П.Геннадьева). Зур залда – «Мырау батыр» (Н.Исәнбәт).
16 февраль – «Мырау батыр» (Н.Исәнбәт).
17 февраль – «Аленький цветочек» (С.Аксаков).
18 февраль – «Аленький цветочек» (С.Аксаков). 19.00 – «Ночь перед Рождеством» (Н.Гоголь).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

12 февраль – Вадим Захаров концерты.
13 февраль – 11.00 – Джаз концерты. 17.00 – Вадим Захаров концерты.
14 февраль – Татарстан Республикасы филармония джаз оркестры концерты.
16 февраль – П.Чайковский исемендәге XV халыкара конкурс лауреаты Лукас Генюшас концерты.
17 февраль – Татарстан Республикасы халык музыка уен кораллары оркестрына кушылып опера йолдызлары Алексей Таринцев һәм Агунда Кулаева җырлый.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

13 февраль – Наталья Железных ансамбле катнашында «Джаз маҗаралары» дип исемләнгән концерт программасы.
15 февраль – Камера музыкасы концерты. Халыкара конкурслар лауреатлары З.Фәхразиев (фортепиано), Т.Гыйләҗетдинов (скрипка), С.Пономарев (виолончель) чыгыш ясый.
17 февраль – «Рита» операсы (Г.Доницетти). Казан дәүләт консерваториясе солистлары һәм хоры, Казан музыка көллиятенең симфоник оркестры катнаша. Дирижер – Д.Железнов. Куючы режиссер – Е.Артамонов.

Кирам САТИЕВ кытыклары

Алдау, алдану...

Бөтен дөреслек ялганга корылган. Алдадылар, алдыйлар һәм алдаячаклар. Дөнья шулай яралган, шулай бара һәм барачак. Кризис дип алдадылар. Кая китте соң ул, кая югалды, кая юл алды? Халык алданды.

Пирамидалар белән тагын шул ук хәл. Эшләми генә баю – урыс әкиятләренә нигезләнгән, адәм баласының канына сеңгән. Кичә генә Иванушка-дурачок хәерче иде – бүген ул патша кызын алды һәм илнең ярты байлыгына хуҗа булды... Халык эшләми генә, тиз генә баемакчы.

Коммунизм дип алдадылар. Барысы да алданды, күпчелек – ышанмады. Бер студент, бу бит ялган дип әйткән иде, диплом алмаячаксың дип, авызын бик тиз яптылар. Фикере ачык калды, ә үзе күптән кереп ятты: башта психбольницага, аннары – мәңгелек йортка. Дипломы җир өстендә калды.

Җиң сызганып, кан-яшь түгеп коммунизм төзетте! Белә торып, бу ялганга - башыбызны идертте! Шуның белән бетте.

Сифилис белән куркыттылар, аннары спид дип алдадылар. Хәзер ковид дип яныйлар. Укол кадау мәҗбүри түгел, ләкин сату-алу, ашау-эчү урыннарына ансыз кертмиләр, шәһәр транспортында йөртмиләр. Армиядә солдатлар “нәрсә соң ул “бактериологическое оружие” дип офицерлардан сорыйлар иде. Белмәвегез хәерле, дип әйтүләре дөрес булган икән. Сифилис бетте, спид – китте, ковид килеп җитте. Чиратта – “Себер язвасы” диләр. Бар нәрсә дә Ходай кулында.

Берәү алдый, икенчесе алдана. Бар нәрсә акчага корылган. Битлек, перчатка, кул юу әйберләрен сатып алды миллионнар. Ә аның миллионнары кемнеңдер кесәсенә керде. Талау ике төрле була: законлы һәм законсыз. Менә монысы инде – законлы талау. Бөтен дөреслек ялганга, алдау-талауга корылган, дип әйтәм бит. Халыкның игътибарын җәлеп итеп, уй-фикерен читкә юнәлтеп, Кашпировский, Чумаклар телевизор экраннарына чумдырып, ил халкын озак алдадылар. Кул болгап, су болгатып, бөтен кешене “терелттеләр”. Табибләрнең кирәге калмады: халык тагын алданды.

Патшаны бәреп төшергәннәрен укып беләбез. Ә нигә кирәк иде? Аның урынына башка патша килә. Ил – патшасыз, оркестр – дирижерсыз, көтү көтүчесез булмый. Булганы юктыр гомер. Хәерчелек мәңгелек булган кебек, алдау-алданулар да гомерлектер.

Алдау, алдану – һәрчак алдаучы файдасына төгәлләнә. Беренче алдаучы кем булгандыр, моны статистика да, хәтта подъезд төбендәге әбиләр дә белми.

Әби-бабайларны теге дөньяда яхшы була, дип алдаганнар. Нәрсә, син анда булдыңмы, аннан кайттыңмы, кемдер кайтып сөйләдеме? Берсе коммунизм дип алдады, икенчесе барыгызны фатирлы итәм, дип ялганлады. Беренчесенә үпкә юк: без коммунизмда яшәрбез, диде. Сүзендә торды. Ул “Сез яшәрсез” димәде бит!

Минем өчен, елның бар көне дә 1 апрель - алдау-алдану көне. Берәү алдаса, икенчесе – алдана. Системаны үзгәртеп булмый. Үзгәртеп карадылар бит инде! Ә нәтиҗәсе?

Алдау, алданучыларга, талау-талануларга күптән күнеккән халыкны киләчәктә нәрсә көтә? Анысын вакыт күрсәтер...

Тапкыр җавап

– Вадим, заманнан артта каласың, әнә барысы да җырлап бии, биеп-җырлый, сикерә, чаба... Нишләп син генә бер урында багана кебек катып торасың?

– Сезнең сорау-киңәшегезгә Кирам Сатиевның афоризмы белән җавап бирәм, – ди В.Захаров – “Әгәр җырчы, тамашачыны селкетә алмаса, үзе селкенә башлый”.

Шамкай шаяруы

Тукталышта Р.Шамкай басып тора. Йөзе борчулы – август төне кебек караңгы. Олы кешене зурлап исәнләштем. Сәламемне алып та тормады, сүз башлады:

– Кайтам да хатынны тотып кыйным, ярам, эт итеп сугәм.

– Нәрсә булды, Рәшит абый?

– Аэропортка бардым, билет бирмәделәр – паспортларны өйдә онытып калдырганмын.

– Ә хатынның ни гаебе бар?

– Гаебе-кыегы, гөнаһы юк. Кемнәндер ачуны алырга кирәк ич! Үземне тотып кыйный алмыйм бит инде!

Соңгы көрәшү

– Рәхмәт сиңа, Кирам энем, укыдым, мине зурлап, Советлар Союзы Гәрәе дип язгансың. Үземнең шундый дәрәҗәле икәнемне белми йөргәнмен... Кыйммәтле ресторанда, кунаклар җыелганда, Г.Рәхимнең “Оныттың бугай” исемле җырын (Г.Ильясов көе) кат-кат уйнадым. Гәрәй абый онытылып, йотлыгып тыңлады... Соңгы көрәшү булган икән...

Кирамизмнар

- Үлгәч тә яшәр өчен, яшәгәндә үлмәскә кирәк.
- Хатыныңны яратасыңмы? Яратам. Аны без дә яратабыз.
- Дөньяда ике куркыныч көч бар: берсе – атом, икенчесе – хатын. Атомны йөгәнләп була...
- Сәламәтлекне сатып алып буламы? Табибне – була...
- Гадәттә, башсыз кеше, башлы түгел, ә башлык булырга омтыла.
- Салкын корал белән дөньяны җылытып булмый. Җылатып була.
- Көчсез бәндә, көчлеләр көче белән көчлене җиңә.
- Яхшы музыкантка тамашачылар кул чаба, ә конкурентлар – аяк чала.
- Көлә белми көлүченең алгы тешләре сирәк була.
- Тарих укытучысы, тарих дәресендә тарихи хата ясап, мәктәп тарихына керде.
- Яратканың ярattырмаса, яратмаганны сөяргә туры килә.
- Вакчыл ир-аттан һәм саран хатын-кыздан саклан.
- Россия җитәкчесенең йөрәгенә татар операция ясады. Казахстан Гимнын татар иҗат иткән, “Во поле береза стояла”ны татар язган...
- Хәерченең хәерче булуына хәерче генә гаеплеме?
- Телевизордан сөйлиләр: “Обезьяны – наши младшие братья”. Ә русның “Старший брат” икәнен аңа кадәр белә идем.
- Билен бөгүче билдән түбән суга.
- Чебиләрне һәм солдатларны көз көне саныйлар.

Үзгәреш җиле

Дөньяда бар нәрсә дә гел үзгәреп тора дип әйтү – дөрес түгел. Коръәнне беркем дә үзгәртми, аны тәрҗемә (тәфсир) генә итәләр. “Аврора” крейсеры да гел урынында тора, исеме дә “Аврора” булып кала. Тапкырлау таблицасы да, нота грамотасы да үзгәрми.

Бу фикерләрне “Үзгәреш җиле”нең соң хәтеремдә яңарттым. Әлеге чарадан нәрсә үзгәрде? Кайберәүләрнең кесәсе калынайды, күп акчалар җилгә очты диючеләр булды. Мин матди ягына түгел, сәнгати ягына игътибар иттем.

Югары музыка белемен – консерватория тәмамлаган, атказанган һәм халык артисты, Европа илләрендә, Кытай, Америкада гастрольләрдә булган, Илһам абый, Әлфия апа һәм башка күренекле җырчыларыбыз белән гомер буе бергә эшләгән баянчы-музыкант буларак әйтер сүзем бар.

Кайбер җырларны шундый үзгәрттеләр: сүзен ишетмичә, аның шул әсәр икәнен аңлап булмый. Кемнәр соң алар? Нота грамотасының дөньяда барлыгын ишетеп кенә белүче сәхнә йолдызлары. Гомерендә бер опера карамаган, балет күрмәгән, симфония тыңламаган, классик музыкага җирәнеп караган эшем иярләре.

Үзгәртмә син көйне (мелодияне)! Әгәр үзеңне җыр-музыка өлкәсендә даһи дип саныйсың икән – яңаны яз, алардан да моңлырак, аһәңлерәк, мәгънәлерәк итеп. Классика шуның өчен дә классика – ул үзгәрми. Клаудио Монтеверди, Скарлатти, Верди, Бах, Бетховен, Моцарт, Глинка, Чайковский, Прокофьев, Шостакович, Сәйдәш, Җиһанов әсәрләре ничек язылган – шулай уйнала, шулай башкарыла.

Көйгә (мелодиягә) тимә! Кереш өлешен дә үзгәртмә – композитор аны алдагы музыкага туры китереп язган. Һәм тагын: куплет арасында теләсә-нәрсә уйнап тору – көйне белмәүдән, наданлыктан килә. Әле шуны аранжировка дигән булалар бит! Тукай шигырьләрен дә, Сәйдәш моңнарын да беркем дә үзгәртми һәм моңа хакы да юк.

Турайтабыз диеп мөгезен, үтерделәр нәсел үгезен. Бераз әкият, бераз мәсәл бу – тинтәклектән көлгән әсәр бу. Турайтма, шулай торсын! Турайтудан ни мәгънә? Кирәкмәгән шөгыль. Борының кәкре, ямьсез, нигә операция ясатмыйсың, диләр. Ходай ничек биргән – шулай калсын. Бөркетнең борынын беркем дә турайтмый, турайтсаң – ул бөркет булудан туктый, башкалар кыяфәтенә керә һәм аны санга сукмыйлар, чукыйлар.

Үзгәртеп кору булды – Совет иле яшәүдән туктады. Начармы, яхшымы? Әйтә алмыйм – монысы сәясәтчеләр эше. Аны кемнәрдер әллә чынлап, әллә көлеп “үзгәртеп кыру” диделәр.

Әгәр татар җыр-моң сәнгатен дөньякүләм аренага чыгарырга уйлыйбыз, телибез икән – иң беренче нәүбәттә ул татарча булырга тиеш. Аның милли булуыннан кыенсынырга, оялырга кирәкми. Пентатоникага нигезләнгән (ә пентатон – биш аваз дигәнне аңлата) музыкабыз җир шарында иң киң таралган лад: татар, башкорт, Идел буе, Урал, Вьетнам, Лаос, Камбоджа, Бирма һәм Кытай көйләре – шушы лад – пентатоникага корылган.

Үзгәрешләргә мин каршы түгел. Ләкин аны аек акыл белән, югары уку йортларында алган тирәнтен белемгә нигезләп тормышка ашырырга кирәк, киләчәккә лаеклы мирас булып калсын.

Иң мөһим ачышлар

Америка галимнәре материаллар эволюциясе тарихындагы иң мөһим ачышлар исемлеген төзегән. Унынчы урында – Бессемер процессы. 1856 елда Генри Бессемер аз углеродлы корыч җитештерү процессын ачканнан соң, арзанлы корыч җитештерелә, транспорт, төзелеш зур тизлектә үсә башлый. Тугызынчы урында – рентген нурларының таркалуы ачылу. 1912 елда Макс Лауэ, әлеге нурларны кристалларга таркату ысулын табып, материалларны рентген белән тикшерү үсешенә нигез сала. Сигезенче урында – малахит белән лазуриттан бакыр табарга өйрәнү. Бу ачыш рудалардан тимерне аерып алуга башлангыч була. Җиденче урында – корычны мичтә эретү. Аны безнең эрага кадәр 300 ел элек Көньяк Һиндстанда уйлап табалар, соңрак ул Дәмәшкъ корычы, дип йөртелә башлый. Алтынчы урында – бетон. 1755 елда Джон Смитон бүген без бетон дип йөрткән гидравлик цемент уйлап таба. Бишенче урында – оптик микроскоп. 1668 елда Антони ван Левенгук 200 тапкыр зурайтырга сәләтле микроскоп ясый. Дүртенче урында – безнең эрага кадәр 2200 елда Иранда пыяла ясый башлау. Өченче урында – 1848 елда транзистор уйлап табылу. Әлеге ачыш башта электрон җайланмалар, аннары микрочиплар, соңрак компьютер технологияләре өчен менә дигән нигез була. Икенче урында – тимер эретү. Аны борынгы Мисырда уйлап тапканнар. Һәм иң мөһим ачыш – Менделеев таблицасы. Галимнәр аны кешелек тарихында иң зур роль уйнаган ачыш, дип атаган. Әлеге таблицадагы химик элементлар ярдәмендә Җир йөзендә яңадан-яңа материаллар һаман уйлап табыла тора.

(“The Guardian”).

Маск сабаклары

Дөньяның иң танылган һәм уңышлы инноваторларыннан берсе Илон Маск тормышыннан шактый файдалы сабак алырга була. Беренчесе – бик күп укырга кирәк. Илон балачагында ук Британия энциклопедиясен тулысынча укып чыккан һәм гомере буе китаптан аерылмый, чөнки уңышка ирешү өчен даими белем алу, яңа идеяләр белән гел рухланып яшәү зарур. Икенче сабак – рекламага акча әрәм итәргә кирәкми: яхшы сыйфатлы продукт җитештерелә икән, аны болай да сатып алачаклар. Эшкуарлык белән шөгыльләнүне яшьтән, бары тик үзең өчен генә җаваплы булган чактан башларга кирәк, өлкәнәйгән саен, гаилә һәм балаларны кайгырту зарурлыгы да арта бара. Бик күп эшләү сорала: Илон Маск еш кына атнасына 100 әр сәгать эшли. Зарлану һәм тәнкыйтьләү урынына файдалы эш белән шөгыльләнү, проблемаларны хәл итү юлларын эзләү мәслихәт. Клиентларны һәм коллегаларны гаиләне яраткан кебек ярату сорала – Маск аларга Twitter аша һәрдаим рәхмәтен җиткереп тора. Уңышка ирешергә ниятләсәң дә, эшнең барып чыкмау ихтималын да фаразлау мәслихәт. Хыялны тормышка ашыру өчен бик каты тырышу зарур, әмма шул ук вакытта уңышсызлыкка да алдан ук әзер булу яхшы. Яңа инновацияле карарлардан курыкмыйча, башкаларга иярмичә, үзең юл ярып бару хуплана. Эштә кечкенә генә булса да уңай максат табып, шуңа ирешү өчен гел алга бару мөһим.

(“Forbes.ru”).

Кыскарту зарур

Германия Хөкүмәте каршындагы Икътисад экспертлары советы (аны “Акыл ияләре советы” дип тә атыйлар) ил хакимиятенә халыкның хезмәт графигын үзгәртергә - 8 сәгатьлек эш көненнән баш тартырга тәкъдим итә. Белгечләр фикеренчә, эш көненең хезмәткәр иртән офиска килгәч башлануы һәм аннан киткәч тәмамлануы бүген инде анахронизм – искелек калдыгы булып тора. “Акыл иясләре советы” рәисе Кристофф Шмидт әйтүенчә, бүгенге динамик дөньядан артта калмаска ниятләгән эш бирүчеләр үз хезмәткәрләрен теләсә кайсы вакытта тиз арада туплый алырга, бернинди дә вакыт кысалары белән чикләмәскә тиеш. Швед галимнәре дә тикшеренү үткәргән һәм 2 сәгатькә кыскартылган эш көне хәзергесеннән күпкә файдалырак дигән нәтиҗә ясаган. Бу тикшеренү ил предприятиеләреннән берсендә 23 ай барган, эшчеләргә 8 сәгатькә түләнгән кадәр хезмәт хакы түләнгән. Предприятие хуҗасы хезмәткәрләренең эш күләменнән һәм сыйфатыннан канәгать калган. Кире искечә эшли башлагач, хезмәтнең нәтиҗәлелеге кимегән. Белгечләр әйтүенчә, эш сәгатен кыскарту хезмәткәрләрне яхшырак эшләргә мәҗбүр итә, алар сирәгрәк авырый да. Элегрәк Австралия табибләре дә шундый нәтиҗәгә килгән булган. Алар исәпләвенчә, эш атнасы 39 сәгатьтән артырга тиеш түгел, алайса хезмәткәрләрнең психик һәм физик халәте һичшиксез начарлана.

(“Die Welt”).

“Кояш” йорты

Испаниянең Прогрессив архитектура институты белгечләре Мадридта “акыллы” йорт уйлап тапкан һәм төзегән. Ул 15 көн эчендә җыела һәм үзе җитештергәннән өч тапкырга кимрәк энергия куллана, чөнки түбәсе кояш энергиясен файдалана торган сыгылмалы фотогальваник панельләр белән капланган. Йорт үзе агач, фанера һәм башка экологик материаллардан салынган. Эргономик формадагы бинада тәрәзәләр бик күп, алар табигый яктыртуны һәм җилләтүне тәэмин итә. Йорт түбәсенә яңгыр суын җыю өчен савытлар куелган. Fab Lab House дип аталган әлеге проект Испаниянең кечкенә шәһәрләре өчен эшләнгән. Арзанлы материаллардан нибары ике атна эчендә җыелганга, аның бәясе кыйммәт түгел. “Кояш” йортының мәйданы 75 квадрат метрга тәңгәл, андагы ресурслар исә 4 кешелек гаиләне тәэмин итәргә җитә. Әлеге проект Европаның Solar Europe People’s Choice Award экологик йортлар дизайны бәйгесендә беренче урын алган инде.

(“Интересно.cc”).

Талымсыз тамаксау

Сигез минутта – 113 панкейк, ун минутта – 241 тавык канаты яки 62 хот-дог, егерме ике минутта – 25 бигмак... Америкадан 29 яшьлек YouTube-блогер Мэтт Стоуни куйган ашау буенча дөнья рекордларыннан берничәсе генә әле бу. Megatoad псевдонимлы егет алты елда үз каналында 15 миллионга якын язылучы җыйган, һәм аларның саны һәр яңа рекорды саен һаман арта бара. Шулкадәр күп ашавына карамастан нибары 59 килограмм авырлыкта гына булган әлеге блогер нигә шулкадәр популяр соң? Social Blade веб-сайты мәгълүматлары буенча, ул ай саен 8 меңнән алып 127 мең долларга кадәр акча да эшли икән әле. Алты ел эчендә комагайның камера каршында ашаган ризыгы тонналап исәпләнә инде: шоколадлы дүрт мең данә M&M’s, литрлап бал, йөзләрчә кабырга, 750 граммлы Nutella какао-пастасы, 20 мең калорияле гигант бургер, 100 телем ак икмәк, 200 мармелад һәм башка ризык белән “сыйлаган” ул ашказанын. Стоуни каналындагы иң популяр видеоны исә – аның 15 кап бик ачы Корея токмачын ашавын – 116 миллион кеше караган.

(“Лента.ру”).

Газета өчен
Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

14 февраль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СИҢА КАЙТАМ». 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Акыл баттл» һәм «Сәйлән».
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Мин». 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
14.00 «Ком сәгате». 12+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «НАУЧИ МЕНЯ ЖИТЬ». 16+
10.30, 21.00 «КРИК СОВЫ». 12+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «Я НЕНАВИЖУ ДЕНЬ СВЯТОГО ВАЛЕНТИНА». 16+
14.35 «Люди РФ». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Открытый космос».
16.30 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «РОДИНА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

4.05 Зимние Олимпийские игры. Фигурное катание.
7.50, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор». 6+
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «СЕРЕБРЯНЫЙ ВОЛК». 16+
23.25 «Вечерний Ургант». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
12.40, 18.40 «60 Минут». 12+
14.30 «КАРИНА КРАСНАЯ». 16+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.20 «ХОЛОДНЫЕ БЕРЕГА. ВОЗВРАЩЕНИЕ». 16+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного.
7.35 «Александр Невский. Дипломат, воин, святой».
8.25 Легенды мирового кино.
8.55 Цвет времени. Альбрехт Дюрер. «Меланхолия».
9.05, 16.35 «ТАЙНЫ СЕМЬИ ДЕ ГРАНШАН».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 85 лет ЦДА. XX век. «После спектакля. Вас приглашает Центральный Дом актёра».
12.10 «Агатовый каприз Императрицы».
12.35 «О ЛЮБВИ».
13.55 Цвет времени. Николай Ге.
14.05 Линия жизни. Алексей Левыкин.
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора».
16.20 Цвет времени. Жан Огюст Доминик Энгр.
17.30 Исторические концерты. Пианисты XX века. Марта Аргерих.
18.40 «Настоящая война престолов».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.35 «Мальта».
21.05 «Сати. Нескучная классика...»
21.50 «А ЕСЛИ ЭТО ЛЮБОВЬ?»
23.50 Документальная камера. «Подпись автора».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЗОЛОТО». 16+
23.35 Остросюжетный «ПЁС». 16+

Сишәмбе

15 февраль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СИҢА КАЙТАМ». 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Уймак» һәм «Сәйлән».
16.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00, 0.25 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
14.00 «Ком сәгате». 12+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «РОДИНА». 16+
10.30, 21.00 «КРИК СОВЫ». 12+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ЛЕТНЕЕ ВРЕМЯ». 16+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Погоня за вкусом». 16+
16.20 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор». 6+
12.15 «Время покажет». 16+
13.30 Зимние Олимпийские игры. Фигурное катание.
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «СЕРЕБРЯНЫЙ ВОЛК». 16+
22.35 «Док-ток». 16+
23.30 «Вечерний Ургант». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.55 XXIV Зимние Олимпийские игры. Биатлон.
13.30 «КАРИНА КРАСНАЯ». 16+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
18.40 «60 Минут». 12+
21.20 «ХОЛОДНЫЕ БЕРЕГА. ВОЗВРАЩЕНИЕ». 16+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 Лето Господне.
7.05, 20.05 «Правила жизни».
7.35, 18.40 «Настоящая война престолов».
8.25 Легенды мирового кино.
8.55 Цвет времени. Илья Репин. «Иван Грозный и сын его Иван».
9.05, 16.35 «ТАЙНЫ СЕМЬИ ДЕ ГРАНШАН».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Александр Розенбаум в Государственном центральном концертном зале «Россия».
12.30 «А ЕСЛИ ЭТО ЛЮБОВЬ?»
14.10 Цвет времени. Жан Этьен Лиотар. «Прекрасная шоколадница».
14.20 «Игра в бисер».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Эрмитаж».
15.50 «Сати. Нескучная классика...»
17.30 Исторические концерты. Пианисты XX века. Артур Рубинштейн.
19.45 Главная роль.
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.50 Искусственный отбор.
21.35 «Белая студия».
22.20 «КЛУБ САМОУБИЙЦ, ИЛИ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ТИТУЛОВАННОЙ ОСОБЫ».
23.50 Документальная камера. «Парки советского периода».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЗОЛОТО». 16+
23.35 «ПЁС». 16+

Чәршәмбе

16 февраль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СИҢА КАЙТАМ». 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00, 0.50 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Шома бас» һәм «Калеб».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Чёрное озеро». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
9.40 «Ачыктан-ачык». 12+
10.30, 20.30 «Юлчы». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
14.00 «Ком сәгате». 12+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «РОДИНА». 16+
10.30, 21.00 «КРИК СОВЫ». 12+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «КАК ВОСПИТАТЬ МУЖА». 16+
14.30 «Люди РФ». 12+
15.00 «Эпидемия». 12+
15.30 «Зов крови». 16+
16.35 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор». 6+
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «СЕРЕБРЯНЫЙ ВОЛК». 16+
22.35 «Док-ток». 16+
23.30 «Вечерний Ургант». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
10.45 XXIV Зимние Олимпийские игры. Биатлон. Лыжные гонки.
13.30, 17.00, 20.00 Вести.
13.55 XXIV Зимние Олимпийские игры. Лыжные гонки.
15.20 «КАРИНА КРАСНАЯ». 16+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
18.40 «60 Минут». 12+
21.20 «ХОЛОДНЫЕ БЕРЕГА. ВОЗВРАЩЕНИЕ». 16+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05, 20.05 «Правила жизни».
7.35, 18.40 «Настоящая война престолов».
8.25 Легенды мирового кино.
8.50, 16.35 «ГЛЯДИ ВЕСЕЛЕЙ!»
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Дорогая Татьяна Ивановна...» Фильм-посвящение.
12.10 Дневник XV Зимнего международного фестиваля искусств в Сочи Юрия Башмета.
12.40, 22.20 «КЛУБ САМОУБИЙЦ, ИЛИ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ТИТУЛОВАННОЙ ОСОБЫ».
13.45 Искусственный отбор.
14.30 «Мальта».
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Белая студия».
17.40 Исторические концерты. Пианисты XX века. Артуро Бенедетти Микеланджели.
19.45 Главная роль.
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.50 Абсолютный слух.
21.35 Власть факта. «Священный союз и трудный выбор Александра I».
23.50 Документальная камера. «Суворов», или Два возвращения».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЗОЛОТО». 16+
23.35 «ПЁС». 16+

Пәнҗешәмбе

17 февраль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СИҢА КАЙТАМ». 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Бергәләп өйрәник» һәм «Сәйлән».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Ватандашлар». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Рәгыйдь - яшен яшьнәү». Рәгыйдь Халитов турында телеочерк. 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
14.00 «Ком сәгате». 12+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Калеб». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «РОДИНА». 16+
10.30, 21.00 «КРИК СОВЫ». 12+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ЗА МЕЧТОЙ». 12+
14.35 «Люди РФ». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Вокруг света. Места силы». 16+
16.20 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор». 6+
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «СЕРЕБРЯНЫЙ ВОЛК». 16+
22.35 «Большая игра». 16+
23.30 «Вечерний Ургант». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 12.40, 20.00 Вести.
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
13.00 XXIV Зимние Олимпийские игры. Фигурное катание.
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
18.40 «60 Минут». 12+
21.20 «ХОЛОДНЫЕ БЕРЕГА. ВОЗВРАЩЕНИЕ». 16+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Правила жизни».
7.35, 18.40 «Настоящая война престолов».
8.25 Легенды мирового кино.
8.50, 16.35 «ГЛЯДИ ВЕСЕЛЕЙ!»
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Вороне где-то бог...»
12.10 Дневник XV Зимнего международного фестиваля искусств в Сочи Юрия Башмета.
12.40, 22.20 «КЛУБ САМОУБИЙЦ, ИЛИ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ТИТУЛОВАННОЙ ОСОБЫ».
13.45 Цвет времени. Надя Рушева.
13.55 55 лет Евгению Гришковцу. Линия жизни.
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Моя любовь - Россия! «Модницы села Чернуха».
15.45 «2 Верник 2».
17.40 Исторические концерты. ПИАНИСТЫ XX векА. Владимир Ашкенази.
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Анна Козлова. «Рюрик».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.50 «Доживем до понедельника». Счастье - это когда тебя понимают».
21.35 «Энигма. Сайнхо Намчылак».
23.50 Документальная камера. «Четыре жизни Сергея Медынского».

«НТВ»
4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЗОЛОТО». 16+
23.35 «ЧП. Расследование». 16+

Җомга

18 февраль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СИҢА КАЙТАМ». 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30, 16.30, 21.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Рыцари вечности». 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Төймә» һәм «Сәйлән».
16.00 «Мин». 12+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.00 «КВН РТ-2022». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 14.00, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10 «Родная земля». 12+
20.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Әмирхан Еники турында телеочерк. 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «РОДИНА». 16+
10.30 «КРИК СОВЫ». 12+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «ОПУСТЕВШИЙ ГОРОД». 16+
15.10 «Клинический случай». 12+
15.40 «Это реальная история». 16+
16.35 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+
21.00 «ГОРОД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор». 6+
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
13.20 Зимние Олимпийские игры. Фигурное катание.
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.30 «Голос. Дети».
23.10 «Вечерний Ургант». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 20.45 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 20.00 Вести.
11.55 XXIV Зимние Олимпийские игры. Биатлон.
12.55, 18.40 «60 Минут». 12+
14.30 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
16.00 XXIV Зимние Олимпийские игры. Хоккей.
21.00 «Возможно всё!» 16+
23.00 «БЕНДЕР. ЗОЛОТО ИМПЕРИИ». 16+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Правила жизни».
7.35 «Настоящая война престолов».
8.25 Легенды мирового кино. Милош Форман.
8.50, 16.25 «ГЛЯДИ ВЕСЕЛЕЙ!»
10.20 «СЕКРЕТНАЯ МИССИЯ».
12.05 Открытая книга. Анна Козлова. «Рюрик».
12.30 Цвет времени. Василий Кандинский. «Желтый звук».
12.40 «КЛУБ САМОУБИЙЦ, ИЛИ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ТИТУЛОВАННОЙ ОСОБЫ».
13.50 Власть факта. «XVIII век: от реформ Петра I к абсолютизму Екатерины II».
14.30 «Беларусь. Несвижский замок».
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Сайнхо Намчылак».
16.15 Цвет времени. Клод Моне.
17.30 Исторические концерты. Пианисты XX века. Клаудио Аррау.
18.45 «Царская ложа».
19.45 «Смехоностальгия».
20.15 К юбилею Татьяны Михалковой. Линия жизни.
21.10 «ЧУЖАЯ РОДНЯ».
22.45 «2 Верник 2».
23.50 «ХОЛОДНЫМ ДНЕМ В ПАРКЕ».

«НТВ»
4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.30, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
11.00, 14.00 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «ЗОЛОТО». 16+

Шимбә

19 февраль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Мин». 12+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00, 0.40 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 «УЕННАН УЙМАК». 6+
16.30 «Юлчы». 6+
17.00 «Әдәби хәзинә». 6+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБиТ- шоу». 12+
23.00 «ЛЮБОВЬ БЕЗ ПЕРЕСАДОК». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Моңга чорналган язмыш. Александр Ключарев». 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 Спектакль «Казан егетләре». 12+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Сула!» Ришат Төхвәтуллин концерты. 6+
22.25 «Мунча моржасы». «Мунча ташы» спектакле. 12+

«ЭФИР»
5.00 «Люди РФ». 12+
5.30 «Опыты дилетанта». 12+
6.00 «Мировой рынок». 12+
7.00 «Сказочный патруль».
8.00 «Нездоровый сезон». 12+
8.50 «СРОК ДАВНОСТИ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЛЕВ». 16+
14.45 «Все, кроме обычного». 16+
16.00 «ПСИХОЛОГИНИ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЧЕЛОВЕК, КОТОРЫЙ СПАС МИР». 16+
22.50 «Человек - невидимка». 16+
23.45 «7 ДНЕЙ, 7 НОЧЕЙ С МЭРИЛИН». 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 11.30 Новости.
10.20 К юбилею Веры Алентовой. «Как долго я тебя искала...» 12+
11.50 Зимние Олимпийские игры. Биатлон.
12.55 «Видели видео?» 6+
14.55 «Короли лыж. Кто получит золото Пекина?» 12+
16.00, 0.45 Зимние Олимпийские игры.
18.40 «Точь-в-точь». 16+
21.00 «Время».
21.20 «БЕЛЫЙ СНЕГ». 6+
23.45 Дневник Зимних Олимпийских игр.

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «Формула еды». 12+
8.55 XXIV Зимние Олимпийские игры. Лыжные гонки.
11.55 «Сто к одному».
12.45 Вести.
13.00 «Юмор! Юмор! Юмор!!!» 16+
14.00 XXIV Зимние Олимпийские игры. Фигурное катание.
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
20.00 Вести в субботу.
21.00 «БАБУЛЯ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 «Снежная королева».
8.05 «ЧУЖАЯ РОДНЯ».
9.40 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
10.10 «Передвижники. Константин Маковский».
10.40 «ГУСАРСКАЯ БАЛЛАДА».
12.15 «Эрмитаж».
12.45 Человеческий фактор. «С неограниченными возможностями».
13.15 «Мудрость китов».
14.05 «Рассказы из русской истории. XVIII век». Владимир Мединский.
15.25 Гала-концерт в день рождения Юрия Башмета.
17.15 «Доживем до понедельника». Счастье - это когда тебя понимают».
17.55 «ДОЖИВЕМ ДО ПОНЕДЕЛЬНИКА».
19.40 «Энциклопедия загадок».
20.10 «ОГРАБЛЕНИЕ».
22.00 «Агора».
23.00 Клуб шаболовка 37.

«НТВ»
4.40 «ЧП. Расследование». 16+
5.10 «ВЫЙТИ ЗАМУЖ ЗА ГЕНЕРАЛА». 16+
7.20 Смотр.
8.00, 10.00 Сегодня.
8.20 «Готовим с Алексеем Зиминым».
8.45 «Поедем, поедим!»
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда с Сергеем Малозёмовым». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. ВОЗВРАЩЕНИЕ». 12+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 Ты не поверишь! 16+
21.20 «Секрет на миллион». 16+
23.25 «Международная пилорама». 16+

Якшәмбе

20 февраль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәгемә - 18!» ИлСафның юбилей кичәсе. 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 «Хайкю». 12+
9.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Очрашулар». Рифат Зарипов концерты. 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент.Общество». 12+
13.30 «Каләм әчендә галәм». Марсель Галиевның юбилей кичәсе. 6+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Чёрное озеро». 16+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «ДЕД, ПРИВЕТ!» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35, 23.20 «Халкым минем». 12+
5.30, 13.35 «Нәсыйхәт». 6+
6.00, 13.00, 0.40 «Татарлар». 12+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 Равил Харисовны искә алу кичәсе. 6+
9.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Әмирхан Еники турында телеочерк. 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы». 12+
14.05 «Минем күңел». Җәвит Шакировның 60 яшьлек юбилей кичәсе. 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 «Түгәрәк бәхет». Айдар Тимербаевның иҗат кичәсе. 6+
22.30 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Моңга чорналган язмыш. Александр Ключарев». 6+

«ЭФИР»
5.00 «Люди РФ». 12+
5.30 «Опыты дилетанта». 12+
6.00 «Мировой рынок». 12+
7.00 «Сказочный патруль».
8.00 «Кондитер». 16+
9.00 «ПСИХОЛОГИНИ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЧЕЛОВЕК, КОТОРЫЙ СПАС МИР». 16+
14.55 «История морской пехоты». 12+
15.50 «СРОК ДАВНОСТИ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЛЕВ». 16+
22.40 «Шерлоки». 16+
23.30 «ФОРС МАЖОР». 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
4.55, 6.10 «ЕГЕРЬ». 12+
6.00, 12.00 Новости.
7.00 Зимние Олимпийские игры. Хоккей. Лыжные гонки.
12.15, 17.00 Зимние Олимпийские игры.
15.00 Церемония закрытия Зимних Олимпийских игр.
19.10 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
21.00 «Время».
22.00 «ХРУСТАЛЬНЫЙ». 18+

«РОССИЯ»
5.15 «Я БУДУ РЯДОМ». 12+
7.00 XXIV Зимние Олимпийские игры. Фигурное катание.
9.30 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00 Вести.
11.30 «Парад юмора». 16+
13.45 «ПОСЛУШНАЯ ЖЕНА». 16+
17.50 «Танцы со Звёздами». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Энциклопедия загадок».
7.05 Мультфильмы.
7.45 «БРОДЯГИ СЕВЕРА».
9.00 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
9.30 «Мы - грамотеи!»
10.10 «ВРЕМЯ ЖЕЛАНИЙ».
11.50 Письма из провинции.
12.15 Диалоги о животных.
12.55 Невский ковчег. Теория невозможного. Олег Каравайчук.
13.25 «Архи-важно».
13.55 «Рассказы из русской истории. XVIII век». Владимир Мединский.
15.05 «ПОХИТИТЕЛИ ВЕЛОСИПЕДОВ».
16.35 «Пешком. Другое дело». Василий Поленов.
17.00 Спектакль «Маленький принц». Константин Хабенский, Юрий Башмет и Камерный ансамбль «Солисты Москвы».
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «ГУСАРСКАЯ БАЛЛАДА».
21.45 Ольга Перетятько и Хуан Диего Флорес в опере Г.Доницетти «Лючия ди Ламмермур». Дирижёр Эвелино Пидо. Венская Государственная опера.

«НТВ»
4.55 «ИДЕАЛЬНОЕ УБИЙСТВО». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.10 «Маска». 12+
23.30 «Звезды сошлись». 16+

СЕБЕРНЕҢ ИМАНЛЫ СӘҮДӘГӘРЛӘРЕ

(Ахыры. Башы 11 нче биттә).

Роза Әхмәдиеваның бабасы Назыйр ага - Тарада яшәп калган Айтыкиннарның берсе. Гафифә һәм Назыйр Айтыкиннар гаиләсендә Умрахилә, Сидхия, Сафия, Закирә, Фәүзия исемле кызлар, Али исемле егет үсеп җитешкән. Алар барысы да Октябрь инкыйлабына кадәр дөньяга килгән. Назыйр ага, кызы Фәүзия Нурмөхәммәт исемле егеткә кияүгә чыккач, аларга Үләнкүл авылында йорт салып бирә. Әхмәдиевларның уллары Рашат һәм Фәрит дөньяга килә. Роза апа үзе 1943 елда туган. Әмма аңа әнисе янында кадерле кызчык булып үсү язмаган. Роза апаның әтисе Нурмөхәммәт – Фин һәм Бөек Ватан сугышлары ветераны – Омскида партия мәктәбендә укып йөргәндә, Фәүзия апа печәнлектән егылып төшә һәм умыртка баганасын имгәтә, аңа гипс салалар. Аннары аларны әтиләре Тара шәһәренә алып китә. Фәүзия апа, кызы Розага биш яшь булганда, бу дөньядан үтә. Бу вакытта гаиләдә әле аңардан да кечерәк тагын бер кызчык була. Балаларны әтиләренең туганы үзенә сыендыра. Нурмөхәммәт ага, укуын тәмамлагач, аны эшкә җибәрәләр, өйгә хезмәтче хатын алалар. Нурмөхәммәт ага, алга таба, балаларга чит кеше булмас әле, әйбәт карар дип, хатынының туган тиешлесенә өйләнә. Роза апаның әнисенең бертуганнары Умрахилә, Сидхия, Сафия, Закирә озын гомерле була, берсе хәтта 100 яше җиткәндә генә вафат була, Али абыйсы Тарада аз санлы милләтләр мәгарифе бүлекчәсе башлыгы булып эшли.

Роза Әхмәдиева Омск педагогика институтын тәмамлап, 45 ел буе Омски педагогика техникумында физика һәм химия фәннәрен укыта. 75 яшьлек Роза апа бүген тәрбиягә алып үстергән кызы-киявенең, оныкларының кадерлесе булып гомер кичерә. Ул Руслан Ашпаков белән бергә «Педагогическая династия Айтыкиных» («Айтыкиннарның педагоглар династиясе») дигән китап әзерләп тә чыгарган.

Сөембикә КАШАПОВА.

Язмада фән докторы Ф.Вәлиев, тарих фәннәре кандидаты С.Татуаров һ.б. тарихчыларның материаллары файдаланылды.

Еш кына аеруча авыр җинаять кылучыларның акылга тулы булуына ышанасы килми. Мисалга, корбанын пычак чәнчеп теткәләгәннән соң, сәнәк тотып, үзе әйтмешли, «контроль удар» ясаган, ягъни башына кадаган Д.Тимофеевны алыйк. Бусы күптән булган явызлык. Былтыр 34 яшендәге шул ук бәндә тагын ике кешене ерткычларча үтереп ташлады. Психик чирле һәм эчкече буларак махсус исәптә тормый ул үзе. Әмма аның үткән тормыш юлы, кылган гамәлләре киресен раслый.

Исерек исәр ерткычлыгы

Дмитрий Тимофеев Удмуртиянең Камбарка шәһәрендә туа. Аңа 6 яшь чакта ике балалы гаилә Минзәлә районындагы Иске Мажын авылына күченә, малай шунда укырга керә. Әтисе Алексей аны 4 нче сыйныфтан соң мәктәпкә йөрмәдә, әнисе өйдә укытты дисә дә, Дмитрий грипп белән авырганнан соң, беркайда да укымавын әйтә. Шулай ук 12 яшьтән колхозда эшли, 13 яшьләр тирәсендә эчә башлавын һәм егермедә «запой»га китә торган эчкечегә әйләнүен дә сөйли ул.

Егеттә бар да тәртиптә түгел икәнен, бигрәк тә, исерек вакытта холыксыз булуын күрәләр авылда. Андый чакта кеше үтерү ихтималы да булу хакында иптәшләренә әйтүен Дмитрий хәзер дә искә ала, котырынкы икәнен белә, йөгәнсезләнеп кылган гамәлләрен хәтерлим дип бара.

Дары мичкәсе 2009 елда гаилә шул районадагы Рус Мөшегәсендә яшәгәндә шартлый. Июль аенда 22 яшь тулу көнен бәйрәм иткәннән соң, айный алмаган егет ындыр табагында эштә чакта югарыда телгә алынган сәнәкле явызлыкны кыла. Хәзер ошбу гамәлен шунда эшләүче хатын-кызны яклау белән аклагандай итә ул.

Моның өчен Минзәлә район суды карары нигезендә Яшел Үзән районындагы Түбән Карамалы колониясендә 9 ел утыра һәм 2018 елда иреккә чыгып әти-әнисе янына кайта. Әлбәттә, акылга утырмый, чөнки эчүен ташламый. 2020 елда бер егетнең борын сөяген сындыра, үзе «ялгышлык белән» дип аклана, кеше үтерүче белән сүзгә керәсе килмичә, авыл малае дәгъва белдерми, ләкин аның ата-анасы гаризасы буенча Д.Тимофеев административ күзәтүгә алына. Шул вакытларда гаиләнең терәге булган хатын-кыз үлеп китә, хөрәсән ирләр түләмәгәч ут, газ бирү туктатылып, йорт яраксыз хәлгә килә. Ата-ул берникадәр Менделеев районында яшәүче икенче малай янында торалар.

Узган елның июль аенда алар икәүләп Тукай районының Югары Суыксу авылына килеп Алексейга ерак туган тиешле эшмәкәр Г.Пискунов хуҗалыгында үрдәк, табак һәм күркәләр карарга ялланалар, янәшәдәге өйдә яшиләр. Ирле-хатынлы Пискуновлар төзелеш өчен цементлы коры катнашмалар эшләү белән дә шөгыльләнәләр. Шул ук ишегалдындагы җитештерү бинасының көнкүреш бүлмәсендә Мөслим якларыннан килгән тагын ике ир-ат тора. Пискуновларның үз йортлары да янәшәдә генә.

Сүз уңаеннан катнашма ясаучы ялчыларга кыскача бәяләмә биреп үтик. Әлбәттә, мондый җирләргә җитеш-юньле тормышлы аек кешеләр килеп эләкми. 1969 елгы Андрей Галимов гаиләсеннән күптән аерылган, берничә тапкыр хөкемгә дә тартылган, балаларына хокукыннан мәхрүм ителгән зат. Чаллыда яшәүче улы Руслан 2020 ел азагында кунакка килүен, тормышыннан зарланмавын, шуннан соң аралашкан-хәбәрләшкәннәре булмавын әйтә. 1975 елда туган Радик Ситдыйков Мөслим район үзәгендәге ата-анасы йортында теркәлгән, гаиләсе, балалары юк, күп еллар элек җинаять җаваплылыгына тартылганы бар. Төп йортына кайткалап йөри ул, узган ел август аенда да ике атна торып, туганнарына мунча салуда ярдәм итә һәм 22 августта эшләү һәм яшәү урынына китеп бара.

Катнашма ясаучы көнлекчеләр рәсми рәвештә эшкә алынмый, билгеле. Хуҗалар зарланмый алардан, эчсәләр дә эшлиләр, иң мөһиме, тавышланмыйлар диләр. Бу яктан Тимофеевларның өлкәне дә әллә ни борчулы түгел. Ә менә кечесе Дмитрийны хуҗабикә акыл ягыннан тайпылышлы дип атый, иренә ул бәндәләрне куып җибәрергә кушып та карый, чөнки алардан курка. 22 августта Георгий Казанга китеп баргач та баласы белән беркая чыкмыйча өендә бикләнеп утыра.

Шул ук якшәмбедә Алексей Тимофеев та кече улы янына китә, ә Радик Ситдыйков кайтып керә. Төн уртасында әйләнеп кайткан Г.Пискунов кош-корт караучылар яши торган йортта һәм Мөслим абзыйлары бүлмәсендә ут януына игътибар итә, юл уңаендагы беренчесе тәрәзәсеннән карагач йоклап яткан Д.Тимофеевны күрә, ерактарак урнашкан икенче бина янына барып тормый. Иртәнге сәгать 5 тә генә барып керә ул анда.

Канга батып идәндә яткан Радик Ситдыйковның салкын икәнен капшап карагач та тоя ул һәм Д.Тимофеев яшәгән өйгә ашыга. Чөнки моның шул явыз эше икәнен икеләнми. Сәрхушне төрткәләп уятып: «Син ник Радикны үтердең?» – дип кычкыра. Анысы мин беркемне дә үтермәдем, дип әйләнеп ята. Полициягә шалтыраткач та тетрәнгән Пискуновлар икәүләп Андрей Галимовны эзләргә керешәләр. Хуҗалык җирлегендә озак йөрергә туры килми, шул тирәдәге күлгә табарак баргач икенче мәет табыла, димәк, Тукай районы эчке эшләр бүлегенә тагын бер шомлы хәбәр ирештерелә.

Өлкән оператив хезмәткәр Фидан Хәмматов соңгысын Югары Суыксуга таба барганда ала. Пискуновлар ул килеп җиткәнче үк, видеокүзәтү җайланмасы язмасын карап өлгергән була. Анда кичке сәгать 5 ләрдә Дмитрийның җитештерү бинасы һәм андагы көнкүреш бүлмәсе ишегеннән эчкә керүе, шактый вакыт узгач аннан Галимов белән Тимофеев чыгып видеокамера «күзеннән» читкә китүләре, күп тә үтми икенчесенең яңадан пәйда булып бинага кереп пычакка охшаш әйбер тотып чыгуы һәм корбаны артыннан китүе күренеп тора. Язмага чит кешеләр эләкми.

Бу хакта Ф.Хәмматовка да әйтелә, ирле-хатынлылар икесе дә Д.Тимофеевның акыл ягыннан кимчелекле икәнен искәртәләр.

Күпне күргән опер ике кеше җанын кыюы билгеле булган диванадан барысын да көтәргә мөмкин икәнен чамалый, билгеле. Йокысыннан уянып торагыннан чыгып килүче әзмәвергә пистолет төбәп, аны йөзтүбән җиргә яткыра, күз ачып йомганчы богаулап та куя.

Тикшерү комитетының аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе Д.Ф.Мөхәммәдиев ике кешене үтерү очрагы буенча шул көнне үк җинаять эше кузгата. Суд-медицина эксперты ишегалдында табылган Андрей Галимов гәүдәсендә, башлыча, күкрәк, муен тирәсендә 9 җәрәхәт булуын, йөрәк һәм башка эчке әгъзаларга зыян килүе, пычак белән аркылыга кисү нәтиҗәсендә муендагы төп кан тамырлары өзелү һәм башка яралар булуын күрсәтә. Радик Ситдыйковның да вәхшиләрчә үтерелүе белдерелә. Анда үткен-очлы әйбер белән кадап авыр җәрәхәтләр ясау өстенә типкәләп күкрәктәге бик күп сөякләр сындырылу да беленә.

Д.Тимофеев гаебен кире кагып тормый. Тикшерүче Д.Мөхәммәдиев аны шул көнне үк фаҗига урынына алып бара. Анда шаһитлар алдында һәм мәрхүмнәр ролен башкарган ике статист ярдәмендә котырынкы гамәлләрен ни рәвешле ясавын күрсәтеп һәм сөйләп бирә ул.

22 август кичендәге фаҗигане күбрәк ул сөйләгәннәр буенча күзалларга туры килә. Ул өлкәнрәк ирләр торагына кергәч тә, «фанфурик» дип йөртелүче спирт эчә алар. Әйтүенчә, өчесенә, йөзәр граммлы 15 шешәне бушаталар. Низаг чыгу сәбәбен А.Галимовның ул су кушкан спирт каты булган дип сүгенә, аңа атап начар сүзләр кычкыра башлавы белән аңлата. Нәтиҗәдә, Андрейны дөмбәсләргә тотына, анысы урамга ычкынгач, артыннан чыгып муен тирәсенә берничә тапкыр чәнчи дә өйгә керә. Моны үтерү максаты белән эшләвен әйтеп тора ул. Ситдыйков белән берәр чәркәне бушаткач, ишегалдындагы А.Галимовны эзләп таба, аның муенындагы ярасын кысып утыруын күргәч пычак белән тетеп ташлый, әйләндереп салып аркага да бер-икене кадагач, яңадан Радик янына керә. Аны үтереп ташлау өчен дә сәбәп чыга, әйтүенчә, ул да начар сүзләр ычкындыра, эчәргә спирт бирми һәм акайган бәндә кулына шул ук пычакны ала, Ситдыйков идәнгә каплангач ярсып типкәләп ташлый. Аның үле икәненә шикләнми, ишегалдында яткан Галимов янына барып аның да җансыз булуына ышангач өенә кайтып йокыга тала.

Тикшерүче Д.Мөхәммәдиев аңа психиатрик экспертиза билгели. Эксперт хроник чирләрем юк, табибта исәптә тормыйм, барысын да аңлыйм, укый-яза беләм дип вакыйгаларны җиренә җиткереп бәян иткән ир-атның рухи кимчелекләре булса да, җинаятьне аңлы рәвештә эшләгән дип белдерә.

Наил ВАХИТОВ.

Тормышка гашыйк ДАНИЯ

Татарстан Журналистлар берлегендә гадәти булмаган чара узды. Аның үзенчәлеге рәссам, язучы, журналист халкын берләштерүендә. Чараның сәбәпчесе күренекле радио журналисты, язучы Дания Гайнетдинова бирелдә матур гомер бәйрәме уңаеннан картиналар күргәзмәсен ачты.

Дания ханымның тормышка соклануын югалтмыйча, һаман яшь калуының серен нидә, дигән сорауга картиналарда җавап табарга мөмкин. Гүзәл табигать, кош-корт дөньясы, башларны әйләндерерлек хуш исле чәчкә бәйләмнәре Д.Гайнетдиновага илһам, яшәр өчен көч бирә. Туган ягы Теләче районы Олы Тиләҗе авылының иркен болыннарын, ямьле Мишә буйларын, ямь-яшел чирәмле капка төпләрен, каз көтүләрен бик яратып сурәтли ул. Кечкенәдән ат җене кагылган рәссамның картиналарында колынлы атларны бик еш очратырга мөмкин. Балачакта әтисенең атына атланып Сабан туенда беренчелекне яулавы әле дә Дания ханымның йөрәген ижатка дәртләндереп тора.

Яшь калуының тагын бер сере – хезмәт. Әтисе Заһретдин абзый Бөек Ватан сугышында батырлыклар кылып кына калмый, яудан кайткач, бөтен Союзга танылып, ВДНХның алтын медаленә лаек була. Әнисе Миңлебикә тугыз бала үстереп, «Ана даны» ордены белән бүләкләнүгә өстенә, сыер, сарык, бозау, корткош тулы хуҗалыкны да алып бара. Шундый тырыш, эшчән гаиләдә туган кыз бала, әлбәттә, кечкенәдән эшкә өйрәнеп үсә. Хезмәт сөючәнлек, кызыксынучанлык аны башта – Чабаксар икътисад техникумына, аннары Казан финанс институтына алып килә. Шуннан соң гына Казан дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлап, Д.Гайнетдинова күңеленә якын һөнәрне таба. Китап нәшриятында әдәби редакциядә һәм республикабыз Язучылар берлеге каршында оешкан СССР әдәби фондының Татарстан бүлекчәсендә эшләгән елларда исә язучы буларак каләмен ныгыта. Бүген ул - унлап китап авторы. Беришләре төрек теленә тәрҗемә ителеп, Анкара шәһәрендә дә басылды.

Яшь калуының тагын бер сәбәбе нәниләр, балалар һәм яшьләр белән әвәрә килеп эшләүдә булса кирәк. 1991 елда «Татарстан» радиосында эшли башлаганнан бирле, Дания ханым балалар һәм яшүсмерләр өчен бихисап тапшырулар эшләде. Аларда балаларны үзләрен катнаштырып, татар теле, мәдәниятенә кызыксынуларын үстерде. Нәтиҗәдә, балаларның беришләре үзләре радиожурналист булып китте. Бүген «Татарстан» радиосында матур тапшырулар белән куандыручы Раил Садриев, мәсәлән, шундыйлардан.

Дания ханымның эше радио чикләрен узып китте. Мәсәлән, «Җыен» фонды белән берлектә алар берничә ел балалар җырларына бәйге үткәрде. Аннары «Казан» милли мәдәният үзәге белән бергә ун ел буе «Җырлыйсы килә» бәйгесен оештырды. Анда республикабыздан гына түгел, Россиянең төрле төбәкләреннән, Казахстан, Үзбәкстаннан милләттәшләребез катнашты.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Дания Гайнетдинова радио тыңлаучыларны атнага бер тапкыр эфирга чыга торган «Татарстан дулкынында» тапшыруында матур әдәби телдә республикабызның мәдәни тормышы белән таныштыруын бүген дә дәвам итә.

Күргәзмә ачылышында Д. Гайнетдинованы Язучылар, Рәссамнар, Журналистлар берлекләреннән иҗатташ дуслары тәбрикләп, алга таба да тормышка сокланып, гаҗәпләнеп, көн саен яңадан гашыйк булып яшәвен теләде.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 11.02.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2750 данә

Заказ 2739

16+